
PRESSA.RU

1926–1991 ЕЛЛАРДА **АЗАТ ХАТЫН**



2017 **МАЙ № 5**

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

БАЛАМНЫ КҮРДЕГЕЗМЕ ӘЛЕ

әти-әниләр ярышы

ЯШЬЛЕКТӘН КАЙТАВАЗ

үткәннәргә юллар юк

МАРСЕЛЬ ВӘГЫЙЗОВ СЫЙЛЫЙ

тай итеннән калҗа

Гүзәл ГЫЙЛАЕВА:

«БАРЫСЫ ДА ЧИСТА СУДАН БАШЛАНА...»



PRESSA.RU



И-и ямьле туган ягым!

И-и ямьле туган ягым!
И-и ямьле туган ягым!



Туфан МИҢНУЛЛИН.
Фото: Рөстәм МӨХӘММӘТҖАНОВ

Кама Тамагы минем изге төбәгем. Анда минем ата-бабаларымның каберләре, ул җирдә мин дөньяга беренче кат аваз салганмын, шул җирнең туфрагына беренче тапкыр аяк басканмын. Ул җир минем җанымның, рухымның иң газиз кисәге. Илһамымның чыганагы. Менә мин шул җирнең баласы булганга бу җирнең хуҗасы дип санаган Иделнең биек ярында басып торам: каршымда Чулманның Иделгә кушылган урыны. Шуңа күрә дә без Кама Тамагы дип аталабыз. Каршымда – бөек Болгар җирләре, уемда – тарих. Илемнең тарихы, халкымның тарихы. Ул тарихта безнең як – Тау ягы да бар. Без дә Болгар дәүләтенең бер өлеше.

Нариман КАМАЛОВ

Гүзәл Кама Тамагы

*Чал Каманың зур Иделгә
Кушылган бер җирендә
Зәңгәр тонык томан аша
Акчарлактай күренә.*

*Әллә килгән дастаннардан,
Әллә тылсым куллары?!
Тау күтәреп, таш чыгара
Аның батыр уллары.*

*Мәтрүшкәле, гөлҗимешле,
Алмагачлы Тау ягы.
Тау ягының ак чәчәге
Безнең Кама Тамагы.*

*Идел-Кама, акчарлаклар,
Ак пароход дулкыны –
Букет сыман уч төбендә
Җыйган ул матурлыкны.*

*Иген шаулый, тургай җырлый,
Чишмә ага таулардан.
Сәлам бирә танкерлары
Чал Иделдән, Камадан.*

*Биш диңгезнең маягы
Гүзәл Кама Тамагы.
Нинди матур! Шау чәчәктә
Ак сиреньнәр таудагы.*

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2017

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электронное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

9 Май – Җиңү көне



5'2017

Фото: Ксения Богданова

Җитәкче-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Җитәкче урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Гүзәл Гыйлаева
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 28.04.2017 ел.
Заказ А-1089.
Тираж 6097.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002




PRESSA.RU

27 МАЙ — РАМАЗАН АЕНА КЕРӘБЕЗ

■ Рамазан – сабырлык ае, ә сабырлыкның нәтиҗәсе – җәннәт.
■ Ураза тоткан кешеләргә ике зур сөенеч бар. Беренчесе – ифтар вакытында, икенчесе Кыямәт көнендә, Аллаһы Тәгалә белән очрашканда.
■ Рамазан аеның беренче ун көне рәхмәт көннәре, икенче ун көне – гөнаһлардан пакьләнү көннәре, соңгы ун көне – уттан котылу көннәре.
■ Һәрнәрсәнең бер зәкяте, ягъни пакьләнүе бардыр, тәннең зәкяте – уразадыр.
■ Кем Аллаһыга ышанып һәм савабын Аллаһыдан көтеп ураза тотса, ул кешенең эшләгән гөнаһлары гафу ителер.
■ Ураза – кешене начар эшләрдән саклаган бер калкандыр.
■ Уразадагы кеше Аллаһ нигъмәтләренең кадерен яхшырак аңлый башлый.
■ Ураза тотучы фәкыйрь-мохтаҗларның, матди яктан авыр тормыш кичерүчеләрнең хәленә төшенә.
■ Уразада кылынган изге гамәлләрнең әҗере уннан җиде йөзгә кадәр арта.
■ Рамазан – догалар, теләкләр, үтенечләр кабул була торган ай.


Казан. Борнай мәчете. Айдар Ильясов эше.





Нур ӘХМӘДИЕВ

Иртәнге дога

И Раббым!
Рәхмәт, бүген дә
Кояшымны күрдем.
Сөйгәнемнең керфекләрен
Таң җиленә төрдем.

Мең разый, исән дусларым,
Тыныч җирем, күгем.
Өстемә алыр хәлдә мин
Дөньялыкның йөген.

Әткәем укый намазын, –
Туган нигез исән.
Телем корсын ятимнәрдән,
Гариплардән көлсәм.

И Раббым, сулар агышын,
Кош сайравын тыңлыйм.
Зәңгәр күкләргә сокланып,
Ышаныгыз, туймыйм!

Балаларым, оныкларым
Бар да исән-имин.
Җирдәге һәммә кешегә:
– Бәхетле бул! – дим мин.

PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА

12







ЧИСТА СУ – ТОРМЫШ УЛ...
Ф. Мостафина

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ

8





«ЯРАТАМ!» ДИП ӘЙТЕГЕЗ
М. Авзалова



20

«САНДУГАЧ САЙРАР ИЛЕМ»
Г. Хәсәншина




16

БАЛАМ НИНДИ – КҮРЕГЕЗ!
С. Гаффарова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





«ЯШӘҮДӘН ЯМЬ ТАБА БЕЛГӘННӘР ОШЫЙ»
Ч. Әхмәтова

24

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



34

ӨЗЕЛГӘН КЫЛЛАР
Р. Кәримова

ЯШӘЕШ 

40



МИНЕМ ЖУРНАЛИСТИКАМ
Э. Закирова



ИЛАҺИ НИЯТ КЫЛДЫМ...
Р. Ахунов

52

ШУЛАЙ УК: 

38 АЛ ЯРАННАР КЕБЕК АЛСУЛАНА...
Р. Вәлиева

48 ЯШЬЛЕКТӘН КАЙТАВАЗ
Л. Фаршатова

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 

60



СӘЙЛӘНЛЕ ШАРФ

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

ИҢ АВЫР ЧИРАТ. ТОРМЫШ КЫЙММӘТЛӘРЕ.

ӨЙНЕ ИРГӘ ЫШАНЫП КАЛДЫРЫП БУЛАМЫ? ФИКЕР.

БЭКПЕКЕР ЯЗМАЛАРЫ. МИН АЧКАН ДӨНЬЯ.

ЛӘЙСӘН ГЫЙМАЕВА БЕЛӘН БУЛАТ БӘЙРӘМОВТАН МАСТЕР-КЛАСС.



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Бөек Җиңү көне якынлашкан саен, күңелдә хатирәләр уяна. Канлы сугышны үз күзләре белән күреп, аның эчендә булып, исән-сау кайткан Хәлилова Фатыйма Хәбибулла кызы турында бу хатирәм.

1921 елда Әгерҗе районы Исәнбай авылында – ярты авыл ачлыктан үлем түшәгендә ятканда туа ул, алабута икмәгеннән ясалган имезлек белән исән калып кара әле син! 20 ел солдатта хезмәт иткән Хәбибулла да кызының үзе кебек үк сугыш газапларын күрәсен күңеле белән сизенде микән?

Укырга теләге көчле булган кыз 1938 елны Алабуга педагогика техникумын тәмамлый, аннан институтка да керә. Үзе чибәр, комсомол алдынгысы да булган кыз турында «Комсомольская правда» газетасында да язып чыгалар. Институтта укыганда беренче мәхәббәте – Салих исемле егетне очрата. Әмма... сугыш хыял-өметләрне җимерә. Салих сугышның беренче көннәрендә үк Курск дугасында һәлак була.

1943 елда, сөйгәне өчен үч алу теләге белән, Фатыйма үзе теләп фронтка китә – Казанда оешкан 1872 нче номерлы зенит-артиллерия полкында снайпер була *(фотода – ул уртада)*. Полк Днепр елгасыннан фронт юллары буйлап Польшаның Висла елгасы буенда урнашкан Деблин шәһәренә кадәр барып җитә. Беренче мәлләрдә полкта 750 ир-ат һәм 789 хатын-кыз исәпләнә. Күбесенә 17-18 яшь – Җиңү көнен шуларның күпмесе күрде икән?

1944 елда полк Украинаның Коростень шәһәрендәге тимер юл үзәген һәм Уж елгасы аша салынган күперне саклый. Көндез күктә разведка самолетлары очса, төнлә кыска интервал белән бишәрләп-алтышарлап немец бомбардировщиклары бомба яудыра. Күккә төбәлгән зениткаларның уттай кызган көпшәләре төн карасында гигант шәмнәр булып күренә.

1945 елның гыйнварында алар соңгы пункт – Деблин каласына якын урман эченә урнаша. Кала өчен каты көрәш бара. 280 дошман самолеты ябырыла алар өстенә. Шәһәрдән нигез урыннары гына кала, әмма Висла аша салынган күперне, бик күп корбаннар бәрабәренә булса да, зенитчылар саклап кала.

Бу полк дистәләрчә аэродромны, тимер юл станцияләрен, күперләрне саклый. Шуның белән совет армиясенә Җиңү яуларга зур ярдәм итә.

Җиңү!!! Висла буендагы шау чәчәктә утырган грушаларны, чәчәккә бөреләнгән сиреньнәрне кызлар яңа күргәндәй була. Әмма йөрәкләрендә сугыш гөрелтесе мәңгегә кала. Күк күкрәгән саен, йөрәкләре кысылып, сыкрап яшәячәк алар...

Сугыштан соң Фатыйма Хәлилова озак еллар Барҗы урта мәктәбендә укыту бүлеге мөдире булып эшли. Фронт юлларын үткән Касыйм атлы егеткә кияүгә чыга. Алты бала: дүрт кыз, ике егет үстерәләр. Сугыштан соңгы тормыш та шома гына бармый. Сугыш аркасында өзелгән укуын ул читтән торып дәвам итә. Мәктәптә татар һәм рус телләреннән белем бирә. Фронтовик язучыларның иҗатын балаларга сөйләгәндә, аның күзләреннән мөлдерәмә яшь тама. Могҗиза белән исән калып, туган якларына әйләнеп кайткан кешеләр сугыш турында сөйләргә яратмый. Хатирәләрне яңарту – төзәлә башлаган күңел яраларын кузгатуга тиң. Фатыйма апа да сугыш турында сөйләргә яратмады...

Ветераннар рәте елдан-ел кими. Хәлилова Фатыйманың китүенә дә май аенда 17 ел була. Үз теләге белән сугышка китеп, амазонкалардай, кулына корал тотып көрәшкән, илебезнең җиңүе өчен үз өлешен керткән Фатыйма Хәбибулла кызы кебекләр онытылырга тиеш түгел.

Гөлзада ӘХТӘМОВА.
Алабуга шәһәре.

Бу шатлыклы да, кайгылы да көнне әтием Гаязетдин гомере буе көткәндер. Сугыш тәмамланганга күпме гомер узган, ләкин сугыш кырында вафат әтисенең каберен дә белә алмый йөдәде ул. Күпме эзләп тә, очына чыгып булмады.

Беркөнне сеңлем Ленара шалтырата: «Абдулла бабай турында мәгълүмат таптым бит», – ди. Кайда вафат булуын, кайда күмелгәнен «Память народа» дигән сайтка куйганнар икән. Шушы мизгелдә ниләр кичергәнемне үзем генә беләм. 70 елдан соң, инде бөтен өметләр өзелде дигәндә, бабабызның кабере табылган! «Вахта Памяти» экспедициясе, Алматы шәһәре, Псков һәм Томск өлкәләренең эзләнү отрядлары «2 нче Балтыйк буе фронтының 22 нче армиясендә сугышкан 54 нче аерым укчылар бригадасы сугышчыларын ачыклау һәм туганнар каберлегенә күчереп күмүне максат

иткәннәр. 54 нче аерым укчылар бригадасы сугышчылары Калинин өлкәсенең Новосокольнический районы Пичевка авылында җирләнгән булып чыга. Өч елга сузылган эзләү дәверендә 373 сугышчының җәсәден эзләп тапканнар. Алар арасында бабабыз Гимальдинов Абдулла Хәйретдин улының да исеме бар.

Абдулла бабай 1912 елда Буденный районының (хәзерге Буа районы) Биморза авылында туа. Сөендек авылы кызы Миһриҗамал белән 1938 елда тормыш корып җибәрә. 1939 елда уллары Гаязетдин тугач, бабай Мәскәүгә эш эзләп чыгып китә. «Урнашкач, кайтып алырмын», – дип вәгъдә бирә. Бабайның язган хатлары әле дә саклана. Кучтәнәчкә җибәргән печенье савытын да, пөхтәләп, ак биләүгә төреп, сандыгында әби бик кадерләп саклый иде.

Бабай вәгъдәсендә тора алмый, 1941 елны сугышка китә. Шул елның көзендә укчылар бригадасы оеша, бабайны 22 нче армиянең 54 нче аерым укчылар бригадасына билгеләләр. 1941 елның 5 декабрендә Озинки станциясеннән озатылган эшелон 9 декабрьдә Химки шәһәренә килеп җитә. Аннары инде аларны Осташков районына җибәрәләр. 54 нче аерым укчылар бригадасы Холм шәһәре өчен сугыша. Ел буена монда оборона тоталар. 1942 елның декабре – 1943 елның гыйнварында Великие Луки өчен барган аяусыз сугышта көрәшеп, күбесе ятып кала.

Бригада 1944 елның 13 гыйнварында Насва станциясе янында оборона тота. Аннары инде Ягодкино-Федорухново, Новосокольники фронты... 54 нче аерым укчылар бригадасы Балтыйк буе тарафына таба күчә бара. Бу – соңгы яу... Абдулла бабай 1944 елның 16 гыйнварында сугыш кырында башын сала.

Ә безнең әби исә бабайны гомере буена көтте... Куллары белән битен каплап, шыпырт кына елар иде...

Аларның бердәнбер баласы булган әти үсеп җитә, әниебез Равия белән гаилә кора, без – алты баланы үстерә, зур йорт сала. Әтисеннән 2 яшендә генә калган әтиебез бабайның каберен эзләп табу теләге белән яшәде. Аны фәкать фотосурәтенә карап кына белә иде. Казанга барып та, әтисе турында бер мәгълүмат та таба алмый кайткач, барлык өметен югалткан кебек иде ул. Ниһаять бабайның хәбәре безгә дә килеп иреште. Ләкин... аны инде әби дә, әти дә белә алмады... Без – аларның балалары һәм оныклары, бабабыз хакындагы шушы хатирәне гомер буе күңелебездә саклarбыз, аның белән горурланып яшәрбез.

Туган нигезебез булган Биморзага шатланып кайтабыз. Туган йортның ямен, җылысын саклаучы әниебез Равия безне гел шатланып каршы ала. Аллаһы Тәгалә аңа озын гомер биреп, исән-сау булса иде.

Зөлфия ХӘЙРУЛЛИНА.
Буа шәһәре.

34 ел элек бакча өчен җир кишәрлеге алганда, шушы җирне кабат үзебезнеке итәр өчен никадәр көч, вакыт, чыгым кирәк булыр дип, башыбызга да килмәгән иде.

Безгә биргәндә ачык ялан булган бу җирләрне уңдырышлы кара балчык иткәнче күпме хезмәт кергәнен үзебез генә беләбез. Ирем, алныялны белмичә, үз көче белән ике катлы бакча йорты салды.

Бу җирне инде бер хосусыйлаштырган идек. Аннан соң да берничә тапкыр документларны үзгәртәсе булды. Ел саен дигәндәй, законга үзгәрешләр керә дә, җир документларын кабат үзгәртергә туры килә...

Быел менә бакчабызны сатарбыз дигән идек. Кулдагы кәгазьләр тагын яраксыз булып чыкты. Былтыр кадастр номерлары алган идек, быел җирне межалатырга да кирәк икән. Җирне хосусыйлаштырган вакытта йорт күрсәтелми калган. Хәзер үзебез салган шушы йортыбызны да хосусыйлаштырасы, ди. Бу эш белән йөрүчеләр белә инде: анда һәр кәгазь, һәр тамга түләүле. Алары – аерым бер тарих. Сүзем ул хакта түгел.

Шушы бакча документлары артыннан йөри башлагач, Казанның үзебез яшәгән район БТИсына мөрәҗәгать итәргә туры килде. Хәзер шунысы ярый – бер оешма иенчесеннән документларны электрон рәвештә генә соратып ала. Ярты сәгать тә үтмәде, документлар килеп тә җитте. БТИ хезмәткәре, яшь кенә кыз, озаклапниләрдер язып, кәгазьләрне безгә тоттырып, күрше бүлмәдә генә урнашкан банк бүлекчәсенә акча түләргә җибәрде. Ниһаять документларны кулга алган шатлыктан, карап та тормый гына биш меңгә якын акча түләп, янә бу кыз янына килдек, ул тагын ниләрдер тутырды...

Инде булды, дип, тынычлап кайтып китсәк, ике сәгатьтән соң БТИдан шалтыраталар. Баксаң, электрон аша безнеке урынына башка бер кешенең документларын җибәргәннәр. БТИда шул килеш безгә биргәннәр, без дә карамыйча гына алганбыз. Җитмәсә, кеше документлары өчен банкка акча да түләгәнбез...

Бу очракта гаеп безнең үзебездә дә бар. Йә, кем инде тикшерми генә документларны кабул итеп ала?!

Мондый хәл бер безнең белән генә булса, очраклылык, дияр идең. Юк шул. Болар һәр эшкә дә шулай җавапсыз карарга өйрәнгән, ахрысы. Беренче барганда, бер егетнең елар чиккә җитеп: «Инде нишләргә?» – дип гаҗизләнеп соравына игътибар иткән идем: баксаң, аның 90 квадрат метрлы өйләрен БТИ хезмәткәрләре 40 квадрат метр итеп ясап биргәннәр. Хәзер өйнең кәгазьдә күрсәтелгәннән күпкә зуррак икәнен фәкать суд аша гына дәлиллисе икән. Егетнең, ачуланып, чарасыз чыгып китүдән башка хәле калмады. Артыннан җәлләп калган идем.

Инде менә безнең белән шундый ук хәл. Һәм бу да соңгысы түгел. Кулыбызга адашып килеп кергән теге документларны илтә барганда, безнең алда торучы ханымның да кәгазьләрендә хата булып чыкты...

Нихәл бу? Документлар белән эш иткәндә аеруча сак һәм игътибарлы булу сорала түгелме соң?..

Гөлнәзирә НУРИЕВА.
Казан.

Хөрмәтле укучыларыбыз!
Сездән хатлар көтеп калабыз.
Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2.
e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU




Фото интернеттан алынды

«ЯРАТАМ!» ДИП ӘЙТЕГЕЗ



ИШЕТӘБЕЗМЕ БЕЗ АЛАРНЫ?! БЕЛӘБЕЗМЕ БЕЗ АЛАРНЫҢ НИНДИ УЕННАР УЙНАГАНЫН, НИЛӘР УЙЛАГАНЫН?!

Мәдинә АВЗАЛОВА

Язмага алынганчы, бу темага кагылышы булган кешеләр белән фикер алыштым. Интернет киңлекләрендә көннән-көн куркыныч күренеш ала барган төркемнәр турында сөйлиләр. Ул чыннан да шундый ук дәһшәтлеме? Ерактан торып, экран аша кыз һәм малайларыбызны соңгы адымга барырга ничек этәрә икән алар? Хәзер бала-чага кул сузымында гына торган, гел янында булган әти-әнисенең сүзен дә бер әйтүдән генә тыңламый. Ә бәлкем, ул төркемнәр суицид турында уйлап йөргән сабыйга юл күрсәтүчеләрдер. Үз-үзенә кул салучы яшүсмерләр моңа кадәр дә бар иде бит... Дөресен әйткәндә, тегеләй уйласаң да, болай уйласаң да җиңел түгел. Сүз бит газиздән-газизләребезнең тормышы турында бара.

Сәбәпләре

Кызганыч, әмма тетрәндергеч андый фактлар белән әледән-әле очрашып торабыз. Саннарга гына күз төшереп алыйк: Татарстан прокуратурасыннан алынган мәгълүматларга караганда, былтыр 13 шундый очрак теркәлгән булса, 2015 елда – 16, 2014 елда – 23, 2013 елда 17 үз-үзенә кул салу очрагы булган. Әйе, узган ел бераз кими төшкән. Ләкин бар бит алар. Соңгы адымга этәрүче сәбәпләрне ачыклавы үзе бер проблема: баланы әтиәнисе аңламый, мәктәптә дә проблема, яшүсмер яшьтәшләре арасында да уртак тел таба алмый яки җавапсыз мәхәббәт... Ныгып җитмәгән бала психикасы өчен шулары да бик җиткән. Мондый чакта каршыңа утыртып, ачыктан-ачык сөйләшсә, «мин сине бик яратам» дип әйтсә дә бит. Юк, ата-ананың моңа вакыты юк. Ул – эштә, ул бит акча эшли. Баласы өчен тырыша. Ә балага, күрәсез, акча кирәкми, якын кешесенең җылы бер сүзенә мохтаҗ, бик мохтаҗ ул. Хәер, ни сөйлим, әти-әниләр беләләр бу хакта. Тик, әйтәм бит, вакытлары гына юк.

Әйткәнебезчә, соңгы вакытларда бу сәбәпләргә тагын да саллырагы, афәтлерәге өстәлде: киберҗинаятьчеләр, төрле төркемнәр... Гәрчә, куертмагыз, балаларга кирәкмәс мәгълүмат кенә бирәсез ише фикерләр чагылып китkәләсә дә, без бу хакта тагын бер кат әти-әниләрнең исләренә төшерергә булдык. Балачага бу хакта бездән башка да бик шәп белә.

Беркөн 3 нче сыйныфта укучы оныгым белән сөйләшәм. «Син бит телевизордан хайваннар дөньясын карарга яратасың, дим. Аңлат әле миңа, китлар, дельфиннардан кай яклары белән аерыла?» «Шуны да белмисеңме? – ди малай, хәйләкәр елмаеп. – Син бит миннән дельфиннар турында сорамыйсың. Сине «зәңгәр кит» кызыксындыра». Һәм ул, мине хәйран калдырып, бу уенның нидән гыйбарәт булуын, нәрсәгә китереп җиткерүен башыннан ахырына чаклы аңлатып бирә. «Ничек уйлыйсың соң: бу нинди уен?» «Әй, – ди ул, кул селтәп, – аны бит аңгыралар уйный, дебиллар, дәү әни». Ул шулай ди. Тик барлык бала да алай уйламый шул. Экспертлар әйтүенчә, республикада интернет белән бәйле үлем-китемнәр әлегә юк. Шуның белән бергә, «төгәлләнмәгән» суицидлар очрагы 60 тан 74 кә җиткән. Ә уенга кереп китмәс борын, тотып-күреп алынган балалар дистәләгән.

Беләгендә – «зәңгәр кит» сурәте

Ул – урта мәктәпнең тәрбия эшләре буенча директор урынбасары. Сөйләменнән үк балалар белән еш аралашканы, мәктәптәге бөтен яңалыклардан хәбәрдар икәнлеге күренеп тора. Шулай булмаса, сиздермичә генә килгән афәтне туктатып кала алган булыр идеме ул?!

– Физкультура дәресе бара, – дип сөйли ул. – Шунда бер малайның беләгенә игътибар иттем. Нәрсәдер ясалган, ерактан ачык күренми. Моны күреп алган иптәшләре шундук малайга: «Җиңеңне төшер...» – дия башладылар. Малай бәдрәфкә чыгып йөгерде. Нык итеп беләген юган, ахрысы. Беләге кызарып чыккан, сурәте тоныкланган. Әмма барыбер күренә.

– Нәрсә бу? – дим.

– Дельфин, – ди.

– Ник алдыйсың, мин китны дельфиннан аера алмыйммы?

– Дельфин инде, балаларны «зәңгәр кит»тан саклаучы дельфин, – ди бу миңа.

– Дәрестән соң алып калдым да, озак итеп сөйләштем малай белән. Барын аңлаттым: бу уенга кереп китсәң, инде бүтән берничек тә чыга алмаячаксың, китеп барганыңны үзең дә сизмәячәксең, – дидем. Ул мине аңлады. Башка мавыкмаска сүз бирде. Без балигъ булмаган балалар белән эшләүче комиссия, полиция хезмәткәрләре белән даими элемтәдә торабыз. Алар педагогларны бу хакта кисәтеп куйганнар иде инде. Без ул чагында әтиәниләр җыелышы җыеп, барын да түкми-чәчми, арттырмый да, киметми дә сөйләгән-аңлаткан идек. Бу хәлдән соң тагын җыелыш җыйдык, тагын балаларга икеләтә



Татарстанда бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Гүзәл УДАЧИНА:

– Балалар өчен интернет беркайчан да куркынычсыз булмады. Соңгы берничә елда хәл тагын да катлаулана гына төште. Чөнки бүген бала-чага челтәрдә үлемгә уен итеп караучы кешеләргә юлыгып тора. Интернет ул – мәгълүмат чараларының күзәтүгә бирелми торган иң катлаулы чыганагы. Роскомнадзор белешмәләре буенча, 9 яшьтән 16 яшькәчә балаларыбызның өчтән икесе интернетта сексуаль характердагы материаллар белән очраша. Моннан тыш, һәр икенче бала челтәрдә җәбер-золымны пропагандалауга корылган мәгълүматка тап була. Ә шуның белән бергә, балаларны зыянлы мәгълүматтан саклауга юнәлтелгән Россия законнары 2012 елда гына гамәлгә керә башлады. Федераль законнарны камилләштерү – озакка сузыла торган гамәл. Шунлыктан, безгә балаларны бу бәладән саклап кала торган республика дәрәҗәсендәге программа кирәк.

Хәзер үз-үзенә кул салуны булдырмый калу өчен, балалар белән ничек сөйләшергә кирәклеге турында методик киңәшләр әзерләнә. Яшүсмерләрне зыянлы мәгълүматтан саклауга юнәлдерелгән законнар федераль законнар белән чикләнгән. Башкача әйткәндә, төбәкләрнең өстәмә норматив-хокукый актлар кабул итәргә хокукы юк. Без исә уяу булырга, тискәре мәгълүматка шундук чик куярга тиешбез дип саныйм. Бала белән сөйләшкәндә һәр сүз уйланган булсын. Уйлап сөйләшик. Кайбер нәрсәләр хакында алар бездән күбрәк хәбәрдар. Һәм, әлбәттә инде, һәрдаим элемтәдә торырга: аларның интернет челтәрендәге куркынычсызлыгын тәэмин итәргә, стресска каршы торучанлыгын булдырырга, киеренке, авыр тоелган халәтеннән чыгуның уңай юлларын табарга өйрәтергә тиешбез. Билгеле инде, яшүсмер белән «суицид кылырга ярамый», дип сөйләшергә кирәкми. Методик рекомендацияләр махсус шуның өчен әзерләнә дә... Ул кулланмада үз-үзенә кул салуга кызыксыну уята торган түгел, ә аны булдырмый калуга юнәлдерелгән киңәшләр урын алачак.

Бала югалту – зур фаҗига. Бигрәк тә шушындый юл белән... Мондый хәлләргә барып җитмәс өчен кайчак ата-аналарга балалары белән ачыктан-ачык сөйләшү дә җитә. Мөнәсәбәтләр әйбәт, җылы булганда, баланың башына суицид уе керми дә.

PRESSA.RU

игътибарлы булырга чакырдык. Аз гына ишарә булдымы, безгә хәбәр итегез, дип үтендек. Әтиләр – малайлар белән, әниләр кызлар белән мунча керегез, балагызның тәнендә сызыклар юкмы, сиздермичә генә тикшерегез, дидек. Ә укучыларга: «Чын иптәш икәнсез, дустыгыздагы үзгәрешләрне күрә калсагыз, шундук әйтегез. Чөнки ул уенның ахыры – үлем», – дидек. Шуннан китте шалтыратулар, шалтыратып кына калмыйлар, өемә киләләр, шикләрен белдерәләр, запискалар бирәләр. Шулай итеп, һәр баланы дисәм дә арттыру булмас, күзәтү астына алдык. Ул төркемнәргә бик җитди карыйбыз. Һәркайсыбызга тигез кагыла торган зур бәла бит ул. Хәзер мәктәптә тәрбия эшләре, төрле түгәрәк эшчәнлекләре икеләтә активлашып китте. Бала азга гына да күз уңыннан ычкынырга тиеш түгел. Әти-әнинең дә, укытучының да...

Ата-ана баласының нинди социаль төркемнәрдә «утыруын» белергә тиеш.

Директор урынбасары үзенең яшүсмер яшәгән өйдә еш булуын, әтисенең бу проблемага аеруча җитди каравын сөйләп ала. «Бервакыт килеп кердем, әти кеше карават астыннан килеп чыкмасынмы... «Нишлисез анда?» – дип сорыйм. «Рәсемнәр эзлим, яшереп куймадымы икән», – ди. Йөзе шундый борчулы. Шулай эшләгәндә генә була ул».

Психолог та яшүсмернең афәтле ул төркемнәрнең бөтен адымнарын белүе, үзен һаман «мин – зәңгәр китларга каршы көрәшүче» дип аңлатырга тырышуы хакында сөйли.

– Алдый торган гадәте бар. «Әгәр куркыныч эш эшләргә кушсалар?» – дигән сорауны да биреп карадым. «Юк, – ди, – мин бит инде зур малай, аны гына аңлыйм». Әйе, ул зур малай. Мәктәптә әйбәт укый, дуслары да күп, тиз аралашучан да. Минем белән дә рәхәтләнеп, ачылып китеп сөйләште. Әмма алдашуы йөзенә чыккан. Димәк, балага күзәтү, катгый күзәтү кирәк. Гадәттә, ата-ана тәрбия мәсьәләсендә бөтен җаваплылыкны педагоглар өстенә аудара. Бары бергәләшеп алынганда, бер фикердә торганда гына хәл ителә торган җитдидәнҗитди проблема бу.

Бу уңайдан районда зур җыелыш уздырганнар. Видеороликлар күрсәткәннәр. «Летай» фирмасы вәкилләре телефонга белдерү куюу, әгәр дә балага хәтәр хәбәр килеп ирешсә, ул хәбәр әти-әни телефонына да килеп эләгү мөмкинлеге турында сөйләгәннәр. Конкрет очракка менә шундый конкрет эшләр...

Котыртучыларга – җәза!

«Хакерлар! Сезгә үтенеч белән мөрәҗәгать итәм! Сез бит барысын да җимерә аласыз. Җимерегез, ватыгыз әле шул «зәңгәр кит» уенын. Юкка чыгарыгыз, бетерегез! Балалар үлә бит». Интернет аша яңгыраган бу сүзләр хакерларга гына кагылмый. Биредә глобаль масштабтагы чишелеш кирәк. Ни өчен әлегәчә балаларны «космоска китәргә» котыртучылар җәзасыз кала бирә? Ил буенча алганда, аларның саны 130 дан артып киткән, дип күрсәтелә. Ә бәлкем, бу сан хәзер арткандыр да. Балаларны суицидка җиткерә торган төркемнәр турында сүз йөри башлагач, Россия Федерациясенең Тикшерү комитеты регионнардагы Тикшерү комитетларыннан шундый факт буенча кузгатылган җинаять эшләре турында белешмәләр җыя башлады. 2016 елның ноябрендә ул төркем администраторларының берсе – Филипп Лис (Будейкин) кулга алынды. Ун регионда эзләнүләр үткәрелде, тикшерү өчен кирәкле мәгълүматлар алынды. Шуңа да карамастан, балаларны ябык төркемнәргә чакырулар – психологик басымнар дәвам итә. Ни өчен диярсез? Чөнки безнең илдә кичекмәстән ярдәмгә килергә әзер торучы махсус оешмалар, кризис хезмәте юк. Җәмгыятебез дә, хокук саклау органнары да фаҗигане туктатып калуга юнәлтелгән хәлиткеч чаралар кабул итә алмый. Сәбәбе: төбәкләрдәге закон чыгаручыларның яшүсмерне зарарлы мәгълүматтан саклардай өстәмә норматив-хокукый актлар кабул итәргә хокукы юк. Ягъни мөмкинлекләре дә, вәкаләтләре дә юк моның өчен. Күз алдына китерегез әле: без законнар чикләнгән дип сөйләнгән бер мәлдә, төркем тырнагына эләккән бала, лезвие алып, кулына «зәңгәр кит» сызгалап ята. Ул инде мөстәкыйль рәвештә, үзе генә бу уеннан ычкынып китә алмый.

Ул төркемнәрнең кураторлары үзләрен иркен тота, бернидән курыкмый. «Безне беркем дә тота алмый», – ди алар. Кылган җинаятьләрен: «Интернет аша да тәэсир итеп була торган ул малай-шалайлар үләргә тиеш. Ницше ни дип әйткән? Егыла башлаган кешене төртеп төшерергә, дигән. Тотрыксыз психикалы ул түбән катлауны юк иткәннән җәмгыятькә файда гына бит. Ә безгә – акча», – дип аңлаталар. Куркыныч булып китә. Ничек инде бу хәлләрдән соң да ул төркемнәргә җитди карамаска? Алар бар, алар янәшәдә, без уйлаганнан да якындарак.

Балалары һәлак булган ата-аналарның, РФ Тикшерү комитеты башлыгы Александр Бастрыкин янына килеп, Россия законнарын, төгәлрәге, РФ Җинаятьләр кодексының «Үз-үзен үтерүгә илтеп җиткерү турында»гы 110 нчы маддәсен камилләштерү турында тәкъдим белән чыгулары бөтен җәмәгатьчелекне аякка бастырган иде. Илнең югары җитәкчелегенә, абруйлы органнар вәкилләренә бу проблемага каршы торырдай чаралар кирәклеге турында мөрәҗәгать әзерләргә, дигән карарга да киленгән иде. Сөйләшүдән соң ун айлап вакыт узып киткән, ә нәтиҗәсе күренми. Күрәсең, моннан башка да җитди проблемалар җитәрлек дип уйлыйлар. Ә балалар көтеп тормый, алар китә тора.
Иң яхшылары, иң уңышлылары...

Былтыр җәй ахырларында Волгоградта яшәүче 16 яшьлек яшүсмер биек йорттан ташланып харап була. Мәктәптә иң яхшы укучы малай, бию белән шөгыльләнгән. Әтиәнисеннән укырга керү өчен кирәк-

ле фәннән репетитор сораган. Ул үләргә җыенмаган, киләчәк турында кайгырткан. Һәм кинәттән менә шундый фаҗига... Әнисе баласының бер генә минутка да телефоннан аерылмавын, аны гел кесәсендә йөртүен, әйтерсең, кемнәндер ниндидер хәбәр көтүен сөйли. Фаҗига буласы кичтә аны алыштырып куйгандай була. «Кулында – телефон, башы аска иелгән. Сөйләшми дә, – дип сөйли соңыннан әтисе. – Сиңа ни булды, улым, дим. Дәшми генә кереп китте». Ходаем кичер, үзләрен Бөек итеп хис иткән ул психопатлар: «Соңгы биремне үтәмәсәң, әти-әниеңне, туганнарыңны юк итәбез. Без бит синең кайда торганыңны беләбез», – дип куркыталар. Әлбәттә, алар яный гына, эшли алмый. Ә бала моны белми...

Татарстан прокуратурасы массакүләм суицид турында хәбәр тарату буенча тикшерүләр башлап җибәрде. Татарстан прокуроры Илдус Нәфыйковның билгеләп үтүенчә, бу гамәл гәрчә бик катлаулы булса да, әлеге вазгыятьтә бөтен игътибар киберҗинаятьчеләргә карата РФ Җинаятьләр кодексының «Үз-үзен үтерүгә илтеп җиткерү турында»гы 110 нчы маддәсен куллануга юнәлтеләчәк. Дөрес, бу җиңел эш түгел. Әлегә ул төркемнәрне оештыручыларга бары тик административ җаваплылык кына яный. «Роскомнадзор эшләми. бөтен серверны ябарга кирәк», – диде прокурор Татарстан Президенты белән очрашуда.

Балалар иминлеге проблемасы берәүне дә битараф калдыра алмый. Хәзер аны хәл итүгә министрлык, төрле ведомство һәм җәмәгать оешмалары вәкилләре алынды. «Бу хәлдән 110 нчы маддәне яңартып кабул итү генә коткарып кала ала. Без инде күптән шундый башлангыч белән чыккан идек», – ди Халык фронты бүлекчәсе вәкилләре. Моннан тыш, социаль челтәрдә теркәлүләрне мәҗбүри итәргә кирәклеге турында да сүз бара.

Апрель башларында булган журналистлар белән очрашуда Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары Лариса Сулима: «Ата-аналар балаларының интернетта нинди социаль төркемнәрдә булуын күзәтеп торырга тиеш», – дип билгеләп үтте. Бигрәк тә имтиханнарга әзерләнгәндә, баланы куркыту, күңелендә төрле уйлар уяту ярамавын кисәтте. Уку йортын сайлаганда ата-ана тарафыннан басым ясалмаска, «Син укырга шунда гына барасың», дигән таләп куелмаска тиеш. «Әгәр дә бала психологик яктан йомшак икән, психологка мөрәҗәгать итәргә кирәк», – диде ул. Килешәбез: ата-аналар балаларының мәктәптәге хәлләре, яшьтәшләре белән мөнәсәбәтләре турында иплəп кенә сораштырып, басым ясамыйча гына, кызыксынып торырга тиешләр. Чыннан да, «Карама, катнашма, ярамый!» дип торганда, балада, киресенчә, кызыксыну уанырга мөмкин. «Кызганыч, психикага начар тәэсир итә торган компьютер уеннарын чыгаручыларга закон тарафыннан җәза каралмаган», – диде министр урынбасары.

Хәл, чыннан да, катлаулы. Социаль челтәрләрдә балаларга төрле «шартлаткычлар» куела: «Кем кыюрак? Кем тәвәккәлрәк? Уенны дәвам итмәсәң, якыннарыңа, туганнарыңа начар булачак». Һәм башкалар, һәм башкалар. Ул адәм актыклары малай һәм кызларның яртысыннан күбрәгенең хыялдагы дөньяда яшәвеннән файдалана. Балада тормышка, чынбарлыкка кызыксыну сүнмәскә тиеш. Ул янәшәсендә якыннары, дуслары барлыгын һәрдаим тоеп торсын.

Уеннан уймак китереп чыгара торган интернет-фаҗигаләрдән чыгу юлын безгә бергәләшеп уйларга, масштаблы чаралар күрергә кирәктер. Әгәр дә җәмгыятебезне таркатуга юнәлдерелгән мондый уеннар бала-чагага, тормышына зыян сала икән, нигә ул социаль челтәрне юк итмәскә?! Бары да үзебездән тора ич! Баланың җан авазы һәркайсыбызга барып ирешсен өчен тагын нинди мисаллар кирәк безгә?! Көнбатыш илләрендә моның ише хәлләргә юл инде күптән бикле бит. Әйткәнемчә, глобаль челтәрдәге җинаятьләргә глобаль җәза кирәклеге күз алдында.



«Сердәш» психология-педагогика хезмәте җитәкчесе Наталья САБИРОВА:

– Матбугаттагы мәгълүматлар тәэсир иттеме, әти-әниләр үзләре сизгерлек күрсәтә башладымы, соңгы вакытта безгә әлеге проблема белән мөрәҗәгать итүчеләр күбәеп китте. Кайбер ата-ана: «Барысы да тәртиптә сыман. Бала бездән берни яшерми, – дип, – ул-бу була калса нишләргә?» – дип, алдан кайгыртып килә. Без аларны тынычландырабыз. «Балагыз барын да сөйли икән, димәк, ул сездән алга таба да берни яшермәячәк», – дибез. Чыны шулай.

Баланың да төрлесе бар: кайсылары күргән-белгәнен якын кешесе белән уртаклашырга ашкынып тормый. Ул барын эченә җыя, үзенә йомыла, сөйләшмәс була. Мондый уенга тартылган яшүсмерне, игътибарлы булсагыз, шундук күреп алырга мөмкин: ул йә гел йоклый, йә киресенчә, йокысызлыктан тилмерә. Ашаудан кала, йә киресенчә, аның аппетиты кискен күтәрелә. Ул агрессив, тиз кабынып китүчән, баланың социаль челтәрдәге битендә депрессив музыка яисә ул сәер рәсемнәр белән кызыксына. Аның нык ябыгырга теләвенә, кофе белән артык мавыгуына, бик иртә торуына, язышкан вакытта гадәти булмаган сленг куллануына, үлем турында төрле шигырьләрдән цитаталар куюына, медуза, мәче, китлар, күбәләкләр кебек символларга, түбәдән төшерелгән фотосурәтләргә игътибар итегез!

Балагызны бүлдермичә тыңлагыз! Ә үзегез артык сүз сөйләмәгез, кирәкмәс мәгълүмат биреп куюыгыз бар.

Әгәр дә балада ныклы, тотрыклы психика икән, гаиләдә барысы да әйбәт, тыныч икән, бер-берсенә карата ярату, кайгырту сизелеп тора икән, ул беркайчан да дус-ишләренең шикле төркемнәрдә уйнарга кыставына бирелмәс. Кирәкми аңа андый уеннар. Аның үзен саклау инстинкты яхшы эшли. Ә инде бала үзе теләп үзенә авырлык китерерлек гамәлләр кыла икән, димәк, аның җанын авырту-сызланулар биләп алган. Һәм аны ишетүче, аның, ул уйлаганча, олы хәсрәтен күрүче кеше дә юк. Ә ул «олы хәсрәт» кайчагында бөтенләй пүчтәк кенә нәрсә булып чыгарга да мөмкин.

PRESSA.RU





Фото: Ксения Богданова

ЧИСТА СУ – ТОРМЫШ УЛ...



Фәнзилә
МОСТАФИНА

СУНЫҢ КАДЕРЕН БЕЛӘ БАШЛАУ ӨЧЕН ТҮБӘН КАМАГА БАРЫП КАЙТЫРГА КИРӘК БУЛГАН ИКӘН. АНЫ НИЧЕК ЧИСТАРТУЛАРЫН ҮЗ КҮЗЛӘРЕБЕЗ БЕЛӘН КҮРЕРГӘ.

Шәһәр йортларыннан бер читтәрәк торган мәгърур да, шул ук вакытта бераз куркыныч та, күккә ашкан торбаларыннан көне-төне төтен бөркеп торган заводны моңарчы үтеп китешли генә күреп калган бар иде. Ә бүген шуңа таба төбәп барабыз – «Түбән Кама Нефтехим» акционерлык җәмгыятенә. Дөресрәге, аның фәнни-технологик үзәгенә, тагын да төгәлрәк итеп әйтсәк, агымсулар лабораториясенә. Кызык инде: каучук, пластик, гликоль кебек 120 төрдән артык химик продукт җитештерә торган компаниягә чиста су турында сөйләшергә барабыз бит. Мантыйкка сыймый кебек. Тик лабораториягә үтеп, аның эш алымнары белән танышкач, барысы да үз урынына утыра.



Лаборатория – һәрвакыт алда

Ишек төбендә җәмгыятьнең берләштерелгән профсоюз комитетының хезмәт буенча техник инспекторы Андрей Геннадий улы Кузнецов каршы ала. Безне ул озатып йөриячәк. Бергәләп «Түбән Кама Нефтехим» акционерлык җәмгыятенең фәнни-технологик үзәге бинасына атлыйбыз. Совет заманында төзелгән бина бу. Яңартылган, төзекләндерелгән, әлбәттә. Ләкин диварларына шул заманның романтикасы сеңеп калган.

«Узган ел шәһәрнең 50 еллыгын билгеләп үткән булсак, быел – компаниянең юбилее», – ди Андрей әфәнде. Аннары сүзне без барасы лабораториягә борып җибәрә: «Башта биологик чистарту корылмалары эшләтеп җибәрелгән, аның артыннан ук – лаборатория, аннары гына – заводлар. Лаборатория – гаскәрнең алгы сафында баручы сугышчы кебек ул, бөтен нәрсә башта аның җилкәсенә төшә».

Менә ул – агымсулар лабораториясе. Пробиркада ничек итеп яңа микроорганизмнар – тест-объектлар үрчеткәнне күзәткәнче, башта җитәкче бүлмәсенә керәбез әле. Гүзәл Ванур кызы Гыйлаевадан лабораториянең эшчәнлеге турында сорашырга. Һәм ул тәмләп үз эше турында сөйләргә керешә.

Агымсулар лабораториясенең тикшеренү лабораториясе дигән өстәмәсе дә бар. Моны ишектәге элмә тактадан ук күреп алган идек инде. Хәзер Гүзәл ханым шуңа ачыклык кертә: «Без суны анализлау һәм аның сыйфатына бәя бирү белән генә шөгыльләнеп калмыйбыз, агымсуның сыйфатын яхшырту өчен төрле технологияләр, методикалар уйлап табуга юнәлтелгән тикшеренүләр дә үткәрәбез».

Билгеле булганча, нефть химиясе сәнәгатендә бик күп су тотыла. Мәсәлән, заводлардагы реакторларда температура 600 градуска кадәр җитәргә мөмкин. Җиһазларны су ярдәмендә суыталар. Технологик процесста да су пары кулланыла. Суны исә Камадан алалар. Җитештерүдә кулланылган су, әлбәттә, химикатлар белән пычрана. Ә бит аны кире чыганагына кайтарырга да кирәк! Югыйсә Камада су калмас иде. Агымсулар лабораториясе беренче чиратта менә шул кулланылган суны чистарту процессын камилләштерү белән шөгыльләнә дә инде.

Түбән Камада җитештерү предприятиеләре күп. Аларның күбесе кулланылган суны, башта үзләренең локаль чистарту корылмалары аша уздыргач, «Нефтехим»ның химик пычранган канализация системасына, аннан инде үзәк коллектор буенча биологик чистарту корылмасына (БОС) коя. Шунда ук бөтен шәһәрнең хуҗалыкта кулланган суы да төшә. Әлеге чистарту корылмаларында узган ел үзгәртеп кору эшләре башланган

> *Су янәдән Камага әйләнеп «кайтканчы» бигрәк катлаулы юл үтә икән.*

һәм ул берничә этапта алып барыла. Анда агымсулар лабораториясе коллективы да актив катнаша. Алар суны чистарту технологиясен камилләштерү белән бергә, бу вакытта атмосферага чыга торган яман исне бетерү буенча да эшлиләр.

Гүзәл Ванур кызы су турында да, аны ничек итеп чистартулары хакында да сәгатьләр буе сөйли ала. Тик йөз тапкыр ишеткәнче, бер тапкыр үз күзләрең белән күрү бөтенләй башка нәрсә бит инде. Сүзсез дә аңлый безне Гүзәл ха-

PRESSA.RU





Үзе бер кызыклы дөнья икән бу!

ным: «Туктале, сезгә моның атмосферасын тоярга кирәк», – дип куя. Безнең күзләр очкынлана. Тиз арада җыенып, бөтен шәһәрнең суы чистартыла торган җиргә – биологик чистарту корылмасына чыгып китәбез.

Эчә торган судан да чистарак

Чистарту корылмасы дигәне үзе бер завод кадәрле икән. Аңлашыла да, суны иләк аша гына сөзмиләр бит, әллә нинди катлаулы фильтрлар аша уздыралар. Цех җитәкчесе урынбасары Сергей Николаев аңлата: әнә теге чокырга бөтен шәһәрнең һәм предприятиеләрнең кулланылган сулары коя, аннан ул шушы фильтр аша үткәрелә – анда каты матдәләрдән арына, аннары ком фильтры аша уза, аннары менә бу цистернага төшә...

Биологик чистарту исә актив ләмдә яшәүче микроорганизмнар ярдәмендә башкарыла. О, монысы Гүзәл Ванур кызының яраткан темасы! Укытучы үз укучылары турында ничек яратып сөйләсә, Гүзәл ханым да шулай: микроорганизмнар аның өчен «балалар» инде ул. «Микроорганизмнарга яшәү өчен җиңел үзләштерелә торган туклыклы матдәләр кирәк. Химкомбинаттан кергән су органик матдәләргә бай була, аларга микроорганизмнарның теше үтми.
Ә хуҗалыкта файдаланылган су алар өчен тәмлүшкә кебек. Пычрак суны гына биреп торсак, микроорганизмнар бик ачулы булыр иде. Шуңа күрә хуҗалык суы белән катнаштырабыз. Шулай эшләгәч, су составында зарарлы матдәләр нәкъ микроорганизмнар ярата торган күләмдә килеп чыга», – ди Гүзәл Гыйлаева. Химия дәресләрен дә шулай тәмле итеп аңлатсалармы...

Актив ләм 20–22 тәүлек яши. Шуңа да аларны гел яңартып, ягъни микроорганизмнар җибәреп торырга кирәк. Нәкъ менә лабораториядә актив ләмдәге микроорганизмнарның «тормыш- көнкүреше» күзәтеп торалар. Аның физик-механик үзенчәлекләрен һәм анда яшәүчеләрнең тышкы халәтен билгелиләр икән. Без кергән лабораториядә берничә пробирка үз көенә әйләнгәләп утыра иде. «Нәрсә болгатасыз монда?» – дип кызыксындык. «Микроорганизмнарны күзәтәбез», – дип, серле генә елмайды лаборант кызлар.

Микроорганизмнар чистарткан судан актив ләмне аерып алу стадиясе башлана. Актив ләм төпкә утыра, ә чистартылган су өстәмә рәвештә төрле вируслардан зарарсызландырыла, составында хлор булган реагент белән дезинфекцияләнә. Булды, чистарту процессы тәмам. Хәзер инде чистартылган суны кире Камага коялар. «Балыклар – кешеләрдән дә нәзберегрәк җан ияләре. Шуңа күрә аларга дигән су без эчә торганыннан да чистарак булырга тиеш. Менә шундый су коябыз да инде без», – ди Сергей Николаев, безне озатканда. Алар чистарткан су Каманың түбән өлешенә – Кама Аланы, Чистай якларына коя.

Яңа ачышлар башында

Яңадан агымсулар лабораториясенә кайтабыз. Суның ничек чистартылганын күрдек, тагын бер әйберне беләсебез калды бит әле. Лаборатория тикшеренү эшләре белән дә шөгыльләнә, дигәннәр иде, анысы нидән гыйбарәт икән? Гомумән, биредә гадәти эш көне ничек уза? Гүзәл Ванур кызы сөйли: «Гадәттә, без нинди дә булса завод-идарәләрнең баш инженерыннан телефонограмма



■ «Нефтехим» ААҖнең фәнни-технологик үзәге 1966 елда сафка баса. Аның составында 12 фәнни-тикшерену лабораториясе һәм тәҗрибә-сынау цехы бар. Үзәктә барлыгы 277 кеше хезмәт куя. Аларның 150 се – югары квалификацияле инженер-техник белгечләр, 23 е – фән кандидатлары һәм берсе – фән докторы.

■ «Түбән Кама Нефтехим» фәнни-технологик үзәге Россия һәм чит илләрнең фәнни-тикшеренү институтлары белән тыгыз элемтәдә тора. Алар халыкара фәнни конференцияләрдә катнаша. Шулай ук үзәкнең үзендә дә уздырыла алар. Узган елгысында, мәсәлән, Казан федераль университетыннан, Россиянең һәм Татарстанның Фәннәр академияләреннән, ФГУП «НИИСК», «ВНИПИнефть» ААҖ, «ВНИИУС» ААҖ, Россия Фәннәр Академиясе Себер бүлекчәсенең Г. К. Боресков исемендәге катализ институтыннан, шулай ук «LyondellBasell» (Италия), «ExxonMobil» (АКШ), «ThyssenKrupp» (Германия), ПАО «СИБУР Холдинг», «3М Россия», «TOYO» (Япония), «Linde AG» (Германия), «Clariant Россия», «Lummus Technology/CB&I» (АКШ) кебек чит ил оешмаларыннан да белгечләр килде.

яки шалтырату кабул итәбез. «Эштә бер проблема килеп чыкты бит әле», – ди ул. Проблема дигәне, суның сыйфатын яхшырту өчен менә болай эшләп карасак ничек булыр икән, диюе дә булырга мөмкин. Киңәш соравы ягъни. Шуннан без үзебезнең инженер-технологлар белән җыелышып сөйләшәбез. Алар производствоның технологик процессын әйбәт белергә тиеш. Әлеге сөйләшү барышында проблемадан чыгу юлы эзләнә».

Проблема дигәннән, кайвакыт суны биохимик ысул белән чистарту барышында параметрлардан тайпылыш күзәтелә икән. Әйтик, бактерияләр саны кисәк кими. Лабораториядә эшләүчеләр аның сәбәпләрен ачыкларга керешә: ни рәвешле кимегән? Яки тагын бер проблема – чистарту корылмасына суның кисәк агып төшүе. Монысына матдәләр концентрациясе үзгәрү сәбәпче булырга мөмкин икән. Тагын тикшерәләр, өйрәнәләр һәм проблемадан чыгу юлын күрсәтәләр. Кыскасы, суны һәрдаим тикшереп торырга, чистарту корылмаларының эшчәнлеген дә күзәтеп барырга кирәк. Гадәттән тыш хәл була калса, кичекмәстән чарасын күрергә.

Сөенече белән дә уртаклашты әле Гүзәл Ванур кызы. Анысы биотехнологик процесслар белән бәйле. Изопрен ясауда (монысы каучук җитештерүдә бик кирәкле чимал) файдаланылган суны чистарта торган ысул уйлап тапканнар. Аның асылы менә нидән гыйбарәт. Изопрен җитештерү вакытында кулланылган суны чистарту буенча биотехнологик тикшеренүләр өчен перспективалы объект (ягъни актив ләмдә яши торган микроорганизм) табу максатында, лаборатория белгечләре Россиянең төрдәш предприятиеләрендәге биологик чистарту корылмасыннан актив ләм алып кайта. Нәтиҗәдә, бик нык пычранган агымсуны чистарта ала торганы табыла. Бу организмнар заводларның үтә дә зарарлы компонентлары белән «туклана». Дөрес, әле тикшеренү-эзләнү эшләре башланган гына, шулай да бу юнәлештә биотехнологиянең киләчәге якты дияргә була.

Гомумән, лабораториядә суны тикшерә торган 200 ләп методика бар. Анда эшләүче белгечләр һаман да эзләнүдә, яңа технологияләр уйлап табып торалар.

«ТАИФ» белән «ТАНЕКО» акционерлык җәмгыятьләре төзелгәч, алар суны мембраналы чистарту технологиясен сайлап алды. Бик югары дәрәҗәле технология ул. Безнең җитәкчелек тә, әллә без дә шуңа күчикме икән, дип уйлана

Көн саен шушы дөньяда кайнагач, аларга гадәти күренеш кебек инде, ә безгә барысын да төртеп аңлатырга кирәк.

башлады. Мин моның кирәксез эш икәнен аңлатуга ярты елымны сарыф иттем. Җитәкчелек тә мине аңлады», – ди Гүзәл Ванур кызы. Менә хәзер өч технологиянең берсен сайлап алырга кушылган аңа – шуны өйрәнеп утыруы.

Лабораторияләрдә татарча да, русча да төрле плакатлар эленгән. Барысы да су турында. Арада берсе аеруча игътибарны җәлеп итә. «Фәкать чиста суда гына тормыш бар», – дип язылган анда. «Без менә шушы девиз белән яшибез инде», – дип елмая агымсулар лабораториясе җитәкчесе Гүзәл Гыйлаева.

PRESSA.RU

БАЛАМ НИНДИ – КҮРЕГЕЗ!

КЫЗЫБЫЗГА КЫРЫК КӨН ТУЛГАНЫН ТҮЗЕМСЕЗЛӘНЕП КӨТТЕМ. ЯНӘСЕ, КЫРЫК КӨНЛЕК БУЛМЫЙЧА, ЯТ КҮЗЛӘРГӘ КҮРСӘТЕРГӘ ЯРАМЫЙ БИТ ИНДЕ...

Билгеләнгән көн узып китүе булды, шундук берничә фотосын социаль челтәргә элдем. Кызымның матурлыгын күрүдән мәхрүм калалар бит!
Мондый матурлыкны, мондый кызыкны гомердә күргәннәре юк!



Сөмбел
ГАФФАРОВА



Соцчелтәргә яңа фотоларны түгел, моннан берничә атна төшерелгәннәрен куям. Шулай эшләсәң, күз тимәс дип уйлап чыгардым да, фотолар тезә башладым. Берзаман куркып та калдым – фотолар куеп хата ясамыйммы? Тагын бер тынычлану юлы таптым – йөзенә йә зәңгәр күз, йә яхшы сүз ябыштыра башладым. Алай да дөрес түгел дип үртәлдем, әлбәттә, ләкин ташып торган бәхет белән уртаклашмасам, шартлар идем, билләһи...

Шулай да, социаль челтәрдәге сәхифәләрен бала сурәтләре белән тутыручы шашканнар рәтенә керү дәрәҗәсенә җитмәдем бугай. Балалы альбомга «йозак» та астым – туганнар, дус-ишләр генә соклана ала хәзер.

Башкалар бер дә пошынмады бугай. Әллә пошындымы? Карасам, бер танышым бала альбомын юк итте. Икенчесе бөтенләй куймый, ә күрәсе килә... Нишләп алай итә икән? Өченчесе...

Әйдә, турыдан сорыйм әле үзләреннән: бала сурәтен интернетка кую дөресме?



Гөлназ Фәйзрахманова, «Болгар радиосы» алып баручысы

Кеше таный мине, моның үз җаваплылыгы бар. Социаль челтәргә балаларның фотосын куюга мин каршы. Беренчедән, алар минем иң кадерле кешеләрем, аларга чит күзләрнең яратып та, яратмыйча да, сокланып та, сокланмыйча да каравын теләмим. Дөньяда төрле кеше бар, алар арасында яман күзлеләре дә... Балаларның мең дә бер төрле кыланууларын, уңышларын чагылдырган фотоларын гаиләбез, якын дусларыбыз белән генә карыйбыз. Мин, җыеп-җыеп булса да, фотоларны ясатып алып, альбомнарга тезәм. Ул альбомны актарырга яратабыз.

Динебездә фотоларны куярга ярыймы, ярамыймы дигән сорауга җавап төрле. Элек «ярамый» дисәләр, хәзер «аралашу чарасы буларак кулланыла ала» диелә. Шуңа: «Һәркем үзе хәл итә», – дип кенә әйтәсе кала.

Өч-дүрт ел элек бу мәсьәләдә икеләнеп йөргән чагымда телевидениедә алып баручы, мин бик хөрмәт иткән хатын-кыз, яраткан актрисам Юлия Высоцкаяның сүзләре тетрәндерде: «Бәхетеңне яныңдагылар белән генә уртаклаш икән...» (Белгәнебезчә, Юлиянең кызы, әтиләре белән авариягә очрап, өч ел буена комада ята.) Бу вакыйгадан соң күп вакыт үтте инде, Юлия социаль челтәрләргә кабат әйләнеп кайтты. Тик хәзер тапшыруларында да, шәхси битендә дә балаларының фотоларын куймый.



Илшат Рәхимбай, кинорежиссер

Мин ырымнарга ышанмыйм, әмма, нигәдер, балага кагылышлы мәсьәләдә шик-куркудан арынып булмый. Бәлки очраклы гынадыр, әмма фотосын куюга ук – кызыбыз йә авырып китә, йә каты егыла... Моннан болай фотолар куймабыз дип килештек.

Энергия дигән әйберне онытырга ярамый. Аның нинди юллар белән кемгә ничек килеп ирешкәнен ансат кына аңлап бетереп булмый шул. Сакланганны саклармын, дигән бит Ходай Тәгалә.



Галия Хабибрахманова, яшь балаларны төшерүче гаилә фотографы

Фотограф буларак, миңа үз продуктымны рекламалау мөһим. Портфолио туплау турында әйтәм. Фотолар – минем иҗатым, көч сарыф иткән хезмәтем. Клиентым эшемне күреп килә. Рәссамнар да бит картиналарын яшереп ятмый. Күргәзмәләр ясап, киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итә. Балаларның фотосын социаль челтәрләргә урнаштырганчы мин аларның әти-әниләреннән рөхсәт сорыйм. Махсус килешүгә имза куйдырам. Аның нигезендә мин үзем төшергән фотоларны, автор буларак, социаль челтәрләрдә, төрле бәйге-күргәзмәләрдә, матбугат чараларында урнаштырырга хокуклы. Әйтергә кирәк, күп кенә әти-әниләр үз ризалыгын бирә. Яңа туган сабыйлар фотосессиясенә килгәндә дә шулай. Ырым-шырымнарга ышанучылар балага кырык көн тулганнан соң гына урнаштырылуын сорый. Мин моның начар ягын күрмим, чөнки профессиональ фотога сәнгать итеп карыйм. Һәм иҗат җимешемне начар ниятләрдә куллануны күз угында тотмыйм.

Рөхсәтемнән башка фотоларымны кайда да булса урнаштырсалар, ул затларны җавапка тартырга хокукым бар. Авторлык хокукымны дәлилләү өчен һәр фотоның башлангыч вариантын саклап барам. Ә менә телефонга төшерелгән фотоларны социаль челтәрләргә урнаштыруны хупламыйм. Чөнки андый фотолар хуҗасыз санала. Аларны берәрсе файдаланса, берни дә эшли алмыйсың...

Фото: Сәмбел Гаффарова

PRESSA.RU



Аида Сәйдәш, фотограф

Баласы тормышын социаль челтәрләргә чыгару яки чыгармау – һәркемнең үз эше. Бүгенге көндә Insta-әниләр азмы? Бала табу йортыннан алып, сабыйның һәр көнен инстаграмга куеп баралар. Башка әниләргә киңәшләр бирә-бирә, балаларының һәр көнен тасвирлыйлар. Чит илләрдә исә бала туугa барлык туганнарга, дус-ишләргә бу яңалыкны белдертүче фотолар җибәрү гадәти нәрсә.

Кайбер әниләр фотодагы бала йөзен йөрәк яки чәчәк белән каплап котылалар. Ул әниләрне гомумән аңламыйм. Бөтенләй куймаска инде... Үзем күз тиюгә дә, яман һәм яхшы энергия булуга да ышанам. Бер яшькә кадәр сабый үтә нәзберек, һәръяклап саклауга мохтаҗ. Күз карашына каршы тора алмый әле ул. Шуңа күрә балаларымның яше тулмыйча сурәтләрен чыгармадым. Хәятнекен куймыйм, ә Ризаэтдин үсте инде – анынкын куеп була. Әтиебез Тәбрис көн дә улы белән сторис алып бара. Мин моңа каршы тормыйм. Киресенчә, видеокөндәлекләрен зур кызыксыну белән күзәтеп барам.



Алсу Мәҗитова, журналист

Балаларның фотосын интернетка куюга мин каршы түгел. Чамасын белеп кенә. Берничә ел элек мәчеттә балалар тәрбиясенә багышланган бер лекция тыңлаган идем. Анда остаз бик дөрес сүзләр әйтте: ата-ана баладан табына торган идол ясамаска тиеш. Әлбәттә, балаң белән горурланырга, аны мактарга, үсендерергә кирәк, әмма башкалардан моны таләп итәргә ярамый. Ә бүген социаль челтәрләрдә балалар – әти-әнинең амбицияләрен канәгатьләндерү коралына әйләнде сыман. Менә күрегез, минеке укый, ә минеке шигырь сөйли, минеке җырлый, дип ярышуга кайтып кала кебек. Моны минем күңелем кабул итми. Ә күз тия дип, йөзенә стикер ябыштырып куюларны бөтенләй аңламыйм. Яман күздән куркасың икән, бөтенләй куймаска кирәк инде сабыйның фотосын.



Зөлфәт Зиннуров, шоумен

Фотоларны кую яклы түгел мин. Үземнекен бер дә куйганым юк. Күз тиюләргә ышанмасам да, «ә шулай да» дигән шик-шөбһә куркытып тора. Олы кызны, әкренләп, чамасын белеп кенә куя башладым. Кечкенәсен – юк.

Ара-тирә фотоларны челтәрләргә элгәндә дә аста тезелеп киткән пунктлар турында онытмыйм.

- Баланың ялангач төшкән фотосын кую куркыныч. Майка баулары җилкәгә төшеп торган бала сурәте бик самими күренсә дә, акылы чирле кеше аңа башка күзләр белән карарга мөмкин.
- Баланың кайда төшереп алынганын күрсәтмим – балалар бакчасы, бала йөри торган түгәрәк атамасы-геолокацияләрен куярга ярамый. Бу мәгълүмат начар ниятле кешеләргә генә кирәк.
- Хобби, уңышлары турында хәбәрдар кешегә бала белән сөйләшеп китү – менә дигән җай.
- Бала турында рәсми мәгълүмат булган (таныклыкмы, паспортмы ул) документны кулына тоттырып интернетка кую ярамый. Сирәк булса да, андыйлар да очрый...
- Кыйммәтле машина, айфон-айпадлар, бизәнү әйберләре белән фотога төшкән баланың әти-әнисеннән көнләшеп, кемдер җинаятькә бармас дип ышанып буламы?
- Башка балалар белән бергә төшкән фотоны калган ата-аналарның рөхсәтеннән башка интернетка кую яхшы түгел. Башта ризалыкларын алыгыз.

Соңгы арада баланың фотоларын Инстаграмга да, башка социаль челтәрләргә дә куюны киметтем. Үзеннән-үзе шулай килеп чыкты. Якын туганнар гына аралаша торган чатка кочагы-кочагы белән фото-видеоларны җибәрәм. Ахыр чиктә нәкъ шушы кешеләргә генә ихластан кызык инде ул фотолар.

P. S. Балабыз үзе дә әкренләп, телефон төймәсенә басып, фотога төшерергә өйрәнеп килә. Тиздән ул да безне интернетка сала башламасмы? «Сез минекен куйдыгыз әле» дип... «Бала Инстаграмына эләгеп, ничек адәм мәсхәрәсенә калмаска» дигән язма әзерләргә калмагае...

«БЕЗНЕКЕ УЛ — ШУНДЫЙ!»

Көннәрдән бер көнне күптән күрешмәгән, белешмәгән танышым шалтыратты.

Ризидә ГАСЫЙМОВА



– Син һаман да газетада эшлисеңме? – дип сорады ул, бер-беребезне искә төшереп дигәндәй, хәл сорашкач. – Әйдә, минем язмыш турында да язып әле.

– Ә нәрсә булды?

– Ирем кеше белән йөри минем...

– Кем белән? – дип, урынсызрак сорау биреп куйдым мин.

– Бер өстерәлчек инде, кем булсын! Ул бит минем инженер, үзебездә эш булмагач, күрше авылга эшкә урнашкан иде. Эштән гел соңга калып кайта башлады бу. Бер ар хатыны белән чуала башлаган икән.

– Син, бәлки, ялгышасыңдыр? – дип тынычландырмакчы булдым мин аны.

– Телефоныннан «смс»ларын укыдым. Менә атаңның нишләп йөргәнен бел, дип, кызга да укыттым. Кыз да әйткән инде үзенә. Ял көнне машинасы белән автобуска озата киткән иде кызны, юлда елый-елый әйткән әтисенә. Шуннан акылга килерме, дисәм – юк! Миңа әйтә: «Аның янына бармый түзә алмыйм», – ди. Бозган инде ул аны, бозган!

– Хәзер нишләргә уйлыйсың инде? – дип сорадым, ни әйтергә белми аптырап.

– Нишлим? Өй зур. Ул бер бүлмәдә, мин бер бүлмәдә утырабыз шулай.

– Ә... бу турыда газетага язу нигә кирәк соң сиңа?

– Менә минем кебек язмышлы кешеләр дә бар икән, дип, үзенә укытырмын. Только минем исемне куя күрмә, яме. Гөлнара дип куй.

– Гөлнара дип тә куярга була, Миләүшә дип тә, – дидем мин. – Тик... Ачуланма, яме, мин монда газетага язарлык нәрсә күрмим.

– Ничек инде күрмисең? – дип ихлас гаҗәпләнде танышым.

– Ирләре йөргән хатыннар бихисап хәзер.

– ...

– Менә син аны берәр ничек йөрүеннән туктата алсаң һәм шул турыда башкаларга да сөйләргә ниятләсәң, бу турыда язарга булыр иде. Вакыйганың азагы юк бит.

– Ну, алайса, әйдә азагын көтик, – диде танышым төшенке тавыш белән.

– Ә нигә көтәргә соң аны?

– Ә нишләргә соң?

– Уйлап кара, ике арагызны яхшырту өчен син ниләр эшли аласың?

– Безнең мөнәсәбәтләр бик яхшы иде әле арага шул өстерәлчек кергәнче! – дип кызып китте ул тагын. – Бөтен авыл көнләшеп карый иде!

– Син ireңне еш мактыйсыңмы?

– Нәрсә өчен?

– Менә өебез зур, дисең бит, бәлки шуның өчен.

– Һе, без бит аны икебез бергә салдык. Минем көч әз кергән дисеңмени?

– Алай дип әйтмим. Синең үзеңне ireңнән аерым итеп хис иткәнең бармы? Яшь, матур, мөстәкыйль, кызыклы хатын-кыз итеп...

– Мөстәкыйль итеп? – дип кабатлап сорады ул аңламыйча.

– Тыңла әле, мин бит телефоннан сөйләшкәнне газетага мәкалә итеп яза алмыйм. Кызыгызны Чаллыда диган идең бит. Аларга киләсең юкмы соң? Бер очрашып, сөйләшеп утырыр идек.

– И кызый, – диде танышым. – Кая инде Чаллыга баргач синең белән очрашып йөрүләр... Без бит машина белән бер көнгә генә барабыз. Безнеке мине үзеннән бер көнгә дә калдырмый. Безнеке ул – шундый!

Мин, ирексездән, көлеп җибәрдем. Ире турында танышымның шулкадәр якын итеп «безнеке» дип сөйләве күңелне шундук тынычландырды. И-и, бездәге бу ихлас фидакарьлекне, гаилә җанлылыкны ниндидер «күрше авыл хатыннары» гына җиңә алырлыкмыни соң? Юктыр!



Фото интернеттан алынды

PRESSA.RU



«САНДУГАЧ САЙРАР ИЛЕМ»

РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

«ТАТНЕФТЬ»ТӘ БИК ЯХШЫ БЕР ГАДӘТ БАР – АЛАР ҺӘР БАШЛАНГЫЧНЫ ДӘВАМЛЫ ИТӘ БЕЛӘЛӘР. «САНДУГАЧ САЙРАР ИЛЕМ» МЕНӘ ИНДЕ 20 ЕЛ РӘТТӘН ҮТКӘРЕЛӘ.

Күңелендә сәнгатькә мәхәббәт яшәгән кешеләр, урау юллар узып булса да, барыбер сәхнәгә киләләр, ә фестиваль аларга туры юлны ача.

Мәскәүдә Спиваков фонды грантларын тапшыру тантанасы булып узды. Залда РФ Дәүләт Думасы депутатлары да утыра. Һәм кинәт шунда минем колагыма күңелемә бик якын татар көе кагылды... Баянчы Газинур Равилевнең уенын зал ул көнне аягүрә басып алкышлады. Фондның 2017 елгы стипендиатларының берсе ул, ә алар бездә ил буйлап та дүртәү генә! Азнакай егете Газинур кебек талантлы балаларны «Сандугач сайрар илем» фестивале эзләп таба һәм аларны иҗади үстерүгә бәяләп бетергесез зур өлеш кертә. «Татнефть» бу яктан башкаларга үрнәк...

Владимир Спиваков оештырган Халыкара хәйрия фондының Башкортстандагы директоры, дәүләт премияләре лауреаты, Мәскәү филармониясе солисты Артур Назиуллинның сүзләрен тамашачыларның алкышлары бүлә. Хәер, кул чабулар юбилейга дип махсус килгән Артурга гына түгел, әле яңа гына сәхнәдә татар халык көе «Зәлидә»не уйнап кереп киткән Газинурга да бугай.

Егерме ел дәвамында «Сандугач сайрар илем» фестивале сәхнәсе аша узган меңләгән балаларның берсе генә ул Газинур. Фестиваль канат куйган сәләтле яшьләрнең барысын барлый, саный китсәкме?! Татарстанның атказанган артистлары җырчылар Эльмира Кәлимуллина, Айдар Сөләйманов, баянчы Наил Сәгъдиев, Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе доценты Антон Попов, җырчылар Мөнир Рахмаев, Алинә һәм Азат Кәримовлар, музыка, сәнгать мәктәбе директорлары, мәдәният идарәсе җитәкчеләре...













Фестивальне оештыручылар беренче адымнарны ясаганда бу хакта хыяллана алдылармы икән?!

«Рухият» фондының беренче директоры, «Сандугач сайрар илем» фестивалена нигез салучыларның берсе булган Илсөяр Хәйруллинаны тыңлыйк:

– 1997–1998 еллар. Ул чакта илдәге хәлләрне күпләр хәтерлидер. Финанс системасы җимерелде. Акчада девальвация башланды. «Татнефть» хосусыйлаштыру процессларына кереп китте. Нефтьнең бәясе 8 долларга калгач, аны бөлгенлеккә чыгару белән яный башладылар... «Рухият» рухи яңарыш фондын менә шушындый иң авыр вакытта оештырып җибәрде «Татнефть». Бер-ике кешенең теләге белән генә барлыкка килмәде ул. «Татнефть» «ана компания» буларак, үзенең кул астындагы башка структураларны – «Девон-кредит», «Зенит» банклары, «Чулпан» иминият компаниясен, уртак предприятиеләрне җәлеп итеп, бу фондның матди нигезен булдырды. Финанс ягы – бер нәрсә, әле идея ягы, «рухи эчтәлеге» бар бит. Безнең фондның икенче канаты бик нык булып чыкты. Беренчедән, җирле иҗатчылар моңа күптәннән әзер иде. Күңелләреннән «Татнефть» ягыннан бер оешкан ярдәм булса иде, дип теләүчеләр нефть чыккан якларда җитәрлек иде. Аларга драматург Туфан Миңнуллин, композиторлар Мәсгудә Шәмсетдинова, Мирсәет Яруллин, балерина Нинель Юлтыева, режиссер Фәрит Бикчәнтәев кебек сәнгатьнең, мәдәниятнең, әдәбиятның корифейлары – фондны нык, көчле сәнгати нигезгә куючы иҗатчылар төркеме килеп кушылды. Безнең янәшәдә шушындый күренекле шәхесләр булгач, әлбәттә, «Татнефть» җитәкчелеге дә бу эшкә бик җитди карады.

Ныклап уйлаганнан соң бер фикергә килдек: фонд яшь буын өчен хезмәт итәргә тиеш. Анда балаларның рухи дөньяларын матурлаучы, аны тулыландыручы бер



Рөстәм МӨХӘММӘДИЕВ, «Татнефть» акционерлык җәмгыяте генераль директорының урынбасары, «Рухият» фонды советы рәисе, Татарстан Дәүләт Советы депутаты:

– «Рухият»нең юнәлешләре бик күптөрле, әмма арада иң мөһиме – «Сандугач сайрар илем» фестивале. 50 меңнән артык бала катнашты инде анда! Мин белгеч түгел, әмма балалар сәхнәдә профессиональләрдән аерылмый кебек. Чыгышлары да затлы, костюмнары да. Татарстан мәдәният министрлыгына рәхмәт – һәр елны Казанның иң шәп сәхнәләрен бирәләр безгә. Опера һәм балет театрында да, Зур концерт залында да, «Пирамида»да чыгыш ясады безнекеләр. Соңгы елларда Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә килəбез.

PRESSA.RU



**Резеда АХИЯРОВА,
композитор,
Г. Тукай исемендәге
премия лауреаты:**

– Фестиваль гимнының сүзләре Нур Әхмәдиевнеке, ә көе минеке. Рәхәтләнеп яздым мин аны. Һәр концерт ахырында яңгырый ул. 20 ел буе! Бик күп көч салына фестивальгә, «Татнефть» исә аларга бу эштә зур терәк. Сәләтле балалар балкып кабына бирeдә.

юнәлеш булсын дип уйладык. «Сандугач сайрар илем» фестивале шулай барлыкка килде. Исемне аңа Мәсгудә Шәмсетдинова уйлап тапты.

Фестиваль буш җирдә тумады, әлбәттә. Аның нигезе бар иде. Әлмәт сәнгать училищесы директоры, композитор Рәис Нәгыймовның җәмәгате Зәйтүнә ханым әлеге уку йортында инде берничә ел бәйгеләр оештыра иде. Ул безнең белән бик теләп хезмәттәшлек итте. Сәнгать мәктәбенең, балалар иҗат сараеның да үз конкурслары бар иде. Мондый көчләр барында безгә оешып китү күпмедер дәрәҗәдә җиңел булды. Гомумән, белгечләр, ата-аналар, балалар көтеп алган проект булды бу: бөтен нефть районнары бу эшкә дәррәү кушылды. Хәер, заманы да романтиклар заманы иде бит...

Аларга иң беренче көннән үк «Татнефть»нең профсоюз оешмасы бик нык булыша: фестиваль вакытында балалар компаниянең сәламәтләндерү лагерьларенда яшиләр. Аларда исә мастер-класслар үткәрергә дә, сайлап алу турларын уздырырга, Гала-концертка әзерләнү мөмкинлеге дә тудырылган.

Фестивальнең Гала-концерты һәрвакыт ике тапкыр үтә. Беренчесе – Әлмәттә. Гадәттә, бу көнне «Нефтьче» мәдәният сараенда алма төшәр урын булмый. («Сандугач сайрар илем» төбәкара фестивале, гомумән, республикабызның көньяк-көнчыгыш районнары өчен ел саен үтә торган зур бәйрәм ул!) Гала-концертның икенчесе Казанда уза.

– Без ул чакта балалар өчен республикадагы бердәнбер фестиваль идек, – дип дәвам итә Илсөяр Мәсәгутовна. – «Йолдызлык» өч елга соңрак барлыкка килде. Шуңа да «Сандугач сайрар илем»гә игътибар зур булды. Иң беренче концертыбыз ук Г. Камал театры сәхнәсендә узды. Тамашачылар арасында Татарстан Республикасының Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм биш министр да бар иде. Балалар белән Казанга кимендә ике көнгә килә идек: беренче көнне концерт куябыз, икенче кичне аларга М. Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет академия театрында берәр опера яки балет яисә зур концерт күрсәтергә тырыша идек. Әле дә хәтерлим, безнең конкурста Гран-при алган ятим малай Венера Ганиевага чәчәк чыгарды. Аның ничек шатланганын күрсәгез?! Әйтерсең бу минутта ул үзе дә сәхнә кешесенә әверелде... Казанга килү – фестивальдә җиңгән балалар өчен бүләк кебек иде ул. Ата-аналарның барысының да мондый мөмкинлеге юк бит. Музейлар карап йөрү, «Макдоналдс»ка кереп сыйланып чыгу да сөенеч иде балаларга...

– Без беркем белән дә ярышмыйбыз, – ди «Рухият» фондының бүгенге директоры Флюра Мәгъдан кызы Шәйхетдинова. – «Сандугач сайрар илем» фестивале иң беренче чиратта төбәгебездә яшәүче күп милләт вәкилләренең мәдәни тамырларын саклауга игътибар итә.

Әйе, шактый катлаулы проект бу. Бер сәхнәдә эстраданы, халык көйләрен, милли биюләребезне һәм классик әсәрләрне берләштерергә кирәк. Моннан тыш, яшь рәссамнар арасында да бәйге үткәрелә бит әле.

Быелдан башлап фестивальдә яңалык бар: җиңеп чыккан балаларга «Татнефть» акчалата премия бирә башлый. «Нефтьчеләрнең бу проектка мөнәсәбәте шушыннан да күренә, – ди Флюра ханым. – «Иң яхшысы – балаларга» дигән шигарьне ничек бар шулай аңлый һәм гамәлгә ашыра алар». Гран-при алган коллективларның җитәкчеләрен хөрмәтләү дә дөрес адым. «Татнефть» җәмгыятенең генераль директоры урынбасары Рөстәм Мөхәммәдиев кулыннан быел бу бүләкне «Азаль» вокал-хореография ансамбле (Зәй) һәм «Мириданс» халык биюләре ансамбле (Әлмәт) алды.

«Сандугач сайрар илем» фестиваленең Гала-концерты сәхнәсенә «Татнефть» стипендиатлары – нефть төбәгендә туып-үскән студентлар күтәрелү гамәле һәр елны кабатлана. Фестивальнең элеккеге лауреатлары, язмышларын сәнгать белән бәйләгән яшьләр – гел күз уңында. Быел алар унау иделәр. (Фестиваль оешканнан соң, республиканың көньяк-көнчыгыш районнарыннан Казан дәүләт консерваториясенә, Казан, Әлмәт, Түбән Кама музыка көллиятләренә, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетына укырга керүчеләр арта. Күпләргә укырга керү өчен фестиваль юлламаны үзе бирә. Түләп белем алучыларга ярдәм иткән очраклар да бар.)

...Юбилей – үткәнгә карап нәтиҗәләр ясау гына түгел, күбрәк киләчәккә күз ташлау да ул. Шуңа күрә «фестиваль инде ике дистә ел яши», димибез, «Сандугач сайрар илем»гә әле 20 яшь кенә», дибез. Уңышлар аңа!

Гөлнур ХӘСӘНШИНА



**Айдар СӨЛӘЙМАНОВ,
«Төрквидение-2014»
Халыкара бәйгесе лауреаты:**

– Фестиваль республикабызның көньяк-көнчыгыш төбәген берләштереп тора. Аның сәхнәсенә беренче тапкыр күтәрелгәндә Зәй шәһәренең балалар музыка мәктәбе укучысы идем әле. 2005 елда Гран-прига ия булдым. Киләчәгемне иҗат белән бәйләү өчен зур этәргеч булды дип саныйм мин моны. Быел минә беренче тапкыр «Сандугач сайрар илем»гә жюри рәисе булып килдем. Бик зур җаваплылык тоеп эшләдем.



ҖӘМГЫЯТЬ

Казанда Татарстан халыкларының III съезды узды. Съездга Казанда яшәүче милли диаспораларның 200 ләп вәкиле, республика районнарыннан 500 делегат килгән иде. Анда граждannar җәмгыяте институтларының дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлеге, этно-мәдәни үсешнең актуаль мәсьәләләре хакында фикер алыштылар.

Татарстан делегациясе эшлекле визит белән Иранга барды. Әлеге визит нәтиҗәләренә тукталып, Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов: «Машина төзелеше, төзелеш материаллары, авыл хуҗалыгы товарлары, медицина җиһазлары һәм башка барлык юнәлешләр буенча уртак проектларны гамәлгә ашырырга без әзер», – дип белдерде.

Башкаланың Бауман урамында «Георгий тасмасы» акциясе старт алды. 9 Майга кадәр волонтерлар Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын хәтерләтүче 15 мең тасма таратачак. Әлеге акция илнең 85 төбәгендә башланып киткән инде.

МӘДӘНИЯТ

Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенең быелгы лауреатлары билгеле булды. Бу исемгә язучы Мәдинә Маликова, сәнгать белгече Розалина Шаһиева һәм дин әһеле Харис хәзрәт Салихов лаек дип табылды.



Казан Кремле музей-тыюлыгының «Эрмитаж–Казан» үзәгендә Третьяков галереясының «Гений века» күргәзмәсе ачылды. Третьяков музееннан 80 гә якын экспонат килде. Әзерләнгән экспозиция сәнгать киңлекләрендә гүзәллек эзләү тарихы, чорның эстетик идеаллар тарихы турында сөйли. Арада – күргәзмәнең энҗе бөртегенә тиңләнгән «Царевна-Лебедь» (Михаил Врубель) кебек сәнгать әсәрләре дә бар. Третьяков галереясы әсәрләре белән 29 сентябрьгә кадәр танышырга мөмкин.

КОТЛЫЙБЫЗ



«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Сөембикә» журналының җаваплы сәркатибе Лариса Маликовага «Татарстан Республикасы матбугат һәм масса-күләм коммуникацияләренең атказанган хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде. Дәрәҗәле бүләкне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов тапшырды. Котлыйбыз!

СПОРТ

Татарстан җыелма командасының теннис буенча спортчысы Авелина Сәйфетдинова «Tennis Europe-2016» халыкара юниорлар турының «14 яшь һәм аннан кечерәкләр» категориясендә турнирның иң яхшы уенчысы булды. Бүләкне аңа Мәскәүдә Россия теннис федерациясе башлыгы Шамил Тарпищев тапшырды.

Казанда Су спорты төрләре сараенда суга сикерү буенча Россия чемпионаты узды. Ярышта илнең 14 төбәгеннән 160 спортчы көч сынашты. Җиңүчеләр дүрт дисциплина – шәхси, синхрон, катнаш сикерү һәм командалы ярышлар буенча ачыкланды.

Ригада шахмат буенча хатын-кызлар арасында Европа чемпионаты узды. Анда төрле илләрдән 144 шахматчы үзен сынады. Казан шахматчысы, халыкара гроссмейстер Алисә Галләмова бу юлы да сынатмады. Ул бронза медаль яулады.

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ

Бөтендөнья татар конгрессы каршында эшләүче «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасының V җыены булып узды. Быелгы форумга 18 ерак һәм якын чит илдән, Россиянең 65 төбәгеннән, республика районнарыннан 400 дән артык делегат һәм кунаклар җыелды. Делегатлар Арча, Биектау, Балтач, Яшел Үзән районнарында булдылар, андагы «Ак калфак» оешмаларының эшчәнлеге белән таныштылар. Казан Ратушасының Колонналы залында исә «Калфак туе» узды.

Казанда «Туган телем – Тукай теле» дип исемләнгән I Бөтенроссия фестиваль-бәйгесе узды. Катнашучылар вокал, театр сәнгате, әдәби сөйләм осталыгы буенча ярыштылар. Фестивальдә катнашырга теләк белдереп, 700 дән артык кеше гариза тапшырган. Фестиваль Г. Тукайның «Туган тел» шигырен татар, рус, инглиз телендә укып башланды.

Унике ел буена уздырылган «Мин татарча сөйләшәм» акциясе елдан-ел популярлаша бара. Ел башыннан алып акция кысаларында дистәләгән проект тормышка ашырыла. Быел катнашучыларны яшь архитекторлар тарафыннан ясалган 400 килограммлы, 3 метрлы «Ә» хәрефе арт-объекты каршылады.

PRESSA.RU



Фәрит Хәйрулла улы МӨХӘММӘТШИН – Татарстан Республикасының соңгы биш чакырылыш (1998 елның маеннан – бүгенге көнгә кадәр) Дәүләт Советының алыштыргысыз спикеры – парламент башлыгы. «Бердәм Россия» сәяси партиясенең Татарстан бүлеге сәркатибе. Татарстан халыклары Ассамблеясе советы Рәисе. 2001 елдан алып 2016 елга кадәр Европа Советының Җирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессында Россия Федерациясе делегациясе әгъзасы булып торды, Актуаль мәсьәләләр комитеты рәисе вазыйфасын башкарды. Бу елның 28 мартында Фәрит Мөхәммәтшинның халыкара эшчәнлеген, төбәк дәрәҗәсендәге демократия үсешенә зур өлеш кертүен югары бәяләп, аңа Европа Советы Җирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессының медале тапшырылды һәм аңа Конгресснң шәрәфле әгъзасы дигән дәрәҗәле исем бирелде.



«ЯШӘҮДӘН ЯМЬ ТАБА БЕЛГӘННӘР ОШЫЙ»



ТАМЫРЛАР Әтием Хәйрулла Динкәй улы Бөек Ватан сугышында җиңү яулап кайткан совет солдаты иде. Тыныч тормышта да ул солдат булды, партия кая кушса, шунда барды, «булсын!» дип эшләде, безне дә шул рухта тәрбияләде. Әтием Сарман районында туган, яшьли әтисез калган. Ачлы-туклы яшәсә дә, укырга-язарга иртә өйрәнгән. 10 яшендә ул инде авылдашларына хатлар, башка кирәкле кәгазьләр язып бирә торган булган. Әтием сугышта вакытта әнисе дә вафат була. Шуңа күрә әти сугыштан үзенең фронтташ дусты Юныс Йосыпов йортына кайта. Бераздан ул аның сеңлесенә өйләнеп тә куя.

Әтине үз уллары кебек кабул иткән гаилә – минем Мирзиян бабам белән Вәсилә әбием. Мин – аларның яраткан оныгы идем. Без – Акташта, бабайлар үз йортлары белән Әлмәттә яшәделәр. Каникул җитсә, бөтен бала-чага аларга җыела идек. Зәй елгасында су коенабыз, атлар караган булабыз, печәнгә барабыз. Аллага шөкер, алар озын гомер кичерделәр. Улыбыз Дамир тугач, Мирзиян бабай аңа тиешле догасын үзе укып, исем кушты. Вәсилә әби белән икәүләп килгәннәр иде. Малайга бүләккә шакмаклы күлмәк алганнар.

Әтинең безне тәрбияләп утырырга вакыты да юк иде, ул иртәдән кичкә кадәр эштә булды. Әмма безгә әни әйтә торган бер тылсымлы сүз бар иде: «Әтиегезгә әйтәм!» Мин хәзер шундый фикергә киләм, әнием Мәһинур гомере буе әтинең гаиләдәге абруен күтәреп яшәгән. «Әтиегез кайткач, көндез эшләгән эшләрегез хакында сөйләрсез». «Әтиегез ничек әйтсә, шулай булыр»... Бер әни генә түгел, ул чорларда күпчелек татар хатыннары «ирне ир итеп» яшәделәр, гаиләнең иминлеген, бөтенлеген тәэмин иттеләр. Никадәр авыр эшләр башкарганнар алар: юк әйберне бар итеп ашарга пешер, кер ю, җый, мичкә ягып өй җылыт, чишмәдән су китереп, мунча як... Марсель Галиевнең «Су буеннан әнкәй кайтып килә» җырын тыңлаганда мин көянтә-чиләк белән судан кайтып килүче әниемне, аңа чордаш апаларны күз алдыма китерәм. Без яшәгән Акташ авылы чишмәләре дә яр астында иде, көн саен ничәшәр көянтә су китерде икән әниебез...



БАЛАЧАК Безнең чорга яланаяклы балачак хас. Язгы кояш карны эретеп бетерүгә яланаяк чыгып чабабыз. Аяк-куллар «чебиләп бетә», әни мунчада елата-елата кер сабыны белән мунчалалап юа, вазелин сөртеп куйган була. Нишләптер, без үскәндә кышлар бик салкын, җәйләр бик эссе булып хәтердә калган.

Мин үземне бик «важный» кешегә саный идем, ике сеңлемә – абый бит! Әлфия белән Рәйсәне карау минем өстә. Рәйсә – төпчек кыз, нәни иде. Әлфия исә миннән бер дә калмый торган иде, мин койма башына менсәм, ул да – шунда, малайлар белән сугыша башласак та арага кереп кысыла. Кайвакыт үзара да сугышып китәбез. Нәрсә бүлгәнбездер иде, бүләрлек әйбере бармы? Кайвакыт мине әнигә әләкли: Фәрит болай эшләде, Фәрит тегене ватты... Шуңа да карамастан, без аның белән «агылый белән тагылый» идек. Хәзер дә һәр очрашуга шатланып яшибез...



МӘКТӘП Беренче класска мин Акташ авылы мәктәбенә бардым. Утын ягып җылытыла торган иске генә таш бина иде ул. Ашарга үзебез белән алып йөри идек. Гадәттә, миңа әни ипи белән бер кисәк ит, шешә белән сөт яисә сөтле чәй салып җибәрә торган иде.

Мин җиңел укыдым, өйгә бирелгән эшләрне озаклап әзерләп утырганымны хәтерләмим. Мәктәптән кайткач тиз генә капкалап алам да урамга чыгып чабам. Кышын чаңгы шуа идек.

Без бу авылда бердәнбер татар гаиләсе идек. Әти чәчемне фронттан алып кайткан үткен пәкесе белән кырып ала. Шул такыр башлы кечкенә генә малайдан авыл китапханәсендә уздырылган кичәләрдә шигырь сөйләтәләр иде.

Акташтан Әлмәткә күченеп кайткач, әти мине нефтьче балалары укый торган мәктәпкә бирде. Нефтьчеләр акчаны яхшы ала, балалары шәп киенә, өсләрендә шәп фуфайкалар. Минем өстә – сырган бишмәт. Малайлар мине мыскыл итеп көләләр... Шуннан соң әтиләр миңа кесәле фуфайка алып бирделәр. Вәт йөреп күрсәттем мин мәктәптә!

Укуны Әлмәтнең 7 нче санлы мәктәбендә тәмамладым. Мәктәпнең ярты гасырлык юбилее булган иде, күпләр белән шунда очраштык, сөйләштек. Класс җитәкчебез Петр Иванович Барашниковны күреп, рәхмәтләребезне әйтергә өлгердек. Классташлар белән бу очрашу соңгысы булмасын иде, дип телим. Кем белә?..



ХЕЗМӘТ ЮЛЫ 15 яшьтә Миңлебай газ-бензин заводында токарь булып эшли башладым. Шуннан армиягә алдылар. Аннан кайтканнан соң, «Әлмәтнефть» идарәсенең контроль-үлчәү приборлары цехында слесарь булдым. Көндез эшләдем, кичләрен техникумда укыдым. Аннары Уфа нефть институтын тәмамладым. Белемем буенча мин – нефтьче. Әмма 70 нче еллардан башлап Әлмәт шәһәрендә партия, совет һәм хуҗалык эшләренә кереп киттем.

Сиксәненче еллар ахырында мине республиканың сәүдә министры итеп куйдылар. Соңрак Татарстан Республикасы Премьер-министры вазыйфасын башкардым. Гомеремнең егерме елдан артыгы Татарстан парламенты белән бәйләнгән.

Мин еш кына үземнең тормышым, хәзерге телдә әйтсәк, карьерам турында уйланам. Хәер, нинди карьера булсын инде, күп вакыт миннән сорап та тормадылар, алдылар, куйдылар...

Парламент рәисе булып та тумыйлар. Сәясәтче булу өчен «бер пот тоз ашау» гына да җитми. Әмма узган тормыш мәктәбем миңа Россия күләмендә һәм Европа Советы дәрәҗәсендә эш алып барырга, үз фикеремне әйтергә һәм теләктәшләр табарга ярдәм итте.

Бер карасаң, минем тормышым сайлаулардан һәм сайланулардан тора кебек. Парламентта бер эшләп киткәннән соң, кабат 1998 елның маенда кайтырга туры килде. Дәүләт Советы Рәисе вазыйфасына без ике кандидат идек. Мәсьәләне минем файдага 27 тавыш хәл итте.

2014 елның 15 октябрендә миңа Европа Советы Җирле һәм төбәк хакимиятләре конгрессының Актуаль мәсьәләләр буенча комитеты рәисе вазыйфасына сайланырга туры килде. Аннан алда мин ике ел дәвамында бу комитетны җитәкләгән идем. Кырымның Россиягә кушылган елы, Европаның Россиягә санкцияләре башланган вакыт иде бу. Минем оппонентым – Лондон шәһәре Ассамблеясе депутаты Эндрю Бофф иде. Аны яклап 25 кеше тавыш бирде, миңа – 27. Ике тавыш белән җиңдем!

Бу очракны шәхси җиңүем дип тә кабул иттем, Европада Россиянең сәясәтен тирәнтен аңлаучы кешеләрнең булуы дип тә... Гәрчә Россиягә карата мөнәсәбәт бик кискен иде ул елларда..



ДУСЛАР Якын дуслар күп булмый. Әлмәт шәһәренең комсомол оешмасында инструктор булып эшләгәндә дуслашкан кешеләр, мөгаен, иң якын дусларымдыр. Барыбыз да – яшьләр, активлар, тормышлар да бер чама. Бәйрәмнәрдә

PRESSA.RU

гаиләләребез белән җыелабыз, табигатькә чыгабыз... Тормыш төрлебезне төрле якка таратты, еш күрешеп булмый, әмма элемтәне өзмибез. Җай чыкса, шатланып күрешәбез. Туган көн, бәйрәмнәр белән котлашабыз.

Дөресен әйткәндә, мин яңа кешеләр белән авыррак дуслашам. Бу мәсьәләгә саграк карыйм. Дәрәҗәле эштә эшләсәң «дуслар» күп була инде ул. Эштән китәргә туры килсә, чын дуслар гына кала.



МӘХӘББӘТ Булачак тормыш иптәшем белән мин армия хезмәтеннән кайткач таныштым. 1968 елның ноябрь бәйрәмнәре иде. Дуслар белән «Восток» ресторанында минем «кайтуымны билгеләп үтәргә» ниятләдек. Янәшәбездә бер төркем яшьләр Әлмәт комсомол оешмасына Хезмәт Кызыл Байрагы орденын бирүне бәйрәм итә иде. Луизаны беренче тапкыр шунда күрдем һәм гашыйк та булдым бугай... Әмма янына барып танышырга, биергә чакырырга кыюлыгым җитмәде. Икенче тапкыр дусларымның туенда очраттым. Өстәл астыннан керергә туры килде аларга. Шунда таныштык. Луиза – искиткеч матур исем! Үзе кебек! Шул көннән соң без – бергә. Ике ел очрашып йөрдек, матур итеп туй ясадык. Тормышыбызны «малосемейка»да башладык. Беренче телевизорны, аклы-каралы «Березка» иде ул, өлешләп түләү шарты белән алдык. 20 ел хезмәт итте. Мин аны Казанга күченеп килгәч, «Эфир» телекомпаниясе музеена тапшырдым.



БАЛАЛАР Дамир белән Лилия. Дөресен әйткәндә, балаларның ничек үскәнен күрмәдем дә дияргә була. Аларны тәрбияләү белән тулысынча хатыным Луиза шөгыльләнде. Ул да, минем әни кебек, «әтиегез белсә!» дип үстерде, балалар алдында мине Әти итеп куя белде. Мин хатыныма чиксез рәхмәтле. Аллага шөкер дип әйтәм, миңа балаларым өчен кызарырга туры килмәде! Моннан соң да шушы тәртип белән яшәсәләр, без бик канәгать.

Дамир финансист, тормыш иптәше дә шул өлкәдән. Ике кызы, бер улы бар. Лилия белән кияү – табиблар. Ике кызлары матур булып үсеп килә. Һәр ял саен җыелып киләләр дә, өебезне шау-шуга күмеп, Луизага ике-өч көнлек эш калдырып китәләр. Икәү генә тынычлыкта калып яшәгәндәй итәбез дә тагын балаларның килүен көтә башлыйбыз. Луиза еш кына мәрхүм әтисенең сүзләрен көлеп искә ала: балалар килгәч рәхәт була, алар киткәч тагын бер рәхәт була...



УҢЫШ Тормышның күп кенә очракларында минем эшләрем уңышлы булды. Әмма бу уңыш – җай килү очрагы гына түгел. Миңа калса, кешенең киләчәген аның эчке халәте, шәхси сыйфатлары билгели. Сабыр холыклы булу, кимчелекләреңне белеп, аларны бетерү өстендә эшләү, үзеңне чикли белү кебек сыйфатлар, минемчә, уңышка ирешүдә мөһим роль уйныйлар. Кешенең эчке дөньясы белән кылган эш-гамәлләре тәңгәл килергә тиеш. Үзең бер төрле яшәп, икенче төрле сөйләп йөреп уңышка ирешеп булмый.



АКЧА Беренче хезмәт хакын 7 нче классны тәмамлагач эшләп алдым. Җәй көне әти мине ремонт-төзелеш идарәсенә эшкә урнаштырды, газон кырыйлатып койма тотарга. Кулда чүкеч, такта, кадак – көне буе тук та, тук. 15 яшем тулганда мин өч җәй рәттән геодезистлар белән геологик эзләнүләрдә булырга өлгергән идем. Алар нефть мәйданнарын үлчиләр, мин линейка тотып торам. Хәйран гына акча эшләдем, кул сәгате сатып алдым, «Победа». Шул сәгать белән армиягә киттем. Мин акчаның нинди хезмәт белән табылганын беләм!

Көтмәгәндә кулга зур акча керсә нәрсә эшләр идегез, дигән сорауны бирәсез... Дөресен әйткәндә, миңа акча каяндыр килеп керми. Премия-фәлән булса, мин балаларга, оныкларга булышу җаен карыйм. Туган якларда шактый тыйнак яшәүче олы яшьтәге туганнар бар, аларга да күпмедер ярдәм итү кирәк. Кемдер «болар балда-майда йөзә» дип тә уйлыйдыр. Әмма дөресен әйтәм, вак-төяк ямауларга урын бар...



МАВЫГУ Мин, гомумән, мавыгучан кеше: волейбол, хоккей, бильярд, балык тоту һәм автомобиль.

Мин аеруча «Волга» машинасын яратам. Әлмәт Башкарма комитетында эшли башлагач, ике урынбасарга бер «Волга» – ГАЗ-21 машинасын бирделәр. Иске генә бу машина безгә бик кадерле иде. Гомер дәвамында эш машиналары алышынды, «Волга»га булган мәхәббәт калды. Гаражымда ярты гасыр элек Горький автомобиль заводында чыгарылган «Волга» – ГАЗ-21 тора. Мин аны моннан егерме биш ел элек отставкага чыккан бер генералдан сатып алган идем. Буш вакытымда шул машинам белән юанам: майлыйм, сөртәм, җыям...

Бу мавыгуым «АвтоРетроКлуб-21»нең оешуына сәбәп булды. Йөздән артык кеше безнең клубта әгъза булып тора. Өлкән агайлар да, яшь кенә малайлар да, гүзәл затлар да кызыксына ретроавтомобильләр белән. Республика буенча автойөрешләр уздырганда төрле шәһәр-авылларда халык сырып ала, сорашалар, мактау сүзләре әйтәләр, фотоларга төшәләр... Фронтовиклар, сугыш чоры машиналарын танып, шуларны куллары белән сыйпап иркәлиләр, елыйлар. Мин иске машиналарга «җан өргән» клуб әгъзаларына бик рәхмәтле.



ҮЗЕМ ТУРЫНДА Без бу дөньяга бик аз вакытка килгәнбез. Шул вакытны юк-барга сарыф итмичә, үзең киткәч тә сине яхшы яктан гына искә алырлык итеп яшисе иде бит! Битарафлыкны җенем сөйми. Хәтта сатлык кешеләрне дә, гафу итмәсәң дә, аңларга тырышасың, бу адымга барырга нидер сәбәп булгандыр дип уйлыйсың. Кыйбласыз кешеләрне аңламыйм. Туфан абый Миңнуллин әйтә иде, Фәрит, моңардан өмет юк, дия иде. Кешенең тормышта үз фикере, карашы булырга тиеш. Миңа яшәүдән мәгънә, ямь таба белгәннәр ошый.

Чулпан ӘХМӘТОВА.

Дөньядагы иң яхшы ун оркестрның берсе дип саналучы Франция милли оркестры – француз симфоник оркестрында төрле илләрдән килгән музыкантлар һәрвакытта да байтак була. Әмма Россиядән килүчеләр оркестр тарихында икәү генә. Сиксән ел эчендә бу! Һәм шул икәүнең берсе – безнең татар кызы! Адэлия ЧАМРИНА – Казанда туып-үсә. Әнисе Динара балалар бакчасында музыкаль җитәкче, әтисе Валера – продюсер, гитарада, фортепианода уйный. Алма агачыннан ничек ерак төшсен, ди, инде?



ХЫЯЛ АРТЫННАН

Адэлияне балалар бакчасында ук «күреп алалар». 1 нче сыйныфка ул сәләтле балалар өчен ачылган махсус музыка мәктәбенә укырга бара. Муса Маликов белән бер партага утырып дәресләр тыңлый. Хәзер дә алар якын дуслар!

Башта аны скрипка классына укырга бирәләр. Ә Адэлиягә альт күбрәк ошый төшә... Үз дигәненә ирешә – күчерәләр. Уку еллары сизелмичә дә узып китә. «La Primavera» камера оркестрында эшли башлый. Ә күңел... Күңел каядыр ашкына!

– Максим Венгеров, Вадим Репин кебек исемнәре бөтен дөньяга билгеле музыкантлар турында без дә, әлбәттә, ишетеп белә идек. Әмма концертларында булганыбыз, аларны тыңлаганыбыз юк. Алар бездә дә чыгыш ясар дип уйлап та булмый. Ә күрәсе, ишетәсе килә! Гомумән, дөньяны күрәсе килә!

Францияне очраклы гына сайлый ул. Хәер, үзебезгә шулай тоелса да, безнең бер адымыбыз да очраклы түгел анысы... «Французлар мәктәптә безнең кебек «сольфеджио» дәресләренә, фортепианода уйнарга өйрәнүгә зур игътибар итмиләр. Шуңа күрә, конкурсның өч турын да бик җиңел генә узып, Париж консерваториясе студенты да булып куйдым», – ди.

Җиңеллекләр шушы урында тәмамланып та куя... Бер танышы булмаган ил. Уку бушлай, әмма стипендия түләнми – тору урыны, ашау-эчү мәсьәләләрен үзенә кайгыртырга туры килә. Иртән консерваториягә укырга йөгерә, ә кичкә супермаркетка эшкә ашыга Адэлия: төне буе сабын яки шөреп саный – инвентаризация үткәрә. Чит ил кешеләренә мондый эш өчен сәгатенә 8 евродан артык түләмиләр. Иң арзанлы фатиргә түләргә, очын-очка ялгарга шул җитә тагын. Хәер, вакыт үткәч, авырлыклар онытыла, күңелдә хатирәләрнең яктысы гына кала.

– Париж – музыкантлар өчен җәннәт, – ди ул. – Монда барысы да синең тырышлыктан тора. Уйнавымны күргәч, бер концерттан икенчесенә чакыра башладылар. Шулай китте... Консерваторияне тәмамлагач, фрилансер булып эшләдем. Спектакльләрдә вакытлыча – контракттан контрактка гына уйнаучыларны алар шулай атый. Бу – бер яктан уңайлы: үзеңә-үзең хуҗа, теләсәң ризалашасың, теләмәсәң баш тартасың...

Ә дүрт ел элек, тәвәккәлләп, шактый зур конкурста катнаша ул. Аңа кабат уңыш елмая! Француз милли оркестрында уйный бүген Адэлия Чамрина.

– Эш тә дия алмыйм моны... Музыка – дөньядагы иң зур мавыгуым бит! Бу яктан мин бәхетле...

Милли оркестрның концертлары Париж белән генә чикләнми: алар әле Европа тамашачысы алдында чыгыш ясыйлар, әле Америка Кушма Штатларына турнега ук китеп баралар. Аз гына буш ара калса, Адэлия кабат гастрольгә кузгала: «Elysee» квартеты да бар бит әле – ул анда да инде җиденче ел уйный.

Парижда яшәүче татарлар Адэлияне үзләре эзләп таба. Шуннан бирле бер концертын да диярлек калдырмыйлар. Тамашачылар арасында якташларың, милләттәшләрең утыруны белү куаныч та, җаваплылык та. «Алар белән очрашуларга үзем дә бик теләп барам. Рәхәт миңа анда... Тамырлар тартуымы икән бу? Бабамның әтисе Саба ягыннан – Әүхәдиевләр, ул имам булган. Әбием кияүгә чыккач, Чамриннар булып киткәнбез.

Алмаз Монасыйпов әсәрләреннән торган концерт куясым килә Парижда. Французларга ошар иде ул. Скрипка һәм фортепиано өчен язылган бик матур әсәрләре бар бит аның. Германиядән Муса да килер иде, сәхнәгә минем белән ул да чыгар иде...»

Гөлнур САФИУЛЛИНА

PRESSA.RU

БУ СТУДИЯГӘ КИЛЕРГӘ ЭТӘРГЕЧ БУЛГАН ДИСКТА 205 ХАЛЫК ҖЫРЫН КҮРЕП УШЫМ КИТКӘН ИДЕ.

Ә бит шушы 2005 җырның һәркайсы «Аксу» студиясе аша узган. Көненә өч җыр яздырып өлгергән сурәттә дә ике ай тоташтан Мирсәет Сөнгатуллин белән эшләгәннәр дигән сүз.





Асия ЮНЫСОВА

МОНДА ҖЫР ТУА

«Аксу» студиясенең пыяла ишекләре янында еш узып йөри торгач, көннәрдән бер көнне борылдым да кердем мин монда. Бер каршылыксыз түргә уздым. Эш белән мәшгуль кыз-егетләр мине тоткарлап тормады. Хуҗаның кайтканын күн диванга утырып көтеп алырга киңәш иттеләр дә, ишектән әледән әле кереп торган клиентлары (дөресрәге, заказчылары) белән мәшгуль булдылар.

Авыл өе дигәнемә бәйләнмәгез. Интерьер шундый – «Аксу» студиясенең «яшәешендә» авыл интеллигенты өендәге рух яши. Шкаф-шкаф китаплар, шкаф-шкаф дисклар. Почмак саен баян, хромка гармун, барабан, виолончель ише уен кораллары. Хәтта синтезатор белән пианино да бар. Харап икән, чып-чын тавыш яздыру студиясе интерьеры бит инде бу, дияргә ашыкмагыз. Тавыш яздыра торган студияләр бу «өйнең» түбәнге катында. Андый – микрофонлы, диварлары чит тавыштан якланган, җырчы өчен илһами рух тәэмин ителгән махсус ике студия болай да бар. Монысы – мин хуҗаны – Рөстәм Сәрвәровны көтеп утырганда манзара кылганы нәкъ менә интеллигент өе! Әнә ич, җиз самавыр чәйгүнен чөеп җырлап утыра; әнә ич, тәрәзә төпләре тулы яран гөлләр, читән кәрзиннәр; әнә ич, диварларда җанга якын затларның фоторәсемнәре; әнә ич, хуҗа өстәлендә ачып куелган дәфтәре белән каләме... Минем әни дәфтәр тикшерә торган җиреннән торып чыгып кына киткән кебек...

Инде «Аксу» тавыш яздыру студиясенең хуҗасы Рөстәм Сәрвәровның үзе белән сөйләшеп утырабыз Бик мөлаем, бик итагатьле кеше булып чыкты бу көмеш чәчле, көмеш мыеклы Мөслим егете. Ташлыяр авылыннан икән. Минем сабакташ шагыйрьләрем Зөлфәт, Фәрит, Харрасларның якташы. Димәк, хатирәләргә генә чумып кына утырсак та, сөйләшеп сүзләр бетә торган түгел. Ә Рөстәм Сәрвәров үзен бөтен татарның якташы кебек тота. Әле дә менә шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовның исемен мәңгеләштерү җәһәтеннән мәшәкатьләнгән чагы икән. Туган авылында шагыйрьнең музееен ачу, Мөдәрриснең шигырьләрен аудиоязмаларда чагылдыру, шигырьләрне сәнгатьчә укуны оештыру, фотоларын, замандашларының истәлекләрен җыйнау кебек инде шушы «мәшәкатьләр» дигән төшенчә эченә. «Аксу»да мондый проектлар һаман гамәлгә ашырылып тора. Әле яңарак кына Филармония залында галим һәм шагыйрь Филүс Хисаметдиновның иҗат кичәсен дә алар әзерләп уздырганнар иде. Хәер, болары «Аксу»ның имиджын, дәрәҗәсен билгеләгән, данын яңгыраткан эшләр түгел әле. Ул иң әүвәле тавыш яздыру, аудио һәм видеодисклар чыгаручы иҗат оешмасы буларак танылды.

Егерме еллап элек, ягъни «Аксу» үзе хакында хәбәр биргәндә бу төр иҗат-бизнес белән шөгыльләнүчеләр байтак иде. «Тургай»лар каядыр югалды. Гөлзадә Сафиуллина студиясе дә эшен туктатты. «Барс-Рекордс» әйбәт кенә эшләп тора, «Болгар радиосы» җырчыларны үз тирәсенә туплый бугай әле. Исемле җырчыларның һәммәсенең диярлек хосусый җыр яздыру студияләре бар. Димәк, «Аксу»ның эшчәнлек кыры тарая бара кебек. Бер юнәлештә генә хәрәкәт иткәндә иҗат йомгагын йомгаклап кую да бик тиз булыр иде. Әмма Рөстәм Сәрвәровның, татар кешесе буларак, үз алдына куйган максаты бер көнлек ихтыяҗлардан ерак тора.

«Милләтне саклау өчен мин нәрсә эшли алам?» Бу сорауны үз алдына куючы сирәк кешеләрнең берсе ул. Интернетта «Аксу ТВ» сайтын ачып җибәрү генә бер хәл. Ул сайтны видеоязмалар белән тәэмин итү икенче нәрсә. Ә инде сайтыңны милләтеңә файдалы итү, киләчәкле итү өчен яшь аудиторияне кайгыртырга, ягъни балалардан башларга кирәк. Бар дөньясы интернетның балалар психикасына һөҗүменнән зар елаганда Сәрвәров шушы глобаль челтәрне игелекле итү әмәлен эзләгән. Һәм тапкан да. Мультфильмнар кирәк. Татарча мультфильмнар! Кая соң алар? Сәнгатьнең бу төре бик кыйммәтле булганга күрә, үзебезнең мультфильмнар бармак белән генә санарлык. Нишләргә соң? Бу юлы да әмәле табыла. Әлфия Һадиева кебек эзләнүчән ярдәмчеләр булганда табылмыймы соң! «Союзмультфильм» төшергән 40 лап фильм тәрҗемә ителә. Шулай итеп, студия тирәсендә һәвәскәр тәрҗемәчеләр туплана. Бер башлагач китә инде. 90 серияле «Иржан» мультфильмын төрек теленнән татарчага аударганнарын сизми дә калалар. Шуларга тагын 60 серияле «Фикси»ләр өстәлә. Бу җәһәттән эшләренең уңай китүенә «Аксу»лар Татарстан мәгариф министрлыгына рәхмәтле. Югыйсә рәхмәтле булырга тиешле кешеләр татар мәктәпләрендә укучы балалар һәм тәрбия өлкәсендә эшләүчеләр булырга тиеш. Хәер, татар балалары өчен җырлар һәм шигырьләр дә мәктәп программалары белән килештерелеп чыгарыла. «Татар әкиятләре», «Татарча сөйләшәбез» сериясеннән чыгарылган тематик дисклар баласын ана телендә матур итеп сөйләшергә өйрәтәсе килгән дәү әниләр, әти-әниләр өчен дә өйдәге йомшак песи кебек үк бик кирәкле ярдәмчеләр. Менә шул диск-китаплар аша үткән нәни татар баласы инде зур үскәч, «Халкыбыз мирасы» сериясеннән чыгарылган җырларны күңел түренә салырлык булып җитешер. Аудиодискка иптәшкә тәкъдим ителә торган китапта исә җырлар сүзләре һәм ияләре белән йөри. Тышлыгын Нәҗип Нәккаш эшләгән бу җыентыкларның бер китабында гына да – 100 җыр. Җырларның һәркайсын студия егет-кызлары төрле чыганаклардан эзләп тапкан. Еллар буе җырчылар «халык җыры» дип башкарган көйләрнең авторлары барлыгы исбатланган.

Ә бит бирегә җыр яздыру өчен генә килмиләр. Әйтик, шагыйрьләр Марсель Галиев, Разил Вәлиев, җырлар белән шигырьләрен бәйләп, аудиоҗыентыклар яздырып киткәннәр. Мондый төр дисклар эшләү өчен профессиональ артистлар – нәфис сүз осталары да җәлеп ителә. Күптән түгел Луара Шакирҗан Австралиядә яшәүче Сөенгөл ханымның романын сәнгатьчә укып яздырган икән. Бу бит сибелгән татар кешеләрен мәдәни йодрыкта берләштерүнең иң отышлы юлы. Әгәренки китап барып җитмәгән урыннарга әдипләребезнең шигырьләре, бәяннары аудио-видео дисклар, сайтлар аша барып җитә икән, бу бит «Аксу» студиясенең татар милләтен саклап калуга керткән биниһая сәрмаясы булып чыга.

Югыйсә «безгә шәхесләр белән эшләү бик рәхәт» дип торсалар да, Рөстәм Сәрвәровка үз иҗатын пропагандалау, халыкка күрсәтү җәһәтеннән эшләгәндә дә ярар иде. Чөнки музыка училищесында укыганда ук Мирсәет Яруллин, Фасил Әхмәтев кебек музыка белгечләренең хуплавын ишеткән бард-гитарист егет Рөстәм Сәрвәров сәнгать дөньясындагы популяр бу жанрны ялгыз билэп тора алыр иде. Рәшит Абдуллин кебек талантттан соң, бу жанрда бездә чыннан да бушлык. Ә бит Рөстәм сүзләрен дә, көен дә үзе язган, үзе үк җырлый да торган – дистәләгән җырын тамашачы хөкеменә чыгарган һәм уңыш казанган башкаручы. Тик хезмәте бернинди дәүләт бүләкләре белән дә бәяләнмәгән бу кешене, нигәдер, үз шәхесе түгел, кайвакыт бөтенләй исемсез кешеләрне иҗат шатлыгы белән сөендерү мавыктыра. Әйтик, Оренбургтан килгән 80 яшьлек Шәһәргөл апаның яки менә 60 яшьлек Гөлфәридә ханымның мираска җыр калдыру теләген ничек инде тамырда килеш кисәсең? Шундый әзерлексез җырчыларга ярдәм итү өчен биредә вокал мәктәбе дә эшләп тора. Анда мәктәп балалары да килеп, җыр күнекмәләре ала ала. Бу мәктәптә танылган җырчы Лилия Чугунова да дәресләр бирә.

Киткәндә күзем дивардагы Россия картасына төште. Татарстан анда яшел кульяулык кебек кенә күренә. «Аксу» шул кульяулык читендәге бер нурлы чәчәк кебек. Әмма бу чәчәкнең җыр-шигырь, милли язмалар рәвешендәге нуры Җир шарын җылытырга да җитәрлек.

«АКСУ» КОМПАНИЯЛӘРЕ БЕРЛЕГЕ



● Аксу TV www.aksu-tv.ru ● Гаилә интернет-каналы. Иҗтимагый, мәдәни, тарихи һәм башка темаларга интервью һәм репортажлар. Шулай ук күңел юаткыч тамашалар, эстрада концертлары, фольклор.

● Халкыбыз мирасы ● CD, DVD дисклар, мультимедия басмалары һәм китаплар, буклет һәм открыткалар, җырлый һәм сөйләшә торган йомшак уенчыклар җитештерү.

● Балачак TV www.balachak-tv.tatar ● Күңел ачу-белем бирү балалар интернет-каналы. Татарча мультфильмнар, анимацион сюжетлар, балалар өчен җырлар һәм караоке.

● Aksu Records www.aksu-records.ru ● Профессиональ тавыш яздыру студиясе. Вокал, уен кораллары яздыру, аранжировкалар ясау, фильмнарны тәрҗемә итү һәм тавышландыру. Шагыйрь һәм композиторлар әсәрләрен тәкъдим итү.

● Интернет магазин www.aksu-studio.ru ● Татарча дисклар, китаплар, сувенирлар Россия буенча түләүсез китерү.

Казан шәһәре, Спортивная урамы, 33 нче йорт,
тел.: 8 (843) 246-22-46.

РЕКЛАМА

PRESSA.RU



Флёра Тарханова – укучылар күңелен гыйбрәтле хикәяләре, уйландырырлык язмалары, матур җырлары белән яулаган авторыбыз. Шигърияте турында, «ак чәчәкләр сыман», дип язып чыктылар! Күпләр өчен ул Гүзәл Яхинаның «Зөләйха күзләрен ача» романын татар укучыларына якынайткан тәрҗемәче буларак та яхшы таныш. Журналистика, тәрҗемә, фән, әдәбият, җыр... Ул барысын да колачлый. Укытучылар гаиләсендә үскән Чистай районы Яуширмә кызы булсын да! Хезмәт юлын мәктәптән башласын да!.. Күпсанлы укучылары, каләмдәшләре исеменнән гомер бәйрәме белән котлыйбыз! Иҗат уңышлары телибез!

Флёра
ТАРХАНОВА

КҮЗЛӘРЕМДӘ – ЯШӘҮ ЧАТКЫСЫ...

*Сандугачлар мине юата**

Синсез генә хәзер кояш бата,
Синнән башка гына таң ата.
Сандугачлар җыры – җанга дәва:
Сине генә сөйде,
Бары син дип көйде,
Дия-дия мине юата.

Җәйләр үтте, көзләр, кышлар китте,
Инде кабат кердем язларга.
Сандугачлар бәгырьләрне телә:
Кайта алмый аннан,
Өмет итмә һаман –
Килмәс инде, күммәс назларга.

Хәсрәт калды, үкенечләр калды,
Әйтер сүзләр калды телләрдә.
Сандугачлар җыры сагыш өсти:
Искә төшереп ярым,
Кайтаралар тагын
Без бәхетле булган көннәргә.

*Син булганда***

Син булганда, күгем балкый минем –
Дөньям тула якты хис белән;
Үбеп озатуым иртә таңнан
Бәхет булып кайта кич белән.

Син булганда, җаным тыныч минем –
Тоям һәрчак синең терәкне;
Күргән газапларым төссезләнә –
Телеп-телеп алмый йөрәкне.

Син булганда, чиксез рәхәт миңа –
Күзләремдә – яшәү чаткысы;
Яратуның бу илаһи көчен
Тик саклыйсы иде, саклыйсы!

*Ялгыз өй****

Туган йортны сагынып
кайткан идем –
Истәлекләр кабат яңарды,
Өрфә җептәй нечкә күңелемә
Үзәк өзгеч хисләр таралды.

Өйгә илтә торган озын юлны
Күмеп киткән әнкәй сагышы.
Баскан саен ишетелеп куя
Әтиемнең гармун тавышы.

Үткәнемә үрелеп карар өчен
Мин күтәрдем хәтер читләрен.
Үсмер чакның күз карашын тоеп,
Сискәнүдән әллә нишләдем.

Инде ялгыз калган туган йортка
Кереп булмый икән капкадан.
Тәрәз аша эчкә карыйм, дисәм,
Күзләремне пәрдә каплаган.

Безнең эзләр яткан шушы өйдә
Җыелышкан узган елларым,
Түзалмадым, тәрәз капкачына
Башым куеп үксеп еладым.

Өйгә илтә торган бөтен юлны
Күмеп киткән әнкәй сагышы.
Баскан саен ишетелеп куя
Әтиемнең гармун тавышы.

*Булдым инде таңда бер Чулпан*****

Таң аттырдым зарыгып, телемнән
Әйтеләсе сүзләрем тамды.
Төн буена бөтен галәмнән
Сине эзләп, күзләрем талды.

Ничә еллар әрнидер бу җан,
Булдым инде таңда бер Чулпан.
Миңа кушылып сыкрый
бар Җиһан –
Ничә еллар әрнидер бу җан.

Өзгәләнгән күңел тулышты,
Сагышыма хисләр булышты,
Уйлар сиңа юл алу белән,
Күз яшьләре каплый сулышны.

Таң аттырдым – керфек чыланган,
Әйткән сүзем барып җитмәде.
Инде телдән алып ташладым,
Ә йөрәктән барыбер китмәдең.

Ничә еллар әрнидер бу җан,
Булдым инде таңда бер Чулпан.
Миңа кушылып сыкрый
бар Җиһан –
Ничә еллар әрнидер бу җан.

---

* Рамил Миндияр музыкасы.
** Муса Маликов музыкасы.
*** Флёра Тарханова музыкасы.
**** Илдус Тарханов музыкасы.

Мәскәүләрдә «Сөембикә» журналының үз кешесе, үз илчесе бар. Нәзифә Кәримова! Аны «Азатлык» радиосыннан да тыңлыйбыз, Казанда үткән милли, әдәби җыеннарда да күреп калабыз, Мәскәүдәге «Зыялылар» клубында оештырган эшләреннән дә хәбәрдар булып торабыз. Ут ул, тынгысыз чын иҗатчы! Хикәя-повестьлар, драма әсәрләре, балалар өчен әкиятләр... Журналистик язмалар, тәрҗемәләр... Бүген инде шушы саллы иҗатта хис, йөрәк җыры булган шигырьләре дә үз урынын тапкан. Иҗат уңышлары телибез, Нәзифә! Юбилей котлы булсын!



Нәзифә
КӘРИМОВА

ЙОЛДЫЗ ЯВА, ЙОЛДЫЗ ЯВА...

Ак томан

Авылга төште ак томан
Актан ак җәймә сыман.
Әкрен генә, җайлап кына
Агачларны каплады,
Аннан йотты томан
Койма белән капканы.
Сыйпап кына үтеп китте
Барлык өйләр өстеннән.
Өйләр күздән юкка чыкты,
Әйтерсең лә әфсеннән.
Күренми, «сөткә» баттылар
Су буендагы таллар,
Су юллары кирәк булса,
Кем ничек эзләп табар?
Дөнья күмелде томанга,
Кешеләр дә югалды,
Мин бара торган юлны да
Томан үзенә алды.
Кычкырсаң да ишетелми –
Тавышны йотты томан.
Әнә шулай кеше белән
Томан бары тик уйный.
Бар дөнья минеке диеп,
Томан бик ялгыш уйлый.

Түз инде!

Уфларым ла икән инде,
Сабырлык чиге кайда!
Күпме түзәргә була соң,
Елларны ялгап айга!
Бүген булмаса, иртәгә
Ходай бирер җиңеллек.
Күтәрмәсне бирми диләр,
Монысына түзәрлек.
Без үзебез үзгәрмәгәч,
Дөнья ничек үзгәрсен?
Ышанычның үз кыйбласы,
Белә кая барасын.
Менә шулай көн артыннан,
Гомерләр узып бара...
Кемнәр генә әйтер икән,
Хәлең ничек, дип, бала?

Елгалар

Ярларга сарылып,
                    талларны сагынып,
Агалар елгалар, агалар.
Ашыгып-ургылып,
                    тын калып, сулыгып,
Өр-яңа ярларны табалар.
Агалар елгалар, агалар.

Язмышның ярлары,
                    күңелнең зарлары
Агалар, елгадай агалар.
Җаннарга ягылган төзәлмәс яралар
Елгадай ияреп баралар.
Агалар еллары, агалар.

Яшьлекнең ярларын,
                    сандугач талларын
Елгалар әле дә саклыйлар.
Елгалар шикелле гомернең еллары
Яңадан әйләнеп кайтмыйлар.
Күңелдә ярларны саклыйлар.

Йолдыз ява

Күккә сыймаган йолдызлар
Яңгыр кебек явалар.
Бәхет сынап күккә карыйм:
Ерак түгел аралар.

«Кулларыма төшегез!» – дип,
Учларымны күтәрәм.
Бәхет шулай яуса күктән,
Күпмесе булыр әрәм!

Җем-җем йолдызлар атылды,
Учларыма төшмәде.
Шаулап коелды күк йөзе,
Миңа гына җитмәде.

Уч кушырып, күккә карап,
Бәхетне көтмә икән;
Кадерләрен белә белсәң,
Җирдәгесе дә җиткән.

Җәйге күккә сыешмыйча,
Безгә таба йолдыз ага.
Әллә Җирдән бәхет эзли –
Йолдыз ява, йолдыз ява.

Бәхет тапмый күкләрдә дә:
Йолдыз үзен Җиргә ата.
Авыр икән йолдыз юлы –
Кара янып җирдә ята.

Әллә янып көйгәнгәме –
Күктә урын беткән аңа;
Йөрәкләрне жу иттереп,
Йолдыз ява, йолдыз ява.

PRESSA.RU

TMTV – СЫЙФАТ БИЛГЕСЕ

Сәгатьләр буе текәлеп карап утырсаң да, туйдырмый торган нәрсәләр була. Беренчесе – ут. Икенчесе – агымсу. Ә өченчесе – җыр, дип тә өстик әле. Аны тыңлап кына калмыйча, яраткан җырчыларыбызның сәхнәдә үз-үзләрен тотышларын, затлы киемнәрен, җырны тавыш белән генә түгел, йөз хәрәкәте ярдәмендә дә ачып бирә алуларын күзәтергә яратабыз бит.

«Барс Медиа» ширкәте халыкка андый мөмкинлекне тудырып кына тора. Ел дәвамында төрле концертлар оештырып, тамашачыны кинәндерәләр. Моңарчы апрель ае татар халкы өчен шигърият һәм Тукай ае буларак билгеле иде. Хәзер апрельне җыр-моң ае дип атасак та ялгыш булмас. Ни өчен дигәндә, менә инде икенче ел рәттән апрель «Барс Медиа» ширкәте карамагындагы TMTV татар музыкаль телеканалы үткәрә торган «Музыкаль биеклек» премиясен тапшыру тантанасы белән истә кала. Әле икенче елын гына уздырылса да, тантана үз урынын, үз тамашачысын тапты инде. Югыйсә зал тутырып килгән тамашачы 7 сәгатькә якын барган концертны ахырынача карап бетергән булыр идемени?! Быелгы тамаша исә TMTV каналының биш еллыгына багышланган иде.

45 номинация. Араларында без күрергә күнеккән «Елның иң яхшы җырчысы», «Иң яхшы җыр», «Иң яхшы клип», «Иң яхшы дуэт», «Тамашачы мәхәббәте» кебекләре дә, замана сулышы өрелгәннәре дә бар: «Иң яхшы рингтон», «Иң яхшы ремейк», «Иң яхшы YouTube каналы». Атамалары колакка ятышлы булуы белән истә калган номинацияләр дә байтак иде: «Гаилә кыйммәтләре», «Моң дәвамчысы», «Ике гасырның иң күренекле җырчысы»... Һәр номинациядә җиңүгә өч җырчы дәгъва кылган булса, «Ике гасырның иң күренекле җырчысы» дигәнендә берәү генә иде – Салават. Көндәшләрсез, үзе генә. Шул рәвешле, оештыручылар аның кабатланмас һәм бердәнбер булуын тагын бер тапкыр билгеләп үтте.

«Пирамида» залын тутырып килгән һәр тамашачының үз җырчысы, үз җыры бар иде, әлбәттә. «Ак калфак» татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы рәисе Кадрия Идрисова сәхнәгә бүләк тапшырырга дип чыккач әйткәнчә, һәрберсе үзенчә матур,


























Фото: Айдар Салихов, Риназ Җамалиев, Эльмир Габидуллин

һәрберсенең үз урыны, үз тавышы, үз тыңлаучысы. Әле танылып кына килә торган яшь башкаручыларны да яратып каршы алдылар, инде татар эстрадасында үз урыннарын тапкан артистларга да алкышларын кызганмадылар. Салават, Хәния Фәрхи, Айдар Галимов, Зәйнәп Фәрхетдинова, Халидә Бигичева, Гүзәл Уразова, Филүс Каһиров, Илдар Әхмәтов халык мәхәббәтенә лаек икәнлекләрен тагын бер тапкыр расладылар.

Татар сәнгатенә керткән өлеше өчен Татарстанның халык артисты Флера Сөләймănованың да «Музыкаль биеклек» сыны белән бүләкләнүе нур өстенә нур булды. Сыйфат ягын да уйлый TMTV каналы җитәкчелеге, үлмәс җырларыбызны һәм легендар җырчыларыбызны да онытмый. Сыйфат дигәннән, сәхнә бизәлешен, җырчыларның чыгышын да менә шул бер сүз белән бәяләп булыр иде – сыйфат. Бүген халыкны тавыш белән генә шаккаттырып булмый. Тамаша кирәк, шоу кирәк. «Музыкаль биеклек» заманның әнә шул таләбен истә тотып оештырылган иде. Сәхнәдә бер-бер артлы реквизитларны алыштырып кына тордылар: менә өстәл һәм урындыклар алып чыгалар, менә кеше биеклеге барабаннар, диван, тәхет, чып-чын мотоцикллар. Аларга бииһая утлар, биючеләр кушыла. Тамашачы өчен 2-3 минутлык кыска спектакль тудырыла. Һәм ул спектакльдә төп рольне, әлбәттә инде, җырчы һәм аның җыры алып тора.

«Музыкаль биеклек» премиясен тапшыру тантанасында «Бәйрәм белән!» дигән сүзләр бик күп яңгырады. Премия тапшыру бәйрәме генә түгел, җыр бәйрәме иде шул ул. Әмма Татарстанның халык артисты Илдар Хәйруллин билгеләп үткәнчә, TMTV халыкка җыр гына бүләк итеп калмый, тагын бер зур эш башкара. «Без шушы матур бинада җыелышып, бер-беребез белән күрешеп, хәл-әхвәл белешеп, тагын бер тапкыр үзебезнең татар булуыбызны белдерәбез, туганлык һәм кардәшлек хисләрен яңартабыз. Ә бу бик кирәкле һәм кадерле әйбер. Шуның өчен рәхмәт телеканалга!» – дип сөйләде артист. Аның сүзләре белән килешми мөмкин түгел. Дәвамлы булсын, татар җыры кебек гомерле булсын иде TMTV премиясе дә!

Фәнзилә МОСТАФИНА

PRESSA.RU

Түбән Камада яшәп иҗат итүче Ралия Кәримованың Яңавыл районы Илдар Юзеев исемен йөртүче Ямады мәктәбендә укуы да, Башкорт дәүләт университетының татар филологиясе бүлеген тәмамлавы да, гаиләсе белән Кама буендагы яшьләр шәһәренә күчеп килүе дә, мәктәптә балалар укытуы да – барысы да аны әдәбият дөньясына әзерләгән. Ул – «Кама таңнары» әдәби берләшмәсе әгъзасы. Күп шигырь-хикәяләр авторы. Ралия шигырьләренә популяр җырлар язылган. Журнал укучыларга Ралия Кәримованың «Өзелгән кыллар» хикәясен тәкъдим итәбез.


Ралия КӘРИМОВА

өзелгән кыллар

ӨЗЕЛГӘН КЫЛЛАР

(Хикәя)

Ишек төбенә үк дигәндәй туктап, сигнал биреп торган кара машинаны күреп, Фәрит чыгарга ашыкты. Хатыны Гөлия аның кием-салымын күздән кичерде, кара костюмының җилкә тирәләрен каккалады, ак күлмәк якасын төзәтте. Фәрит затлы хушбуен сипте дә күн папкасына үрелде, хатыны белән баш кагып кына саубуллашып, ишеккә таба атлады. Гөлия тәрәзәдән урамга күз салды. Нинди чибәр, пөхтә аның Фәрите! Үзе акыллы, тыйнак. Шәһәр Башкарма комитетында эшли хәзер, сәүдә эшләре өчен җавап бирә. Оештыру сәләте, телгә осталыгы да бар, төшеп калганнардан түгел! Казанда студент елларында танышканнар иде Гөлия белән Фәрит. «Көзге бал» бара иде, педагогика институтының биофак студентлары янына бер төркем егет килеп кергәч, бар да аларга таба борылды. Егетләр авыл хуҗалыгы институтыннан икән. Кайбер кәттә кызлар:

– Фу, колхоз-навоз! – дип, читкә караган арада, егетләр икенче биюгә кызлар сайлады. Аксыл йөзле, нечкә билле, кыска итәкле шаян Гөлия янында тукталганы: «Әйдә, сылу, биибез!» – дип кулын сузды. Дулкынланып торган куе чәчле бу егет коңгырт күзләрен тутырып кызга карады да матур итеп елмайды. Егет нык бәдәнле, үзен ышанычлы тота. «Булачак колхоз рәисе инде бу!» – дигән уй чагылып үтте кызның башыннан. Кичәдән соң егет аны тулай торакка озата китте. Алтын көз шәһәр урамнарын сары яфраклар белән бизәгән тын гына кич иде бу. Яфракларны кыштырдата-кыштырдата, урам буйлап акрын гына җәяү атладылар. Шулай башланган танышлык әкренләп мәхәббәткә әверелде. Әнисе белән таныштырыр өчен Беренче майда кызны авылларына алып кайтты Фәрит, җәйге каникулда үзе Гөлияләргә китте. Бишенче курс ахырында өйләнештеләр. Диплом аласы көн җитеп килә иде, Гөлия иренә яңалык җиткерде:

– Фәрит, миңа юлламаны шәһәр мәктәбенә бирәләр! Нишлибез инде?

Гөлияне Чулман буендагы яшь шәһәргә җибәрәләр, Фәрит тә юлламаны шунда сорады. Мең төрле хыял, якты уй-ниятләр белән алар яңа шәһәргә килеп урнаштылар. Монда яшьлек романтикасы ташып тора. Илнең төрле якларыннан килгән комсомоллар – эшчеләр, белгечләр көндез төзелешләрдә эшли, җитештерү корылмалары төзи, юллар, заводлар сала. Ә кичләрен бию мәйданнарында, клубларда мәш киләләр. Шәһәр тирәсендәге хәтфәдәй болыннарда –

чәчәкләр, хисапсыз күлләрендә – балыклар, киң аланнарында – җиләкләр... Яңа йортлар калкып, фатирлары балкып тора. Хозурлык! Шашкын хисләре ташкын булып ургылып торган яшь белгечкә эш тиз табылган кебек, фатирны да озак көттермәделәр, тиз бирделәр. Коммунист кешегә кайда да юл ачык бит, Фәритне шәһәр партия комитетына чакырдылар. Шулай яшәп киттеләр. Менә уналты ел үткән дә киткән икән бит... Кызлары үсеп бетте, кечесе – өченчесе дә укырга керде. Тормышлары матур, яратышып яшиләр! Гөлия, шуларны уйлап, мәктәбенә таба атлады.

Соңгы вакытта күңелен кырып торган вакыйга булып алды әле менә. Фәрит авылдан әнисен алып килгән иде, шуннан нииндидер кытыршылыклар чыга, аңлашылмаучылык барлыкка килә башлады. Улын көнләгәндәй, кайнана сүз кыстыра, бар нәрсәгә кысыла, юк сәбәпләр табып тузына. Гөлия сүз әйтми, улларын ялгызы интегеп үстергән ананы аңларга тырыша. Бу хәлләрне күреп, Фәрит берничә айдан:

– Гөлия, бер бүлмәле фатир алырга җай чыгып тора, әнине аерым урнаштырсак, яхшы булырмы икән, ничек уйлыйсың? – дип сүз катты.

– Килгәнне кумыйм, киткәнне тыймыйм, үзең ничек хәл итәргә телисең, шулай эшлә, җаным, – диде хатыны.

Атналар, айлар үтте. Соңгы вакытта Фәрит соңлап кайта башлады: йә эше күп, йә очрашу билгеләнгән, йә районнарга чыгып киткәннәр... Шәһәргә Мәскәүдән кунаклар килә, аларга да эшне күрсәтәсе... Сәбәп табылып кына торды. Гөлия кәефсезләнеп китте исә дефицит күн итекләр пәйда була, матур сумка да алып кайтты ире, хатынның колакларын алтын алкалар да бизәде. Үткән атнада кайнанасын яңа фатирга урнаштырып, тәрәзәләренә пәрдәләр элде, кызлары белән бергә идәнен юды, җыештырды. Шул ук вакытта Фәритнең бөтенләй читләшә баруын да тойды ул. Завуч, аның дәресенә кереп утырганнан соң, бераз карап торды да:

– Гөлия Гафуровна, әллә авырыйсызмы? – дип сорап куйды.

– Нәрсәгәдер башым әйләнә, – дигән булды ул. Кырыгы да тулмаган яшь хатынның башы әйләнү табигый нәрсә түгел дә, тик ярты төн буе йокламыйча борчылып ирен көткәнне кешегә әйтеп буламыни? Эштә онытылып торырга була: әле классы белән экскурсиягә бара, йә фестивальгә яки җыр конкурсына әзерләнәләр; класс сәгатьләренә темалар сайлый, дәресләренә планнар төзи – тавык та чүпләп бетерә алмаслык бит укытучының эше! Тәртипсез балаларны да гел күз угында тотарга, гаиләләре белән танышырга, кирәксә, ярдәм итәргә туры килә – югыйсә урам хәзер үзенә суырып алачак. Аларны мәктәп бакчасына, теплицада эшләргә чакыра Гөлия апалары. Җир эшен үзе дә бик ярата, авыл кызы бит ул. Җәйге ялларын гел бакчада үткәрә, кызлары белән иртә яздан кара көзгәчә яшелчә-җимеш, чәчәкләр үстерәләр. Сирәк килеп күренгән Фәрит җыйнак кына итеп өй төзетте, рәхәтләнеп яшәргә була хәзер. Эштән соң кайчакларда үзе дә бакчага кайткалый, әнисен дә алып килә. Тик ул башка орбитада әйләнә иде инде.

Сәүдә өлкәсенә курьерлык итү кызык икән. Кибет директорлары арасында кемнәр генә юк! Бик кәттә, майлы күзле, хәйләкәр, шактый чибәр, төзәнгән һәм мода белән генә киенгән кыю ханымнар, әфәнделәр арасында бер гүзәл Фәритнең игътибарын аеруча җәлеп итте. Бакыр төсендәге калын кызгылт-сары чәчләрен биек итеп өеп куйган, шундыйрак төстәге затлы йон костюмының түшенә алтын брошка кадаган, нечкә билле, калку күкрәкле, иреннәре тулып пешкән чия сыман, яшел сөрмәле күзләрен тутырып серле генә карап куя. Ә тулы төз аякларында биек үкчәле йомшак күн итекләр: әйтерсең ул мода журналларыннан төшкән дә монда килеп утырган. Фәрит аннан озак кына күзләрен алалмый торды. Исеме җисеменә туры килеп торуын әйт син аның, Гүзәл исемле икән яшь ханым! Сәүдә хезмәткәрләре көнен бәйрәм иткәндә якыннанрак таныштылар. Табигать кочагында оештырылган бәйрәм инде тәмамланып килә, халык төркем-төркем булып таралыша башлаган иде. Үзләре өчен корылган чатырда берничә пар бик матур утырдылар. Коньяк тәэсиреннәнме, Фәрит бу чибәркәйгә гашыйк булуын сизми дә калды. Бар да шул көннән башланды. Көндезләрен аны күрергә тырышты, төннәрен уеннан чыгара алмады – әллә берәр сихри көче бармы икән соң? Юк сәбәпне бар итеп Гүзәлгә шалтыратты, кичке ашка ресторанга чакырды. Бер көнне ул, узып барышлый, аны әнисе янына алып керде. Хәдичә апа, аларны күргәч, барын да аңлады... Хәйләкәр, шомарган, тыштан ялтырый... Улының, гаиләсен калдырып, Гүзәл фатирына күчәргә уйлавын, хатынның тәртипсез үсмер улы да булуын белгәч, килененә мөнәсәбәтен үзгәрткәндәй:

– Матур чәчәк яхшы җимеш бирми ул, улым! Үз кызларың бик итагатьле, тәртипле. Хатының да уңган, ялгышма! – дип әйтеп карады, тик эш узган иде инде. Фәрит, гаиләсен алдап, сөяркәсе белән Ялтага ук китеп барды. Көннәрдән бер көнне өйләренә кайтып, кием-салымын җыя башлавы балаларына да, Гөлиягә дә аяз көнне яшен суккан кебек тәэсир итте. Җыенды да машинасына утырып китте...

– Сөеклем! Мин синең өчен таулар күчерергә дә риза! – диде Фәрит яшь хатынга. Бергә яши башлагач, Гүзәлне өрмәгән җиргә утыртмады. Хатынның фатирын шәп йортка алыштырдылар. Хатын-кыз теләсә, таш кыялар аша да үтә бит ул: оста иде Гүзәл, иркәләп, җайлап кына иренең яңа машинасын үз исеменә яздырды, улын аның фамилиясенә күчертте. Рамилнең наркотиклар кулланганын баштан иренә сиздермәде. Безне капчыкка ничек кенә яшерсәң дә, капчыкны тишеп чыга бит ул! Фәрит сизгәндә, эш тирәнгә киткән иде инде.

– Рома! – диде әни кеше, коньяклы стаканын алдындагы кечкенә өстәлгә шудырып, – беркая бармыйсың! Синең мәктәпне тәмамлап чыгасың бар! Укы, укып бетергәч, теләсәң нишләрсең!

PRESSA.RU

Рамил әнисенә нәфрәт тулы күзләре белән карады да өстәл тартмасыннан кирәк кадәр акча алып, ишекне шапылдатып ябып чыгып китте. Өч көннән соң кайткан малай үз бүлмәсенә кереп бикләнде. Бала хәсрәтен басарга дип, Гүзәл еш кына шешәгә үрелә башлады.

– Сөеклем, син алай күп эчмә әле, безгә бер малай алып кайтырга кирәк!

Фәрит кызларын исенә төшерде: әти дип йөгереп торган балалары сагындыра башлаган иде, әбиләре чакырып очраштырды аларны. Тик кечесе генә аны кочаклап, алдына менеп утырды. Фәрит кызларының хәлен сорашкан булды, бүләкләр алырга акча бирде: укытучы хезмәт хакына бернәрсә дә алып булмаганын белә бит ул! Чыгарылыш сыйныфында укыган олы кызы акчага кагылмады да, ә әтисе аңа күпме кием, акча кирәк буласын уйламады. Рамил яңа әти белән сөйләшмәсә дә, Фәрит мәгариф бүлегендә эшне җайлады: юньләп укырга йөрмәгән егет тә мәктәпне тәмамлап, өлгергәнлек аттестаты алды.

Икенче елны Гүзәле ирен шатлыкка күмде: бишенче дистәгә чыккач, Фәритнең улы туды! Тупырдап торган таза, матур малай! Бәхет өчен тагын ни кирәк!

– Сөеклем, кунак җыеп бәби ашы үткәрик! Рестораннан килеп өстәл әзерләрләр, мин сөйләшеп куйдым.

Кунаклар Фәритнең җитеш тормышын күреп «аһ» иттеләр. Бигрәк тә әнисе, авылдан килгән абыйлары, институтта укып чыккан дусты Ирек, йортка, андагы байлыкка исләре китеп, музейда йөргән кебек йөрделәр. Утыз икесе тулган хатын егерме яшьлек кебек – үзе чибәр, ә горур Фәрит сөеклесеннән бик канәгать иде.

Сәламәтлеге яхшы булса да, дүрт кенә ай имезде баласын Гүзәл: түшләрем сузыла, тирем шәлперәя кебек сылтаулар табып, фитнес-клубка йөри башлады. Шушы яшьтән нишләп әле өйдә бикләнеп ятарга тиеш ди ул?

– Фәрит, безнең бүген девичник! Саунада җыелабыз, син иртәрәк кайт, матурым, яме!!

Ул еш кына дуслары белән очрашты, күңелле бәйрәмнәрдән калмады, эчеп кайтса да, иренә белдермәскә тырышты. Рамил аларны ташлап чыгып киткән иде инде. Тик ул эшләргә дә, укырга да теләмәде, кайдадыр югалып йөрде.

Фәрит кайтып кергәндә, ми тартмаларын зыңгылдатып бәби елый иде.

– Һай, улым, нәрсә булган минем бәләкәчемә, нишләп шулай елыйсың инде? Тамагың ачтымы әллә?

Бала караучы хатын баланың ашамавын әйтте дә өенә ашыкты. Авырып киткән баланы әтисе ярты төнгә кадәр күтәреп йөрде.

– Нишләп бик озак юынасыз, сөеклем? Мин нишләргә белмим, әллә ашыгыч ярдәм машинасы чакыртыйкмы? Шамилнең температурасы бар!

– Алып китәргә теләсәләр? Үзең барып ятсаң, чакырт!

Шунда Гөлиясен исенә төшерде Фәрит. Аның балалар өчен үлә язып торуын, авырсалар ничек дәвалавын уйлады. Чын әни шундый буладыр да инде! Ах, ялгышты бугай ул... Матур тормыш ничектер тоныкланып киткәндәй булды... Бала йоклап киткәч тә тирә-юньдәге күренешләргә, тавышларга, хәрәкәтләргә бернинди игътибар бирмичә озак утырды ул.

* * *

Рамилнең передозировкадан үлүенә әнисенең артык исе китмәде. Шамиле мәктәптә укый иде инде. Эчүгә сабышканы өчен, үзен кибет директоры вазыйфасыннан алдылар.

«Әни, безгә килеп тор әле, балага да, Гүзәлгә дә күз-колак булыр идең», – дип, Фәрит әнисен чакырып карады, тик Хәдичә апа картайган, оныгына ярдәм итәрлек түгел шул инде. Юлдан чыккан исерек киленне дә һич күрәсе килеп тормый. Күрше-тирәнең гайбәтләреннән гарык булса да, үз фатирында яшәп калды.

Тагын бер ел гомер үтте, хатыны, аның кайчандыр сөекле Гүзәле эчкече иде инде. Нишләргә соң? Аны туктатып булмый. Артык ирек бирү шулай бозды бугай аны. Бер көнне саунада исерек Гүзәлнең үле гәүдәсен таптылар. Фәрит эшеннән китәргә мәҗбүр булды.

– Улым, Шамил! Без бер-беребезгә ярдәм итеп, киңәшләшеп яшәргә тиеш!

Әти кеше һаман яхшыга өметләнә иде.

– Я никому ничего не должен! – дип кенә җикеренде малай. Наркотик дигән зәһәр агуның тәмен ул да белә иде инде.

Фәритнең, башын иеп, Гөлия янына, балалары янына кайтасы, гаепләрен танып, алларына тезләнәсе килде. Ләкин арада – мәңге узып үтәлмәс киртәләр, өзелгән кыллар, чишелмәс төеннәр иде.



Рәсем: Наталья Васильева

ҮЗЕ ФАНИ ДӨНЬЯДАН КҮЧЕНГӘННЕҢ СОҢЫНДА ДА ШОМЫРТ КЫЗЛАРЫ, АК ЧӘЧӘКЛӘРЕ БЕЛӘН СЕРЛӘШЕП, АНЫ РӘХМӘТ БЕЛӘН ИСКӘ АЛЫРЛАР! ДОГАЧЫЛАР БУЛСА...

Асия СӘГЫЙТОВА

ҖИРДӘГЕ ЭЗЛӘР

Догачы булыр балаң юк икән, синең исемеңне зурлап искә алырлык күркәм гамәлләрең халык күңелендә калырга тиештер инде. Ә бит ул күркәм гамәл дигәнең гап-гади генә, әмма халыкка кирәкле бер эш булырга да мөмкин. Мәчет салдыру, мәдрәсә ачу кебек бинаһая чыгымлы гамәл булуы да, китап язу, җыр чыгару кебек илһам җимеше булуы да мөһим түгел. Фәкать күңел сафлыгын чагылдырган, ихлас башкарылган булуы да җитә ул гамәлнең.

Шул – Кояш апаны сорап шалтыратудан соң уйландым мин бу турыда. Уйлану өчен икенче бер сәбәп тә бар иде. Гомер буе Балык Бистәсе районында яшәгән, шул районда эшләгән Мирзаҗан исемле кешенең кинәт вафаты хакында ишеттем. Мин дә белә идем аны. Шофер булып эшләде. Ул районга йомыш төшеп барганда аңа утырган идем берчакны. Казан белән Балык Бистәсе арасы йөз чакрымлап булыр. Шул араның һәр карышын яттан белгән бу кеше бик әйбәт экскурсовод булган иде минем өчен.

«Асия апа, бу юлларны мин үзем салдым бит, шуңа күрә яхшы беләм. Мин моннан күземне йомып та уза алам, – дип сөйләгән иде ул, үзе салышкан юлларның сыйфатына сөенеп. Казан–Балык Бистәсе арасы, юлы белән генә түгел, бәлки озата барган табигате белән дә соклангыч. Ә Мирзаҗан өчен ул табигать, гомумән дә, мавыктыргыч китап кебек иде бугай. «Менә бу турыда урманга кереп китсәң, чикләвек куаклыгына килеп чыгасың. Мәктәптә укыган елларда шул чикләвеклек мине киендергән иде, – дип сөйләп китте ул. – Килгәндә карап чыккан идем, быел да чикләвек мул булыр кебек. Чикләвек өлгергән вакытта яшен була күрмәсен инде. Алайса, яшен чикләвекнең төшен ала». Мин ул кадәресен аңлый алмыйм инде. Чикләвеккә йөргәнем булмады. Ничек булган төшне яшен алсын инде? Ә менә сүз каен җиләге, мәтрүшкә темасына күчкәч, колагымны тырпайтам инде мин. Балык Бистәсе – экологик яктан чиста төбәк. Шифалы үләннәрне моннан җыясы иде бит! «Асия апа, кайда нәрсә үскәнен миннән дә яхшы белүче булмас. Чиста төбәк дисез дә бит, алай да юл буеннан кирәкмәс. Җыелышып килегез вакыты җиткәч, үзем күрсәтермен. Әнә теге ауган каеннарны күрәсезме? Шул тирәдән узган ел Наилә белән (хатыны) ярты сәгатьтә бер чиләк каен җиләге җыеп алган идек. Боерган булса, быел да җиләк уңар. И-и, юл буе тула инде каен җиләге сатучы кызлар белән! Иллә дә ямьле була соң инде».



Шулай алдан ук хозурланып сөйләгән иде ул алда көткән, хәзер инде үтеп киткән җәйне. Шул җәй белән бергә үзенең дә гомере үтеп китәрен адәм баласы белми шул. Ярый әле белми! Җиләгә дә, мәтрүшкәсе дә җыелды быелгы мул җимешле җәйнең. Суыткычны ачкан саен җәй нигъмәтләрен барлыйм. Ачкан саен Мирзаҗан дигән матур күңелле кеше искә төшә. Һәм күңелдә бер сурәт яңара.

Шул чагында, юлда кайтып килгәндә диюем, машина йөртүчем кинәт кенә машинасын туктатты да: «Асия апа, бераз туктап алыйк әле, мин урманга кереп чыгыйм әле», – диде дә, агачларны аралап кереп китте. Мин аптырап утырып калдым машинада. Шактый гына торып чыкты бу. Мирзаҗан бәхетле иде!

– Исәннәр! – Минем сораулы карашымны тотып алды. – Юл салдык дип сөйләдем бит әле. Юлны бит аны туры алып барырга тырышасың. Ә юл салучылар юлына бик матур шомырт куагы чыгып баскан! Шау чәчәктә! Хәтта бульдозер йөртүче шактый каешланган агай да төрәнен шып туктатты. Җыелыштык та шомырт тирәли әсәрләнеп торабыз. Йә, нишлибез инде синең белән, Шомырт кызы? Сүз берләшкәндәй, куакны туфрагы-ние белән кубарып алдык та урмандагы бер матур аланга хасиятләп утыртып куйдык. Шуны карап чыктым әле. Шау чәчкәдә! Ярый әле әрәм итмәгәнбез гүзәлкәйне.

Яхшылык кешенең үзен дә матурлата. Әнә ничек балкыган Мирзаҗанның йөзе! Эчтән яктырган. Әгәр ул: «Бервакыт шушы турда бер куянны таптаткан идем», – дип сөйләгән булса, мин аңа, мөгаен, нәфрәт белән караган булыр идем. Ә болай ул мине сокландырды. Шушы бер гамәле өчен генә дә бу кеше Табигатьнең олуг рәхмәтен казанган лабаса.

PRESSA.RU

Яран гөл

Тәрәз төбем минем берничә,
Тәрәз саен яран гөл үсә.
Ал яраннар кебек алсулана,
Бәгырькәем мине күрде исә.

Кайгы-хәсрәтем дә юк сыман,
Йөрәккәем яна ут сыман.
Газаплана иртә-кичләрен,
Әйтә алмыйча йөрәк хисләрен.

Яннарыма гына килсә иде,
Сөям сине, бәгърем, дисә иде.
Күзләреннән алмый күзләрем,
Әйтер идем йөрәк серләрем.

Тәрәз төбем минем берничә,
Тәрәз саен яран гөл үсә.
Ал яраннар кебек алсулана,
Бәгырькәем мине күрде исә.



Резеда
ВӘЛИЕВА

АЛ ЯРАННАР КЕБЕК АЛСУЛАНА...

Мин Казаннан еракта, Башкортстанның Салават районында үскән кыз. Беренче май көнне туганга, әтием Тәфкалүн башта Майя дип исем куярга теләгән. Шулай да озак уйланып йөргән әле. Ахырдан бер фикергә килеп, әнине туктаткан: «Ашыкмыйк әле, әнисе, куймыйк аны. Мин кызыбызга матур исем таптым – Резеда!» – дигән. Уфа якын булса да, мәктәп елларымда ук бөтен җаным белән Казанга ашкындым. Ул әллә нинди бер хыял шәһәре, шагыйрьләр шәһәре, олы бер мәркәзебез булып күңелне яктыртып торды. Тукай дип, Казан дип үлдем инде гел! Шулай булмыйни! Укытучы әнием Мәрзия Нигъмәтҗан кызы үзе дә шигъри җанлы, нечкә күңелле, чәчәкләргөлләр ярата, матурлыкка табына торган кеше иде бит. Тукайның бөтен шигырьләрен яттан белә, шуларны үзенчә көйгә салып, җырлап та йөри. «И балалар, сез беләсезмени соң Тукайны?!» – дип, шагыйрь турында дәреслекләрдә язылмаганнарны да безгә җиткерергә тырыша. Шундый гаиләдә үс тә, иҗат, шигырь дөньясына тартылма ди!

1947 ел. Мин – Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеге студенты. Группабызда 13 кеше: биш кыз, сигез егет. Гариф Ахунов, Фәрит Хатыйпов, Марат Сәгыйтовлар... Тулай торакта Сания Сибгатуллина белән бер бүлмәгә эләктек. Мин шигърият дөньясына гашыйк, ул җырлый. Мин дә җырлыйм анысы, ләкин Саниянең тавышы бөтенләй башка – чылтырап чыга...

Икенче курста укыганда бер егетнең үземә игътибар күрсәткәнен тоям. Зәңгәр күзле, аксыл йөзле, үсмер малайлар кебек юка гәүдәле бу егет бездән бер курска түбәнрәк укый. Бик тырыш, тыйнак, әдәпле. Мине күрсә, кыпкызыл була! Күзләрен яшерә. Әллә кыенсына, әллә ошата... Берзаман дуслашып ук киттек. Тулай торактагы бүлмәбезгә килеп, мине танцыга чакыра башлады. Яраткан музыкабызга рәхәтләнеп биибез. Ул мине очыртып кына йөртә! Арабызда дуслыктан гайре бернәрсә дә юк, билгеле. Җитмәсә, минем инде егетем дә бар. Төзелеш-архитектура институты студенты Фаршат белән йөрибез. Ул озын буйлы, чибәр, гармунда бик шәп уйный...

Ә теге егетнең мине күргәч кызарулары ошый инде менә! Бер көнне бүлмәбезгә кайткач, шул хакта шигырь юллары белән генә әйтеп салдым:

«Ал яраннар кебек алсулана,
Бәгыркәем мине күрде исә...»

– Кем ул? – ди Сания.

– Бер егет инде, – дим. Хәер, Сания кем икәнен болай да белә инде.

Уйнап кына әйтелгән сүзләрдән шигырь юллары туды. Мин «Яран гөл» дигән беренче шигыремне яздым. Аны көйгә салып, җыр итеп җырлый башладылар. Берзаман Сания очып кайтып керде: «Пединститут кызлары гел синең җырны җырлыйлар икән! Качып кына сине күреп тә киткәннәр инде!» – ди.

Ә кыюсыз егетем бик ярдәмчел дә булып чыкты әле.

– Резеда, диплом темаңны алдыңмы әле? – дип гел кайгыртып тора.

Ә мин һаман сузып йөрим. Йә темасы ошамый, йә җитәкчесе күңелгә ятмый.

– Өлгерермен әле, ашыктырма! – дим, исем китмичә генә.

– Юк, борчылам, Резеда. Тотынырга вакыт бит инде. Әйдә, үзем табам теманы, – дип өтәләнә.

Һәм миңа... «Тукай һәм балалар әдәбияты» дигән теманы тәкъдим итә! Тукай булсын да, ничек ошамасын инде! Ул бу тема буенча үзе эшләгән, шактый мәгълүмат туплаган икән инде. Мине булачак җитәкчем Якуб Агишевка да алып китте, әллә никадәр материаллар да бирде. Иренмичә, булышып, язганнарымны карап, тикшереп тә чыга әле. Эссе, кояш кыздыра. Утырабыз, утырабыз, язабыз, сызабыз... Китапларны бер читкә куеп, Идел буена төшеп китәсе, табигатьтә йөрисе килә. Ә ул мине мактыймактый эшләтә.

Шушы тынгысыз егет булышлыгы белән группадагы биш кыз арасыннан бер мин генә «биш»кә яклап чыктым дипломны!

Миннән битәр сөенүе, күзләр очрашкач, оялып кызарулары гел күз алдында тора...

...«Яран гөл»не бүген яңа көйгә, яңа җырчылар җырлый инде. Салават, Зәйнәп Фәрхетдинова, Алия Исрафилова... Сәүбән Чуганаев көенә җырлана торган «Яран гөл»не иң беренче булып Зәйнәп Фәрхетдинова тамашачыга җиткерде. 1994 елда уздырылган «Уятмакчы булсаң халык күңелләрен...» дигән телевизион конкурста Салават башкарган «Яран гөл» исә беренче урынга лаек дип табылды. Шул җыр өчен тавыш биргән тамашачылардан студиягә өем-өем хатлар килгән. Телевидениедән шалтыратып, мине дә бүләкләү тантанасына чакырдылар. Зал шыгрым тулы. Күрәм, баласын җитәкләп, аптыраган кыяфәттә берәү йөри. Рәтләр тирәсеннән бер үтте, ике... Абау, Сәүбән Чуганаев бит бу! Танып алып, үз яныма дәштем. «Урын юк...» – ди, боегып кына. Шаккаттым. Җыры җиңгән өчен аны бит зурлап чакырырга, дәрәҗәле урыннарга утыртырга тиешләр иде югыйсә. Зәйнәп чакыруы буенча гына килгән икән шул көйнең авторы. Оештыручыларның башы җитмәгән анысына... Сәхнәгә чакырып, миңа сүз бирделәр. Арабызда җырның композиторы да утырганлыгын әйттем. Ул да, сәхнәгә күтәрелеп, котлау сүзләрен җиткерде. Салаватны чәчәкләргә, бүләкләргә күмделәр. Хәтта машина да бүләк иттеләр! Күңелле күренеш, әлбәттә. Әмма Сәүбән Чуганаев өчен йөрәгем әрнеп калган иде ул чакта...

Кара, «Яран гөл» җыры әллә никадәр истәлекләр яңартты күңелдә! Яшьлек еллары, оялчан егет, аның миңа эшләгән яхшылыклары...

...Ә минем тәрәзәләрем гөлләргә күмелеп утыра. Арада ал яраннар да бар. «Резеда гөлләре», диләр аларны.

PRESSA.RU















МИНЕМ ЖУРНАЛИСТИКАМ

КӨТЕЛМӘГӘН ВАКЫЙГАЛАР. ШӘҺӘРЛӘР. ИЛЛӘР... МИНЕМ ЖУРНАЛИСТИКА ШУЛАР БЕЛӘН ШЫПЛАП ТУЛГАН. СЕЗГӘ ТӘКЪДИМ ИТӘ ТОРГАН ЯЗМАМ ШӘХСИ ТОЕЛСА ДА, АНДА ИЛ ТАРИХЫ, ҖӘМГЫЯТЬТӘГЕ ҮЗГӘРЕШЛӘР ЧАГЫЛАДЫР. ХӘЗЕР МЕНӘ ИСКӘ ТӨШЕРӘМ ДӘ...

Эльмира ЗАКИРОВА

Журналист, профессия булудан бигрәк, яшәү рәвеше ул. Познер белән тулысынча килешәм. Журналист эше миңа дөньяда иң шәбе тоела! Син – һәрчак яңалыклар, вакыйгалар үзәгендә. Син – туктаусыз эзләнүдә. Ерак юллар, кызыклы кешеләр белән очрашу-аралашулар, редакциядә генә була ала торган үзенә бер мохит... Берничә шәп юл язар өчен, өч тәүлек буе йокламау турында ишеткәнегез бармы? «Трое суток шагать, трое суток не спать ради нескольких строчек в газете...» дигән җыр безнең турыда инде ул! Төн буе йокламыйча язып, соңгы ноктаны куйгандагы рәхәтлекне инде бернәрсә белән дә алыштырып булмый!

Беренче көннәремнән үк кызыклы вакыйгалар, иҗат белән тулы дөнья, хыял утравы булган икән ул минем журналистикам. Балалар журналына мәктәпләр, пионер тормышы бүлегенә редактор итеп эшкә алдылар. Командировкалы, летучкалы, марш-маршрутлы, слетлы, пионер учаклы редакция тормышы башланды. Кайларда гына булмыйсың! Кемнәр белән генә күрешмисең! Кылт итеп «кукурузник»та Чирмешәнгә очуым искә төште. Галстугын, дәреслекләрен алып чыгу өчен янып торган өйгә кереп һәлак булган кыз турындагы хат мине тетрәндергән иде. Тиз генә юлга җыендым. Тирән, үтемле язма килеп чыкты. Ошаттылар. Хәзер инде ул вакыйгаларга башкача бәя биреп утырам. Кирәк иде микән мондый мәкалә? Идеяләр өчен үзеңне корбан итү?.. Бүгенге акылым белән мин башкачарак язар идем... Балалар журналында эшли башлаганда ук мәкаләнең исеме интригалы булырга тиеш икәнен дә, тапталган сүзләрдән качарга кирәген дә гел искәртеп тордылар. Якын кешеләреңә сөйләгән кебек гади тел белән язарга кирәген дә шунда өйрәттеләр. Кыскасы, бүген сез – якын кешеләрем, ә мин сөйлим...

МӘСКӘҮ. ВКШ. 1986 ЕЛ. Баш редактор Роза Туфитуллова мине ВКШга укырга җибәрде. ВЛКСМ Үзәк Комитеты каршындагы Югары комсомол мәктәбен шулай дип йөртәләр. Мин латыш кызлары белән бер бүлмәдә. Таныштык. Лиена Суна – «Драугс» журналында, Илзе Бригадере «Пионерис» газетасында эшлиләр. Эстония, Грузия, Украина, Әзәрбайҗан, Казакъстан, Үзбәкстанның пионер журналлары редакторлары белән бергә лекцияләрдә утырабыз... «Тормышыбыздагы реформаны иң элек балалар күңелендә үткәрергә кирәк...» «Балалар журналисты үзе бер профессия...» «Гади итеп язарга, ясалмалыктан качарга...» – диләр. Ораторлык осталыгы дәресендә сәясәтчеләрнең сөйләү манерасын өйрәндек. Ялкынлы сүзләре белән миллионнарны әсәрендергән Куба лидеры Фидель Кастро чыгышының язмасын тыңладык. Юмор белән сөйләргә яраткан Черчилль дә, көчле тавышлы Троцкий да шәп ораторлар булган...

Белмим, нигәдер Мәскәүдә тизрәк уйлый, җәһәтрәк кыймылдый башлыйсың. Кулымнан килсә, журналистларны берничә көнгә генә булса да Мәскәүгә җибәрер идем! «Комсомольская правда», «Пионерская правда», «Московский комсомолец», «Учительская газета» журналистларыннан мастер-класслар алабыз. Беркөн безгә «Литературная газета»дан Юрий Щекочихин килде. Павел Гутионтовны инде «Комсомолка»ның «Алый парус»ы аша беләбез! «Пионер», «Мурзилка», «Вожатый»ларда летучкаларда катнашабыз. Балалар өчен «Миша» дигән өр-яңа журнал чыга башлаган әнә. Безнекеләр, Михаил Горбачев хөрмәтенәдер, дип фаразлый.

Кызык, Чабаксардан килгән Анатолий Смолин (чуашларның күренекле шагыйре, соңрак Президент Николай Федоровның ярдәмчесе – *Э. З.*), Алматыдан килгән журналистлар минем белән рәхәтләнеп татарча сөйләшәләр! Абхазиядән килгән Геннадий Аламия (хәзер ул күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, барыбызны да Сухумига кунакка чакырды. Атаклы язучылары Фазил Искәндәр турында сөйләде. «Сандро из Чегема»ны укыйсым килеп, ымсынып калдым.

Мәскәүдә темплар, тизлек, масштаблар – башкача.

РИГА. КОЛЛЕГАЛАР ЯНЫНДА. 1986 ЕЛ, ИЮЛЬ. Казаннан Ригага самолетлар оча. Ләкин Аэрофлот кассаларында беркайчан да билет булганы юк. Илдар (ирем) «Комсомолец Татарии» газетасында эшләгәч, комсомол өлкә комитеты броне аша гына билет ала алды. Хатларда Лиена белән редакциядә очрашырга килешкән идек. Дүрт сәгатьләп очып, 12 дә инде Баласта дамбис урамындагы матбугат йортына килеп җиттек. Нәкъ Казандагы газета-журналлар нәшрияты бинасы кебек биек. Без – Казансу яры буенда, алар – Даугаванықында. «Драугс» («Дус») та шунда. Тик... редакциядә кеше юк, диделәр. Бераздан, ашыгып, Лиена килеп керде. «Бездә редакциядә утырып эшләмиләр. Кемдер очрашуда, кемдер материал әзерли... Кабинетта бер дежур журналист кына кала», – диде ул. Лиеналарга киттек. Аларда кофе эчәбез. Кызыл өстәл-урындыклар, кызыл суыткыч, кызыл люстра... Тагын да тәмлерәк булсын өчен, кухняны шулай «кызартканнар». Лиена муеныма гәрәбә муенса кидерде. Илзе килде. Аннары телевидениедә эшләүче Харалдс, пионер газетасы корреспонденты Вилнс... Менә шундый журналистлар компаниясе. Лиенаның әтисе Ян Британс (Латвия Журналистлар берлеге рәисе, республиканың иң зур газетасы «Циня»ның баш редакторы) безне Юрмаладагы дачаларына чакырган. Латыш милли ризыкларын әзерләр өчен Лиена алданрак китте. Без Харалдс белән электричкада бардык. Булдури, Дзинтари, Майори дигән станция исемнәре колакка кереп кала. Тәрәзәдән кергән наратлар хуш исе, Балтыйк диңгезе һавасы борынны кытыклый. Харалдс русча үзенә бер акцент белән (Раймонд Паулсныкы кебегрәк) сөйләп бара...

Лиена белән Харалдс безне Сигулдадагы «Турайда» замогына, ачык һавадагы этнография музеена да алып бардылар. Рига урамнары буйлап таныштырып йөрүне белеме буенча тарихчы Вилнска тапшырдылар. Гаҗәп: Вилнс безнең Казан ханлыгы чорын да, Сөембикә ханбикә язмышын да бик яхшы белә!

Фото: шәхси архивтан һәм интернеттан.

PRESSA.RU

ЛЕНИНГРАД. ГКЧП. 1991 ЕЛ. Журналистлар гаиләсендә ил гизү, дөнья күрү – беренче планда! Улыбыз Алмазга 9 яше тулган көнгә бүләк әзерләдек – Ленинградка алып барырга булдык. Казан–Ленинград поезды таң алдыннан китәчәк. 20 августта иртүк шунда булачакбыз! Петродворец, Эрмитаж, Пушкин музее, Петропавел крепосте, Адмиралтейство... У-уу! Карап чыгарга бер атна түгел, ай да җитмәс! Без әле кайда тукталасыбызны да белмибез. Вокзалда фатир тәкъдим итүче бюродан адреслар алып була, диделәр.

Көн үзәгендә поездда шомлы тынлык урнашты. Радиодан ишетелгән «ГКЧП, Форос, Горбачев авырый», дигән сүзләр колакны торгызды. «...Президент вазыйфаларын Янаев башкара...» – дигән яңалык ишеттек. Мине аңлаталмаслык курку биләп алды. Ленинградка барып җитәбезме, юкмы? Кире әйләнеп кайта алабызмы, юкмы? Алда ниләр көтә? Шундый шөбһәле уйлар һич баштан чыкмый. Хөкүмәттә СССР Президенты

Журналист вакыйгалар үзәгендә булырга тиеш!

Михаил Горбачев алып барган үзгәртеп кору сәясәтенә каршы төркем оешкан. Пассажирлар шулай ук аптырау хәлендә. Бер ир-ат Илдар янында тукталды да, «Перестройка. Гласность. Демократия» дигән язулы футболкасына ишарәли: «Моны салып ташла!» – ди: әллә чынлап әйтә, әллә шаярта. «Юк, салмыйм! Миңа ошый», – ди Илдар да.

...Иртүк килеп төшү белән гадәти шәһәр ритмын тоеп – трамвай-троллейбуслар йөреп тора, халык каядыр ашыга, милиция берәүне дә туктатмый – бераз тынычландым. Дәүләт перевороты озакка бармас, бәлки?

Без урнашкан фатирда телевизор эшләп утыра: «Лебединое озеро»ны (инде ничәнче кабат!) әйләндерәләр икән. Фатир хуҗасы, өлкән яшьтәге ханым: «Көне буе аккошлар күрсәтәләр», – дип сукрана, ГКЧПны сүгә... Кичтән Ленинград телевидениесе буенча мэр Анатолий Собчак ГКЧПга каршы чыгыш ясаган. 20 августта иртән халыкны «Дворцовая площадь» мәйданына протест митингына чакырган. Әйберләрне урнаштырдык та шунда чыгып чаптык! Ха-лы-ык!!! Йөз меңләптер! Собчак сөйли, ләкин аны ишетәбез генә, шулкадәр халык арасында күреп тә булмый. СССРда бердәнбер Ленинград телевидениесе генә беренчеләрдән булып 19 августта путчка каршы чыккан, диләр! Гэкачепистларны «мәктәп дәресләрен начар үзләштергән «өчле» капчыклары» дип атадылар, ил тарихын да белмиләр, дип көлделәр. Кәеф күтәрелеп китте. Илдар Казанны, редакция телефонын җыя. (Невский проспектында адым саен шәһәрара телефон-автомат будкалары. – *Э. З.*)

– Люда, редактор белән тоташтыр тизрәк! Газетага хәбәр бар. Бүген Ленинградта ГКЧПга каршы протест митингы узды!..

– Ул бүлмәдә юк... Сөйләшер микән әле ул... Бу темага сөйләшмибез...

Чыбыкларның аргы башында каушаган тавыш чак ишетелде, аннан өзек-өзек гудоклар китте. (Кайткач белдек: ул көннәрдә редакцияләр аптыраште калган. – *Э. З.*) Ә ике көннән «Вечерний Ленинград» газетасы «С победой, соотечественники!» дип язып чыкты.

Туры Казанга кайту планыбыз да үзгәрде. Шушы хәлләрдән соң ничек инде танклар, БТРлар узган Мәскәүне, снарядлар тигән Ак йортны күрми кайтасың?!

ЭРФУРТ, ГЕРМАНИЯ. 1995 ЕЛ. Республикабызның газета-журнал редакторларын Германиянең Эрфурт шәһәрендәге F+U фирмасы кабул итте. Икътисадның һәм матбугатның базар мөнәсәбәтләренә күчүен өйрәнергә бардык. «Тюрингер Альгемайне» газетасына электрон почта аша дөньяның иң зур телеграф агентлыкларыннан көн саен меңләгән хәбәр, фотолар килеп тора. Безне аяктан егарлык яңалык, әлбәттә, тираж иде. Газета Тюрингиядә 300 мең тираж белән тарала! Газетаны иртәнге 6 да ук инде өйләргә китереп бирәләр. Бу эшне студентлар, укучылар, пенсионерлар башкара икән. Редакциянең 5 меңләп газета таратучысы, бик зур автомашиналар паркы бар. Төнге 11 нче яртыда газета басыла башлый, ә 11 гә инде типография капкасына беренче машиналар килеп туктый...

Үзебез өчен кызыклы дөнья ачып кайттык Германиядән. Безне кабул иткән як саубуллашу кичәсенә чакырды. Шунда Татарстан Журналистлар берлеге рәисе Римма Ратникова (ул чакта «Молодежь Татарстана» газетасының баш редакторы да иде) немец телендә җавап сүзе белән чыкты!

СТОКГОЛЬМ. 1997 ЕЛ. Аны «Төньяк Венеция» дип тә йөртәләр... Йонлач эт кыяфәтле Скандинавия ярымутравында түбәдә яшәүче Карлсон, озын аяклы Пеппилар шәһәре Стокгольм урнашкан. Иртүк безне Стокгольм сәламләде... Тәрҗемәче-гид, елмаеп, ярда көтә. Шулай да беренче каршы алучылар – әрсез акчарлаклар иде. Алар – багана фонарьларында, челтәрле күперләрдә, яр буйларында... Объективны томшыгына ук терәсәң дә, кузгалырга уйлап та карамыйлар. «Мине төшер!» дигән кебек утыралар. Каян килгән фотомодельләр!.. Редакциягә баруыбыз турында да сөйлим әле. «Dagens Nyheter» – Швециядәге иң зур газеталарның берсе. «Көн саен 52 бит белән чыга. Штатта 250 журналист. Репортерлар уртача 20-25 мең крон хезмәт хакы ала. Маркетинг, реклама белән шөгыльләнүчеләр күбрәк тә ала», – ди газета редакторы Клас Баркман. Редакция урнашкан бинаның үзендә поликлиника, бассейн, ресторан... Эшләре бик соңга калучылар өчен кунып калырга бүлмәләр әзерләнгән. Газета чыгару төнге 2 ләргә кадәр сузыла, диләр... Зур офисларда журналистлар күпләп утыра. Кабинетлары компьютер залыннан пыяла стена, пыяла ишекләр белән бүлеп алынган. Көн саен иртән редакция хезмәткәрләре өчен алма, груша, виноградлар тулы кәрзиннәр куела икән биредә. Һәм түләүсез, ди...

МӘСКӘҮ. «КОМСОМОЛЬСКАЯ ПРАВДА», 2004 ЕЛ. Тагын әле шундый журналистика да бар – Президент турында яза торган. Кремльдә ниләр булган, башка илләрнең корольләре, әмирләре, президентлары белән нәрсә турында сөйләшкәннәр... Дәүләт башлыгын һәртөрле визитларда озатып йөри андый журналист. Кремльдә даими аккредитациясе булган, властьның иң югары даирәләренә үтеп керә алган журналистлар күп түгел. Алар җыенысы бергә «Кремль пулы»н тәшкил итә.
Без шундый журналист белән күптән таныш инде. «Комсомольская правда»да эшләүче Саша Гамов! 80 нче еллар ахырында Илдар «Советская Россия»дә стажировка узганда Гамов белән танышкан. Хәзер дә аралашып торалар. 2004 елда редакциябез белән Мәскәүгә «Ялкын» журналы юбилеен үткәрергә баргач (аның беренче саны Мәскәүдә чыга бит! – *Э. З.*), яшь журналистларыбызны Гамов белән очраштыру турында уйлана башладым: менә дигән мастер-класс! (Идеяне Илдар уйлап тапты, редакциягә дә ул алып барды. – *Э. З.*) Саша, теләгебезне җиткергәч, шундук риза булды.
Айрат белән Сөмбел барачак. Айсылу, Раилә, Рөстәм, Фәйрүзәләр Асадуллаев йортындагы бәйрәмне әзерли... Ә мин, «Комсомолка»да очрашу узасы сәгатьтә, Татарстанның Вәкаләтле вәкиллегендә булырга тиеш.

Правда урамы, 24 нче йорт, 6 нчы кат – безнекеләр «Комсомолка»да. Атаклы «Зәңгәр зал» бер якта кала...

Журналистларыбызга Александр Гамов сөйләгәннәр кызыклы фильм кебек күз алдыннан үтә. Кремль тормышы, пул журналистларының аралашу кагыйдәләре, Ельцинның сайлау алды турнесы («Ял көннәренең бик сирәк эләгәсенә күнегергә туры килә. Ашыгыч рәвештә чакырып алып, командировкага җибәрүләренә дә... Кайчак форс-мажор шартларда бөтенесен хәл итәсең...»), Алматыда Путин белән тау чаңгыларында шуу, Президентның 3000 метр биеклектән сәгатенә 100 километрдан артык тизлек белән төшүе. («Президент артыннан уктай атылган идем, ярый әле сакчылар туктатты, юкса, егылсам, сөякләремне дә җыеп алалмаслар иде...») Путин килгәч, эш стиле үзгәрү («Президент тәүлегенә 20 сәгать эшли. Ул тәүлекләр буе ашамый да йөрергә мөмкин... Безнең мәкаләләрнең язылышы да үзгәрде. Хәзер бездә эчке «цензор» бар...»).

ДАГОМЫС. «БӨТЕНРОССИЯ-2006» ЖУРНАЛИСТЛАР ФЕСТИВАЛЕ. Казанда әбиләр чуагын яңгырлар алыштырган чак. Ә мин 26 градуслы эсседә диңгезгә йөгерәм... Пляж тулы журналистлар! Барыбыз да Сочига, Дагомыска журналистлар фестивalенә җыелдык. Россия Журналистлар берлеге рәисе Всеволод Богданов һәркемне үз итеп сөйләшә. Казаннан икәнебезне белгәч, «Марсель Зариповка сәлам әйтегез!» – диде. (Алар «Советская Россия»дә бергә эшләгәннәр. – *Э. З.*).

Дулкыннар шавын ишеттерер өчен телефоннан Казанны, редакция номерын җыям: «Кара диңгез сәламли сезне!» – дим. Тиздән мастер-класслар башланачак.

«Московский комсомолец»ның күзәтүчесе, бүгенге армиядәге хәлләр турында язучы, Уставтан тыш мөнәсәбәтләрне кискен тәнкыйтьләүче Юлия Калинина, Шереметьевлар династиясе турында фильм төшергән Фекла Толстая, Россия журналистикасы легендасы Леонид Шинкарев (Раджив Ганди, Фидель Кастродан ничек интервью алуын мавыктыргыч итеп сөйләде!), атаклы Константин Симоновның улы, журналист һәм режиссер Алексей Симонов...

МӘСКӘҮ. ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫ. 2010 ЕЛ. Казаннан Мәскәүгә – поездда, «Комсомольская»дан «Охотный ряд»ка – метрода. Һәм Дәүләт Думасы. Яшьләр тематикасының матбугатта чагылышы турында парламент тыңлауларына ашыгам. «Шаги к успеху» тапшыруларын алып баручы депутат Алина Кабаева уздыра аны. «Хәзерге телевидениегә сорауларым бик күп. Ни өчен һаман шоу-бизнес, скандаллар анда? Тәрбияви функциясен ник югалткан? Журналистлар ник этиканы онытalар?» – дигән иде ул үзе үткәргән семинарларда.

...Экспертлар арасында кемнәр генә юк! ЛДПР фракциясе лидеры Владимир Жириновский, МГУның журналистика факультеты президенты Ясен Засурский, Россия Президенты киңәшчесе Михаил Федотов, «Эхо Москвы»ның баш редакторы Алексей Венедиктов...

«Яшь кеше стройдагы шөреп булмасын...»

Җайлы гына башланган чыгышларны РЕН ТВдан Марианна Максимовская кинәт өзде: «Бүген яшьләр аудиториясендә хурлыкка каласың килмәсә, «рухи кыйммәтләр», «демократия» сүзләрен әйтмәвең хәерлерәк», – ди. Зал гөж килде. Һәм китте, китте!.. Кайнар бәхәсләр, кыю фикерләр... Блокнотка төрткәләп барам.

«Идеаллар юк. Күпләрнең чиновник буласы килә». (В. Жириновский.)

«Һәр өченче яшь кеше елга бер (!) китап укый. Һәр икенче яшь кеше «Газпром»да эшләргә хыяллана». (Д. Дондурей.)


«Яхшы укый торган малайның текстында 70 орфографик хата. БДИда әзер җавапларга гына төртеп утыру түгел шул бу! Яшьләребез начар түгел. Ләкин алар надан». (Я. Засурский.)

Яшьләр сәясәте, дигән булабыз. Ә талантсызларга нишләргә? Икенче сорт итеп караргамы? Бәлки, алар ялтырамый торган талантлар?» (М. Слободская.)

«Массакүләм мәгълүмат чаралары яшьләребезне тәрбияләргә тиеш, ләкин, ни кызганыч, бүген алар бу функцияне үтәми». (Я. Засурский.)

...Менә шулай. Яшьләр сәясәтендә сәясәт күбрәк, яшьләр азрак... Уйланып утырдым. Нәтиҗә ясарга тырыштым. Яхшы журналист үзе сайлаган миссиягә һәрчак тугры калырга тиеш. Бу – кешеләргә гаделлек тантанасын урнаштырырга булышу, дөньяны аз гына булса да яхшы якка үзгәртергә омтылу.

Мин менә шундый журналистика ягында!



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз:
www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU

Әллә язмыш, әллә ялгыш...

Мәдинә АВЗАЛОВА

ЙӨЗЕННӘН БЕР ГЕНӘ МИНУТКА ДА НУР СҮРЕЛМӘГӘН, ЕЛМАЮ КИТМӘГӘН, ДӘРТЕ ТАШЫП ТОРГАН ГАҖӘЕП БУ ХАНЫМГА СОКЛАНМЫЙ МӨМКИН ТҮГЕЛ...

Фото: Ксения Богданова

Язмышыма бер көн сорау бирдем,
Нигә һаман мине сыныйсың?
Ә ул миңа көлеп җавап бирде:
«Сабыр бит син, бәләм, сынмыйсың».

Алар концерттан чыкканда, төн уртасы җитеп килә иде. Егет сөйгәнен үзләреннән җиде чакрымдагы авылга озата китте. Юлның яртысына җиткәч, туктады да әйләнеп кызга карады: «Ярый, мин киттем, – диде ул, – син инде хәзер үзең дә кайтып җитәсең...» Шаяртадыр дип уйлады кыз. Ләкин егет, кырт кына борылып, авылы ягына атлады. Ул җиде төн уртасында, җиде юл чатында басып калды. Әлбәттә, кыз кайтып җитте, курка-курка гына булса да кайтып җитте. Әмма бу төн, егетнең бу кыланмышы аның йөрәгенә мәңгегә уелып калды...

Мең мәшәкатьләре, борчу-хәсрәтләре белән ашыгайөгерә узып барган гомернең инде офыкларга китеп барышы. Шуннан бирле 30 еллап вакыт үтеп киткән. Ничәмә-ничә язлар, көзләр, кышлар килеп киткән. Ә ул һаман, кайта-кайта, күңел төпкеленә үк яшеренгән әлеге вакыйганы искә төшерә. Ни өчен әле шул чагында ук гыйбрәт булырдай шушы очрактан нәтиҗә ясамады? Ни өчен авыз ачып, бер сүз әйтмәде, үпкә белдермәде. Ни өчен тәкъдим ясаганда, кире какмады. Чөнки ул аны яратты. Кискен, сәер гадәтләрен дә белә иде. Мәхәббәт хатын-кызны телсез итә, хисле, канатлы итә. Ә Ясирә – сәнгать кешесе. Белгечлеге буенча түгел, җаны-күңеле тоташ сәнгать дәрьясында аның. Күктә йөзә торган, кешеләрдә бары яхшыны күрә торган андый бәндәләргә бу тынгысыз, бу әрсез тормышта икеләтә сыналасы, икеләтә кыйналасы. Язмыш бу!

Аның әтисе дә авылда данлыклы бер гармунчы, әнисе Рәйсә апа – җырчы. Берсе уйнап, икенчесе җырлый башласамы?! Бер-бер артлы үсеп килгән дүрт кыз һәм бер малай да әти-әнисеннән калышмый. Әнә кызлар гармунда уйнарга өйрәнеп килә. Әнә алар дүртәүләшеп авыл сәхнәсен гөр китерә. Үсеп җитеп, шушы оядан канат чыгарган кызларны авылдашлары, түземсезләнеп: «Сабантуйга Мансур кызлары кайтыр микән?» – дип, аларның җырлавын көтә торган иде.

Дүртенче сыйныфны үз авылында тәмамлаган кыз укуын башта Сәрдекбашта, аннары Сәрдек урта мәктәбендә дәвам иттерә. Әйбәт укыган, өздереп җырлаган, төс-кыяфәте дә бик килешле кызны озата кайтучылар, аның белән танышырга теләүчеләр аз булмагандыр дип уйлыйм. Тик ул инде күптән үзенә тиң санаганны йөрәгенә кертеп куя. Егет урта мәктәптән соң армия хезмәтенә алына. Ясирә исә Алабуга педагогика институтына укырга керә.

– Сәнгатькә гашыйк кеше укытучы белгечлеген сайлыймы?

Әйләнеп чыга алмаслык зур, заманча җиһазландырылган йортның иркен залындагы йомшак диванга утырышып алабыз да ашыкмый гына үткәннәр турында гәп куертырга керешәбез.

Ул дөрес әйтә. Элек, хәер, хәзер дә иң дәрәҗәле, иң кирәкле һөнәр дип йөртелә бит ул. «Укырга кая керәсең?» – дигән сорауга җавап, гадәттә, бертөрле була торган иде: «Кая, кая?! Әлбәттә инде, укытучылыкка...» Егет – армиядә. Ул – институтта. Солдатны хезмәткә озатканда да әллә ниткән купшы сүзләр әйтелмәде. «Мин сине көтәрмен», дигән вәгъдәләр дә булмады. Күзгә-күз генә караштылар да шуннан барысы да аңлашылды. Соңыннан, аерылышкач, хатлар да йөргәндер, җылы сүзләр дә әйтелгәндер анысы...

– Институтны тәмамлап, Купка авылында укытып йөргән чагым, – дип искә ала артта калган ул елларны әңгәмәдәшем. – Егетем армиядән кайтуга ук миңа тәкъдим ясады. Мин ике дә уйламадым, шундук риза булдым. Эш шуңа бара иде ич инде. Аннары башка кешегә кияүгә чыгуны күз алдына да китерә алмадым. Үзем сайлаган, үзем көтеп алган... Бәхет шулдыр, дидем.

Аның борчулары, миңа күчеп, җанымны телгәләде...

Нәрсә ул бәхет? Ул нинди була? Бу сорауга берәү дә төгәл-ачык кына җавап бирә алмас иде. Кемдер өчен ул – карьера, кемдер өчен – зур акча, кемдер өчен – газиз бала, якыннарыңның сәламәтлеге... Ә Ясирә өчен бәхет ул ирең белән бер сулышта сулау, бер-береңнең күзенә карап яшәү, бер-береңне ярты сүздән аңлау. Һәм, әлбәттә инде, өч баласының исәнлеге-саулыгы. Мин аннан: «Бәхетлеме син?» – дип сорамадым. Ишеткәннәремнән соң сорамадым.

Адәм баласы үзенең пары белән туа, диләр. Шул тиңеңне табасың икән, син бәхетле, тапмыйсың икән – бәхетсез. Сирәктер ул үз ярын эзләп тапкан кешеләр. Андыйлар олыгайгач та бер-берсенә игътибарны, кызыксынуны, кайгырту дигән нәрсәне югалтмыйлар. Урамга да алар җитәкләшеп чыга. Мин үзем дә шундый парларга артыма борыла-борыла карыйм – нинди бәхетлеләр! Темадан читкә китеп булса да, бер танышымның хәйран калып сөйләгәннәрен искә төшерәм: «Европа буйлап сәяхәткә чыккач, юлдашларыбыз арасыннан бер парны күзәттем, – дип сөйли ул. – Олы яшьтәгеләр үзләре. Ире хатынын бик кадерли: башыннан бүреген, өстеннән пальтосын салдыра, чәчләренә кадәр тарый. Сорадым шунда: «Әллә яңа өйләнештегезме? Мөнәсәбәтләрегез искитәрлек», – дидем. Хатын шул чагында: «Безнең инде җиткән ул-кызларыбыз бар. Бер-береңә игътибар – гадәти нәрсә, шулай булырга тиеш», – дип гаҗәпкә калдырды». Ни өчен мин боларны сөйлим соң әле?! Ә, әйе, Ясирә ханым да бу хакта сүз чыккач: «Казанга концертларга еш йөрим. Фойеда җитәкләшеп йөргән, тамаша барышында бер-берсенең колагына нидер пышылдаган ир белән хатынга сокланып карыйм», – дигән иде.

Әйе, шулай булырга тиеш. Акны – ак, караны кара дип күрергә күнеккән Ясирә ханымның холкы – турыдан. Дөньяда булмаган юк-бар сүзләрне, кем әйтсә дә, җөпләп утыра торганнардан түгел. Шулай да тәмам

PRESSA.RU

аңлап бетерә алмаган иренә 30 ел гомерен багышлаган бит әле ул. Үзе дә: «Яратышып яшәдек», – ди әнә. Ышанып әйтә. Сөйләвенә караганда, матур башланган, бай-мул тормыш белән дәвам иткән гомерне чәлпәрәмә китерүче сәбәпләр җитәрлек булган югыйсә. Синнән башка сулыш та ала алмас сыман тоелган иреңнең көннәрдән бер көнне сулга каерылуы, яман гадәтләре белән теңкәгә тиюе, дистәләгән еллар дәвамында ир туганнарының кредитын түләп җәфалануы... барысы, барысы да аның башыннан кичкән.

Хатын-кыз барына да түзә ул: нахакка әйтелгән авыр сүзләргә дә, югалту ачысына да, хыянәткә дә... Нигә түзә?!

Хәер, әңгәмәдәшем болар турында сөйләргә яратмый. Ире белән бергәләшеп ни рәвешле эшмәкәрлеккә кереп китүе, балалар үстерүе хакында гына рәхәтләнеп, теләп сөйли.

– Сигез ел Кукмараның 2 нче урта мәктәбендә татар теле фәнен укыттым, – дип дәвам итә ул сүзен. – Яратып укыттым. Ә ирем ул чагында Манзарас авылында пекарня сатып алып, үз эшен башлап җибәргән иде. Бервакыт эштән кайтты да әйтә миңа: «Эшеңнән кит, миңа ярдәмче кирәк», – ди. «Мин – укытучы бит, эшмәкәр түгел. Акча саный белмим», – дим. «Өйрәнерсең...» – генә диде. Башка сүз куертып тормадык. Ир әйткәч, эшлисе. Мәктәбемне калдырып, шунда күчтем. Озак ияләштем дип әйтә алмыйм. Кеше белән тиз аралашучан мин. Шундук ипи пешерүче кызлар белән дуслашып киттем. Кызлар хәзер инде гел минем янда. Бер-бер сүзләре, үтенечләре булса, минем янга киләләр. Ирем карап-карап йөрде дә: «Нигә алар гел синең янда? Нигә алар гел синнән сорыйлар?» – дип аптырата башлады.

Шулай итеп, менә инде 19 ел ул «Манзарас күмәче»н пешерә. Эшмәкәр! Хәзер Ясирә Мансур кызы Гарифуллина үзе үк җитәкче дә. Чөнки берникадәр вакыт эшләгәннән соң, булдыклы ире тарала башлаган азык комбинатына барып керә. Шунда яңадан үзенең эшен көйләп җибәрә. Иң әүвәле, хатынын калдырып, икенче эшкә китеп бара. Аннары... өйдән үк чыгып китә.

– Иремә ышана идем. Кайдадыр кем беләндер бутала дип, башыма да китереп карамадым. Ә ул йөргән икән. Хатын иң соңыннан белә дип, тикмәгә әйтмиләр. Шулай да шикләнә торган идем, чөнки соңгы вакытларда гел бәйләнде. Йә теге, йә бу ярамый аңа. Йә һич нигезсез көнләшкән була – тавыш чыгарырга җай эзли. Сорадым шул чагында: «Нигә бер дә юкка җәберлисең? Торасың килмиме әллә минем белән?» – дип. Ул дәшмәде, ләкин әкренләп әйберләрен алып чыгып китә башлады. Ә бер көнне миңа әйтте: «Мин чыгып китәм. Хәзер инде үзең генә яшәп кара. Тормыш сындырачак әле сине...» Кычкырып елыйсым, нигә шулай дип әйтәсең, ташлап китүеңә мин гаеплемени, дип сорыйсым килде. Әйтмәдем. Ул китте, мин калдым. Болын кадәрле йортта берьялгызым торып калдым. Балаларымның һәркайсының үз тормышы. Алар – Казанда. Олы улым Искәндәр белән киленем Илсөя – дин юлында. Әйбәт кенә эшләре бар. Уртанчы кызым Илүзә – инглиз теле белгече. Ул хәзер КФУда укыта. Кияүдә инде, оныгым Кәрим белән кунакка гел кайтып йөриләр. Гомумән, шимбә-якшәмбе өй эче гөрләп тора. Балалар барысы да кайта. Кече кызым Гөлүзә банкта эшли. Таянычларым алар минем. Картайган көндә кемгә сөяләсең? Шуларга инде...

«Күзгә чыгып киткәненә алты ел була», – ди ханым. Саный, димәк, оныта алмый. Ә бәлкем, хыянәтен оныта алмыйдыр. Чыгып китүгә үк 23 яшьлек бер рус хатынына өйләнеп куйсын әле? Хатын-кыз өчен моннан да газаплы, моннан да рәхимсез каты җәза бар микән дөньяда? «Сынырсың», – диделәр аңа. Ул сынмады. Моның ише сынауларга, чыннан да, күпләр бирешә. Чыннан да, сынып төшә. Тик ул андый түгел. Аның ирләрнеке сыман нык холкы, хатын-кызларга гына хас нечкә күңеле, ә иң мөһиме: балалары – алтын баганалары бар. Һәм тагын аның зур юанычы, адашып калырлык хәтәр юллардан алып чыгардай шөгыле бар: ул – сәнгать кешесе! Әнә хәзер дә, тәрәзәгә томырылып кояш нурлары караган бер мәлдә, якты-чиста, зәвык белән бизәлгән өй эчен моңга, әйтеп бетергесез сагышка күмеп, җыр яңгырый. «Кем шулкадәр өздергеч итеп җырлый? Нинди җыр бу?» – «Мин җырлыйм, – дип гаҗәпкә калдыра Ясирә ханым. – «Җыр белән яшим» дип атала. Илгиз Зарипов аны Галиәхмәт Гатин сүзләренә язган. Әйе, матур җыр. Минем халәтемә туры килә торган җыр. Мин аны сәхнәләрдә җырлыйм. Халык та бик ярата бу җырны». Аның өстәлендә – Роберт Миңнуллин, Шәмсия Җиһангирова шигырьләре. Ул аларны ача да укый, ача да укый. «Кешеләргә, якыннарыма кирәкле кеше булып яшисем килә», – ди ул һәм:

«Куркам бары беркемгә дә
Кирәгем калмавыннан», – дип, Фәнис Яруллинны да искә төшереп ала.

Әллә язмыш, әллә ялгыш адәм баласын бер белмәгән сукмакларга алып кереп китә. Әнә шулай, һич көтмәгәндә, җиде юл чатында ташлап калдыра... Ташлап калдыра да гомер буе үкенерлек гамәлләре белән уңлы-суллы яңаклый. Тугач та маңгайга язып куелган язмыштан узмыш юк, диләр бит. Тик кем ничек уза бит аны?! Менә кайда хикмәт!

Ясирә ханым җырлар белән шыплап тутырылган блокнотын ача һәм укый башлый. Мин дулкынланып тыңлыйм. Ул укыган шигырь юллары һәркайсыбызга кагыла шикелле:

Язмышыма тагын сорау бирдем,
Күп калдымы әле түзәсе?
Ул, уйланып, миңа җавап бирде:
«Гомер буе, балам, түзәрсең».

«МИН ҖЫР БЕЛӘН ЯШИМ...»



«Мин бу көнне шундый көттем!» – дип килеп керде ул редакциябезгә. Оренбург өлкәсенең Матвеевка районы, Иске Әшер авылында яшәүче Шәһәргөл апа МОСЫЙФУЛЛИНА – журналыбызның якын дусты. Моңарчы бер-беребезне читтән торып кына белә идек, ниһаять, якыннан танышу да насыйп булды.

Хәер, ул журналыбыз хакында болай да бөтенесен белә иде инде. Гомере буе алдырган «Сөембикә»се бит! Ә менә без аның турында күп нәрсә белдек. Башта – үзе сөйләгәннәрдән, аннары – җырларыннан, шигырьләреннән. Хәния Фәрхи, Динә һәм Рафаэль Латыйповлар, Зифа Нагаева һәм башка күп кенә күренекле артистларыбыз да таныр аны. Танымый ни, Иске Әшергә концерт белән килгәч, кунакханәгә җибәрмичә, зур агач йортына алып кайтып кунак итә, кара мунчасын ягып сөендерә торган Шәһәргөл апалары ла ул!

Исеме... Иң элек исеме җәлеп итте безне. 1948 елда Ташкентта дөньяга килгән кызга 47 нче елда туып, озак та тормый вафат та булган туганының исемен бирәләр – Шәһәргөл. «Шуңа күрә үтә бәхетле булганмындыр мин», – дип елмая ул үзе боларны сөйләгәндә. Аннары тавышы гашыйк итте. Ялындырып тормады – башта берне, аннан тагын берне, тагын-тагын – җырлады да җырлады. Ә без онытылып китеп тыңладык. Тиздән 70 яшен тутыра дип тә әйтмәссең – тавышы күкрәп чыга әле Шәһәргөл апаның.

Кем белә бит, бәлки, 1963 елда Казан театр училищесына имтихансыз гына кабул ителгәч тә, башкалада укырга калган булса, бүген Шәһәргөл Мосыйфуллина исемле бик данлыклы артистыбыз булыр иде. Әтисе рөхсәт бирми шул, артист эше эшмени ул янәсе. Кызның, җырлау хыялын күңеленә бикләп, әтисенә буйсынмый чарасы калмый. Әтисе Габдрәхим – аның өчен төп кеше, төп терәк бит. 3 яшь тә 8 айлык вакытында әнисенең кире Ташкентка китеп барганын, китүчеләр утырган ат арбасы артыннан үкси-үкси йөгергәнен дә хәтерли әле ул.
Үги әнисе Вәдиганы да, үз баласыдай күреп тәрбияләгәне өчен, чиксез хөрмәт белән искә ала. Тик әти... Әти – башка, аның урыны түрдә.

Әтисенең сүзен тыңлап, туган авылы Бәкердә (хәзер яшәгән Иске Әшереннән 30 чакрым ераклыкта гына анысы да) сыер саварга кала Шәһәргөл. Шушы урында аның күзләре очкынланып китә. Мәхәббәт тарихына килеп җиткәнбез икән ләбаса! «17 яшем тулгач, район үзәге Матвеевкага Сабан туена бардым. Марат исемле егет көрәшә, мин сәхнәдә җырлыйм. Бер күрде дә: «Сеңелкәш, мин сине бүген алып кайтып китәм», – диде. Ярар, Марат абый, бик чибәр икәнсең, алып китәрсең, дидем. Алып кайтып та китте. Шул көннән башлап сыер саварга башка җибәрмәде инде, рәхмәт төшкере», – дип сөйли Шәһәргөл апа. Маратының гына гомере кыска булып чыга.
Аның вафатына да 24 ел икән инде. Өч бала тәрбияләп үстергәннәр: Гөлсара, Алимур, Гөлнара.

Бүген Шәһәргөл апа балаларының, 5 оныгының, 1 турунының бәхетенә сөенеп яши. «Туганнарым, балаларым – минем бәхетем», – дип яратып сөйләп кенә тора.

Тагын бер нәрсә яшәргә көч бирә аңа – җыр. Театр училищесына укырга бара алмаса да, җырдан аерылмый ул. Шәһәргөл апа – бүгенгәчә Иске Әшер клубы мөдире. Анда хезмәт куя башлаганына да 20 ел инде. Яшьләр белән бергә концертын, спектаклен дә куя, җәйге озын көннәрдә клубында төнге икеләргә хәтле дискотека оештырырга да авырыксынмый. Әле йөгерергә дә чыга икән. Кышын исә – чаңгыда. Кирәк булса, шпагатка да утырып күрсәтәм, дип тә гаҗәпләндерде. Берүзе генә яшәсә дә, йөзләп кош-корт та тота... Һәм көн саен, үкчәле туфлиләре белән, кәс-кәс атлап, клубка – яраткан эшенә бара.
Җыр аны яшәтә...

Фәнзилә МОСТАФИНА

PRESSA.RU




Фото интернеттан алынды

Татарстаннан мең чакрым ераклыкта чын татарча Сабантуй гөрли. Зөлфия юлдашлары белән, бик мавыгып, күккә ашкан озын багана башына әтәч алырга дип үрмәләүчеләрне карый иде, чәчләре чалара төшкән таныш түгел ир-егет: «Зөлфия! Зөлфия, син... Сез түгелме соң бу?» – дип дәшкәч, бермәлгә аптырап калды.

Люция ФАРШАТОВА

ЯШЬЛЕКТӘН КАЙТАВАЗ

– Әйе, бу мин. Ә Сез... Наил?! Син?

– Әйе-әйе, Наил! Таныдыгыз, рәхмәт. Ничәмә-ничә еллардан соң нинди очрашу, ә?! Бу якларга ничек килеп чыктыгыз? Ә, әйе бит әле, син... Сез журналист халкы кайларда гына йөрмисез!

– Шулайрак, чынлап та, мин биредә эш буенча. Әйдә, тәкәллефсез генә – син дип кенә сөйләшик, ярыймы? Ә син үзең соң ничек бу якларда?

– Дуслар янына кунакка дип тә, эшләрем буенча да килгән идем. Беләсеңдер, мин бит хәзер туган ягымда яшим. Үз бизнесым бар.

– Зөлфия ханым, кызлар-егетләр, әйдәгез, сезне чәйгә дәшәләр. Аннары кайту ягына кузгалабыз, диләр юлдашларыгыз, – бәйрәмдә Татарстаннан килгән журналист һәм артистларны озатып йөрүче урындагы җитәкчеләрнең берсе аларны ашыктыра башлады.

– Зөлфия, бер генә минутка... Ничек инде, 35 елдан соң очраштык та бер сүз дә сөйләшми аерылышабызмыни?

– Шулай булып чыга инде. Хуш!

– Юк, тукта, телефон номерыңны булса да калдыр, зинһар.

– 35 ел буе кирәкмәгән телефоным сиңа нигә кирәк булды әле, Наил? Очраштык, хәл-әхвәлләрне белдек һәм шуның белән шул.

– Ашыкма әле, зинһар, Зөлфия, хәзер барысын да аңлатам. Бер генә минутка тоткарлан. Йә инде, эчмәгән чәеңме?

– Аңла, мин үзебезнекеләрдән кала алмыйм.

– Кал, зинһар, минем дә эш белән берничә көннән Казанга барасым бар...

– Юк-юк. Син нәрсә сөйлисең? Ху-уш!

Наил, Наил... Яшьлекнең иң самими вакытында күңелдә нииндидер билгесез һәм иләсләндергеч хисләр уяткан, үрсәләндереп елаткан, төн йокыларын качырган спортчы егет Наил. Менә, ичмасам, очрашу бу! Кайда диген әле – Казаннан мең чакрым ераклыктагы Федераль Сабантуйда! Сөйләшеп тә булмады, җитмәсә, их!

Автобус җай гына туган якка тәгәри. Төн буе юлда килеп, аннары көне буе Сабантуйда йөреп арыган

юлдашлары йокымсырап та китте әнә. Ә Зөлфиянең, киресенчә, йокысы качты, хәтер йомгагы кирегә сүтелә башлады.

...1972 елның июль уртасы. Мәктәпне тәмамлаган классташларның укырга керергә дип кайсы кая таралышкан чагы. Хыяллар зурдан: бар да институтларга керерләр дә зур – укыган кеше булырлар, иншалла. Зөлфия дә үзе хыялланган Казан дәүләт университетына юл тотты. Район үзәгеннән ары чыкмаган, томшыгын ярып, якты дөньяга яңа баккан чебеш баласыдай кызларын әти-әнисе 200 чакрымдагы Казан кадәр Казанга берүзен ничек чыгарып җибәргәннәрдер, Зөлфия хәзер дә аптырый. Бигрәк тә үзсүзле, тәвәккәл иде шул, шуңа ышанганнардыр инде.

Университетны тиз тапты үзе, тик анда документлар тапшыру өчен генә дә су буе чират икән. Арыса арыды, ачыкса ачыкты, кичкырын тапшырды ул документларын. Әллә кайдагы Каравай бистәсенә барып, туганнарын да тапты. Ә имтиханнар әле августта гына икән. Кыз икенче көнне күптән күрергә хыяллланган Казан Кремлендә, Бауман урамында йөргәннән соң, кичкә таба автовокзалга ашыкты. Килсә, бүгенгә билетлар сатылып беткән. Инде нишләргә? Касса янында аның кебек яшьләр кайнаша. Ни күрсен, узган ел гына алар мәктәбен тәмамлаган күрше авыл кызы Нурия дә шулар арасында. Зөлфия, бәхет кошын күргәндәй, аның янына томырылды. Кыз һөнәр училищесында укый, практика вакытында сөт-май заводында эшли икән. Сменадан чыккан да, алда өч көн ялы булгач, авылга кайтып килергә уйлаган.

– Борчылма, хәзер автобус шоферы белән сөйләшеп карыйбыз, кайбер чакта утырта алар, – ди Нурия. Ни әйтсәң дә, бер ел буе шәһәрдә яши шул, рәтен белә. Тик бу юлы шофер артык пассажирлар алырга риза булмады, юлда гаишниклар күп, ди.

– Ярар, иртәгә автовокзал ачылганчы ук килербез дә билет алып, кайтып китәрбез, – ди Нурия. – Син бүген кайда кунасың соң? Әйдә, безгә генә, Чуаштан кызы Халидә кичә үк авылына кайтып китте, аның караваты буш. Тик безнең фатир хуҗабыз бик кырыс әби. Син, бүлмәгә кергәч, бүтән чыгып йөрмәссең, яме.

Автовокзалдан ерак та түгел – Париж Коммунасы урамындагы өч катлы иске агач йортның беренче катында тавык кетәге кебек кечкенә генә бүлмәдә яшиләр икән Нуриялар. Тар коридордан шыпырт кына уздылар да, бүлмәләренә кереп бикләнделәр.

...Имтиханнар бирергә июль ахырында килде Зөлфия. Тулай торакка урнашып алгач, Казан белән танышырга чыгып китте. Көтмәгәндә-уйламаганда трамвайда Нуриялар очрады. Шаулашып-гөрләшеп эштән кайтулары икән.

– Карале, Зөлфия, синең белән бер егет кызыксына бит әле, – дип шаккаттырды кинәт Нурия. – Халидә янына килгәч, минем альбомдагы фотоңны күрде дә, таныштыр да таныштыр, ди. Курыкма, әйбәт егет ул, Халидәнең авылдашы. КАИда укый.

– Ой, егетләр кайгысымыни миндә, имтиханнарга әзерләнәсем бар.

Шулай да ул Нуриягә тулай торак адресын әйтте. Университетта консультацияләр башланды. Аннары беренче имтихан. Инша язып, хаталар күп ясадыммы икән инде, дип борчылып, бүлмәсенә кайтып керсә, бүлмәдәшләре аны бер егет эзләп килүен, кечкенә генә хат кисәге калдыруын әйтеп шаккаттырдылар. Хат ниндидер таныш булмаган Наилдән иде. Күрешергә теләвен әйткән, «Кольцо»га очрашуга чакырган.

...Имтиханын «дүртле»гә тапшыру сөенеченнәнме, кызыксынуы җиңдеме, свиданиегә барырга булды Зөлфия. Запискада язылган урында бер генә роза чәчәге тоткан озын гына буйлы егет басып тора. Башта ул аңа ерактан сынап карап торды. Әллә бармаска, борылып китәргәме дип тә уйлады. Тик кызыксынуы җиңде, барып дәште.

Егет тә дулкынланган иде, беренче мәлдә сөйләшеп китә алмадылар. Чәчәген дә әле бер, әле икенче кулына күчерде. Ялгыш сабагын сындырды да кызарып ук чыкты, аннары аны чүп савытына ташлады. Трамвайга утырып тулай торак ягына киттеләр. «Бәхетле» билет эләккәч, бераз сөйләшеп алдылар да тагын тындылар. Аннары Зөлфия, имтиханнарга әзерләнәсем бар, дип, тиз генә кереп китәргә ашыкты.

«Күңелгә әллә нинди серле кыз булып кереп калдың. Һәм мин сине еш искә төшерәм, Зөлфия».

Бигрәк сәер егет булып чыкты ла бу, сөйләшә дә белми, нигә дип очрашуга чакыргандыр, дип уйлады ул Наил турында. Мишәр егетләре бик усал һәм кыю дигән булалар тагын.

...Ул елны Зөлфия университетка керә алмады: 1 балл җитмәде, бер урынга дүртәр-бишәр кеше иде шул. Классташларына да бәхет елмаймады. Ләкин берничәсе, шул исәптән Зөлфия дә, алдагы елларда хыялларын тормышка ашырдылар. Ә аңынчы кайсы кайда эшләп тордылар. Зөлфия исә бик еракка – классташ кызы белән аларның кунакка кайткан туган тиешле авылдашларына ияреп, Урал якларына китеп барды. Тимер юллар төзүдә катнашты ул.

Алар тимер юл тупигында торган вагоннарда яшәделәр. Көндезләре исә полигонда – эштә уза. Бервакыт – кышның салкын бер көнендә көндезгә әбәт вакытында конторадан аларга почта китерделәр. Зөлфиягә дә берничә хат бар иде: әти-әнисеннән, дус кызыннан һәм... Наилдән. Хатлар берничә. Ул аларны авылга юллаган, әниләре исә – бирегә. Бер хатны ачты Зөлфия: аннан ниндидер порошок коелды. Икенчесен ачты: тагын порошок.

...Наилләр группасын хәрби лагерьга җибәргән булганнар икән. Өйрәнүләр вакытында бер яшь лейтенант, үзенең пистолеты белән мактанып, «салагалар»га оста-

PRESSA.RU

лыган күрсәтмәкче булган да, якынлашып килүче өлкән командирны күргәч, ялгыш атып җибәргән. Ул «җүләр» пуля Наилнең аягын яралаган – тубык сөяген чәрдәкләгән. Инде берничә ай госпитальдә дәвалана икән. «Уколлар, дарулар белән тәмам туйдырып бетерделәр, хәзер мин аларны эчмим дә инде, берничәсен сиңа «көчтәнәч» итеп җибәрәм», – дигән.

«Теге вакыт без синең белән җүнләп таныша-сөйләшә дә алмадык, оялуымнан әллә нишләдем мин ул көнне, – дип, бик мавыктыргыч башлаган егет хатын. – Югыйсә андый оялчан да түгел үзем. Әмма нишләптер мин ул көнне сиңа туры карый да алмадым. Бары синең бик тә горур икәнеңне генә аңладым. Мин сезнең тулай торакка икенче, өченче көнне дә, аннары да килдем, тик сине очрата алмадым. Укулар башлангач, сине университетка барып эзләп тә карадым, әмма кафедрада быел укырга кабул ителүчеләр арасында андый исем-фамилияле кешенең юклыгын әйттеләр. Димәк, язмышыма язмаган икән, дип, инде килешкән дә идем, беркөнне минем янга госпитальгә авылдашым Халидә белән синең якташың Нурия дә килгән иде. Ул синең, укырга керә алмагач, каядыр Урал якларына китүеңне әйтте һәм авылыгызның адресын бирде. Һәм менә мин сиңа хат язам. Бәлки, ул миннән бәхетлерәк булыр: сине эзләп табар. Әлбәттә, син инде мине күптән оныткансыңдыр да, егетең дә бардыр. Мин җебегән аркасында бигрәк әллә нинди булды бит безнең теге көнге очрашу, истә калырлык та түгел. Алай булса, хатларымны ертып ташла да оныт мине.

Юк-юк, күңел барыбер нәрсәгәдер өметләнә. Кош теле хәтле генә булса да хәбәр көтеп, Наил».

Наилне онытырга сүз бирде дә аның исемен йөрәгенең иң ерак почмагына яшереп куйды.

Чынлап та, Зөлфия ул берничә сәгатьлек очрашуны оныткан диярлек иде инде, хатларны укыгач, ничектер күңеле кузгалып алды. Инде өч айга якын диярлек госпитальдә ятучы егетне җәлләде һәм хат язып җибәрде. Шуннан ике арада хатлар йөри башлады. Наил дә аның кебек романтик булып чыкты. Хат аша әле киногa «чакыра», әле концертка. Аннары икенче хатында телевизор аша гына караган кинолары турында яза, «синең белән бергә карагач», эчтәлеген бик хәтерләмим дә, ди. Үз чиратында Зөлфия дә аны танцыларга, киногa «чакыра» башлады. Шулай итеп, берничә ай буе бик тә мавыктыргыч итеп хат аша аралашты алар. Соңгы хатларында Наил әле бер тапкыр да яратып карамаган кыз бала өчен бик тә тансык сүзләр дә яза башлады. Мондый сүзләрдән соң, җәйгә Казанга кайтып, укырга керергә җыенган Зөлфия очрашу мизгелләрен көннәрне санап көтә башлады.

Шулай итеп җәй җитте, Зөлфия янә Казанга кайтты. Документларын университетка тапшыруга ук ул, алдан килешенгәнчә, Наилнең апалары фатирына китте. (Әле култык таякларында гына йөрү сәбәпле, госпитальдән чыккач, Наил апаларында яши иде.) Кыңгырауга баскач, ишекне шактый ачмый тордылар. Аннары гына бер кыз ачты. «Син кем?» – дип сорады да, исемен ишеткәч, башта кызарынып китте, аннары, мыскыллы елмаеп, Зөлфияне Наил яши торган бүлмәгә алып керде. Наил дә, аны күргәч, бер агарып, бер кызарынып алды, күзләрен кая яшерергә белмәде. Зөлфиягә уңайсыз булып китте, күңелендә әле үпкә, әле ачу дулкыннары тибрәнеп алды. Наил бер сүз дә дәшми, аңа карап телсез калган, теге кыз да аларны ялгыз калдырырга ашыкмады. Зөлфия тиз генә хәл-әхвәл сорашып, күчтәнәчләрен бирде дә, саубуллашу ягын карады. Ишекне япканда гына Наилнең: «Зөлфия, туктале, син дөрес аңламадың», – дигән сүзләре генә ишетелеп калды.

Бик тә рәнҗеде ул чакта егеткә. Тулай торакка кайтып җиткәнче үрсәләнде. Наил исә тагын аның авылына хатлар язды, теге көнге күңелсез очрашу өчен гафу сораган, очрашыйк, аңлашыйк дип үтенгән иде. Ә теге кызның авылдашы, мәктәптә укыганда очрашып йөргән кызы булуын, күптән инде араларында берни дә юк икәнлеген, авылдаш кызның ул көнне әниләре җибәргән күчтәнәчләрне генә китерүен язган иде.

Ләкин киребеткән горурлыгы Наилнең аклануына ышанмады һәм Зөлфия аңа башка хат язмаслык усал итеп җавап язды. Егетем бар, дип тә өстәде. Араларны шулай кискен өзсә дә, ягымлы хатлары белән күңелнең бер почмагында урын алган иде инде Наил.

Кызыклы да, мавыктыргыч та студент тормышы башлангач, егетнең образы тоныклана төште, билгеле. Әмма Ходай аларны тагын бер очраштырды әле. Өченче курста укыганда аларның факультеты белән КАИ студентлары арасында дусларча футбол ярышлары булды. Ул ярышта Наил дә катнашты. Матч тәмамланганчы Зөлфиянең күзе егеттә генә булды. Ул да аны күрәдер, күзәтәдер кебек тоелды. Ярышлар тәмамлангач, ул ничек тә егет күзенә чалынырга тырышты. Менә күзләр очрашты, аларда әллә нинди очкыннар уйнап алды, әмма шулчак егетнең көчле кулларына бер кыз килеп асылынды. Моны күргәч, Зөлфия дә тиз генә үз командаларыннан бер егетне култыклап алды. Шулай итеп, юллар мәңгегә аерылды.

Инде менә бүгенге очрашу... Бәлки каласы булгандыр, бер-ике көнгә соңга калып кайтудан дөнья җимерелмәс иде әле, ди кузгалган күңеле. Син нәрсә, җүләрләндеңме әллә, акылыңа кил, син бит ир хатыны, балалар анасы, ди акылы.

Ул юл буе шулай үрсәләнеп кайтты. Азга гына йокымсырап киткән арада Наилне төшендә дә күрде бугай әле. Әллә юкмы?

Аннары да берничә көн буена әлеге очрашу исенә төшеп, күңелен ярсытып-уйнаклатып куйгалады әле Зөлфиянең. Тел очында исә һаман яшьлек кайтавазы булып бер җыр бөтерелде:

Яшь гомер бер узгач,
Кайтмый ул яңадан...



СӨНГАТУЛЛИНА Луиза

Казан дәүләт университеты.

Кияүдә. Ике кызы, оныгы бар.

Карьера: «Кайбыч таңнары» газетасы баш мөхәррире

Тормыш шигаре: «Гадел булуга, сабырлыкка ни җитә!»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Онык балдан татлырак!

Төнге сәгать өчләр тирәсендә телефоныма смс килеп төште. Үз-үземне кая куярга белмичә, бүлмәдән бүлмәгә йөреп йокы качкан төн иде ул. Кызым, Резедәм, бала тудыру йортында, аңарда – тулгак ачысы... Бар теләгем: исән-сау гына котылсын иде балакаем! Ниһаять, менә ул хәбәр: «Мин дә бүген синең кебек / Гамьнәргә тулдым, әни. / Мин сине яңа аңладым – / Мин әни булдым, әни!.» Шагыйрә Илсөяр Иксанова иҗатын ярата шул ул... Шул минуттан статусыбыз үзгәрде: дәү әти-дәү әни булдык! Балдан татлы Сәйдәбезне сөеп туя алмыйбыз. Бу җиһанга аваз салган һәр сабый шулай көтеп алынган булсын иде!


Солдат кайтты... 72 елдан соң!

Одноклассникидагы битемә Мурманск өлкәсенең Заполярный шәһәрендә яшәүче эзтабар Сергей Швецовтан хәбәр килде. Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган солдат Кәшәфулла Зәйнуллинның туганнарын эзли, сезнең районныкы булырга тиеш, ди. Аның фамилиясе уеп язылган портсигар тапканнар. Олы Урсак авылында яшәүче фермер Фариз абыйның да фамилиясе шундый булгач, кичке сәгать ун булуга да карамастан, шалтыраттым. Туганнар булып чыктылар! Портсигар салынган посылка Кайбычка килеп җитте инде. 9 Май көнне аны тантаналы төстә мәктәп музеена тапшырачакбыз.


Читтәге милләттәшләр безгә үрнәк!

Группадашым – Пермьнең Барда районында туып-үскән Нәсүр Юрушбаев инде күптәннән Германиядә яши. Режиссер, журналист. Үзган ел газетабызның электрон почтасына минем исемгә саф татар телендә хат язды ул. Командировкага җыенган чагым иде, бер соравына тиз арада җавап бирергә кирәк булгач, фикерләремне хезмәттәшемә әйттем дә, чыгып йөгердем. Ул Карагандада туып-үскән, татарча сөйләшсә дә, җавапны рус телендә язган. Икенче көнне почтаны ачсам, Нәсүрдән хәбәр килгән: «Нәрсә, Татарстанда яшәп, туган телеңне оныттыңмы әллә?» – дигән. Оялуларымны белсәгез иде!..

сөендерде







көендерде

Имтиханнар белән тормыш бетми

Имтиханнар чоры җитә. Чыгарылыш сыйныф укучыларының әти-әниләрен очратсам, сүз үзеннән-үзе БДИга барып тоташа. Балаларга караганда, алар күбрәк борчыла һәм өстәмә паника тудыра кебек тоела миңа. Кызым имтихан биргән елны, бу куркуны җиңәргә бик тә тәҗрибәле бер укытучының сүзләре ярдәм итте үзем. «Балаң мәктәптә ничек укыса, имтиханда да шул билгене алачак», – диде ул. Чыннан да, шулай булып чыкты. Балаларыбызны саклыйк дисәк, бәлки, безгә – әти-әниләргә башта үзебезгә тынычланырга кирәктер? Имтиханнан куркып, үз-үзенә кул салучылар быел булмасын иде инде!

«Ялкын»сыз балачак буламыни?!

Май – Татарстанда матбугат ае. Балачактан ук газета-журналлар укып, үзебезне киләчәк һөнәребезгә әзерләгән буын без. Беренче класстан алып унынчыга кадәр өебезгә «Ялкын» журналы, «Яшь ленинчы» газетасы килеп торды. Мәктәп укучысы булган һәр өйдә алдыралар иде аларны. Нинди генә эш белән мәктәпләргә барсам да, укучылардан балалар өчен чыгарылучы газета-журналларның кайсыларына язылулары турында сорашмый калмыйм. Әмма җаваплары сагайта шул...

Җир шарында тынычлык урнашырмы?

Кибетче Аннаның Кайбычка ерактан килен булып төшкәнен белсәм дә, кайсы яклардан икәнлегеннән хәбәрдар түгел идем. Беркөнне сөйләшеп киттек. «Украинадан мин, – диде ул. – Булачак ирем белән интернет аша таныштым да, тәвәккәлләп, кайттым менә. Татарстан турында ишетеп кенә белә идем. Улыбыз үсеп килә. Ә әти-әниләрем анда калды, алар яшәгән тирә тынычрак». «Сагынасыңдыр инде», – дим. «Сагынам, сүз дә юк. Әмма андагы мәхшәрне искә төшерсәм, үзәкләрем өзелә. Бер гаепсез халыкның каны коелганга җаным әрни. Ә монда – Россиядә безгә берни янамый, шулай булгач, сагынсам да түзәм».

PRESSA.RU



ИЛАҺИ НИЯТ КЫЛДЫМ...



Руслан
АХУНОВ

Барысы да Зәлиянең туган көненә бер ай кала башланды. Көтелмәгән бүләк белән сөендерәсем килә иде үзен, тик аның нәрсә булырга тиешлеген белмим. Колак чите белән генә хатынымның туган көнен өйдә түгел, ә кайда да булса башка берәр җирдә үткәрәсе килүен ишетеп калган идем. Әкияттәгечә «бар шунда – белмим кая, китер шуны – белмим нәрсәне», дигән кебегрәк баш ватып йөргән көннәрем. Шул вакыт күземә кредит картасы чалынды: анда минем бонуслар – бушлай мильләр шактый җыелган булырга тиеш бит! «Аэрофлот» офисында «әйе, шулай», диделәр – үзебез теләгән берәр илгә бушлай очып барып кайта алабыз икән. Ул көнне бәхет кошы тоткан кеше кебек очып кайттым да Зәлиягә: «Туган көнеңдә кайда буласың килә? Франциядәме, Италиядәме, бәлки, диңгез ярындадыр – сайла», – дидем. Уйлап та тормыйча: «Израильдә», – дип җавап бирде ул. Дөресен әйтим: шаккаттым. Аннан – сөендем. Минем өчен берьюлы ике куянның койрыгын тоту булачак бит бу: анда минем күптәнге дустым, элеккеге бас-гитаристым яши. Өйләнеп, шунда күчеп китте ул. Еш кына шалтыратып, кунакка чакыра. Сөйләшкән саен, киләм, дип вәгъдә бирәм. Менә бит нинди җай чыгарга тора!..

Моңарчы нигәдер бер тапкыр да әйткәне булмады: Зәлиянең бик күптәннән Әл-Акса мәчетен күрәсе, изге урыннарда буласы килә икән. Туган көнне – мәчеттә! Кызык... Өстәвенә, дустым Викторга да кунакка барабыз. Әйткәнемчә, террасасында куй итеннән барбекю ясап, мине сыйларга күптән хыяллана ул. Аннан Әл-Акса мәчетенә бәйле нәзерем дә бар бит әле минем.

Моңа кадәр Израильдә булганым бар иде барын. Экскурсия вакытында Иерусалимның гүзәл урыннарын өстән-өстән генә күрсәтеп чыгалар да – шуның белән вәссәлам. Дөрес, Вифлеемга да барып җиттем хәтта. Ә менә Әл-Акса мәчетенә керә алмадым. Койма аша аның алтын гөмбәзенә сокланып карап торганым әле дә хәтердә. Ул вакытта яшь идем әле, аңлап та җиткермәгәнмендер, ләкин әллә нинди бер хис күңелне бимазалап калган иде. Төрле диннәр кисешкән борынгы шәһәр уртасында, ниндидер тылсымга төренеп, вакытка буйсынмыйча, аерым бер дөнья булып утырган ул мәчет бүген дә күз алдында...

Билетларны җомга көнне иртән шәһәргә барып төшәрлек, җомга намазына мәчеткә өлгерерлек итеп алдым. Таныш хәзрәттән кайсы догаларны укырга икәнен сорадым, кайберләрен искә төшереп, хәтерне яңартып куйдым. Хәзрәт Әл-Акса мәчетеннән ерак түгел Ибраһим пәйгамбәрнең һәм тагын бик күп изге җаннарның каберләре бар икәнен әйтте. «Барып күрегез, бик изге урыннар», – диде.

Интернет аша гидлар эзли башладым. Мәчеткә гарәп гидлары гына алып керә ала икән, ә андыйларны табу катлаулы мәсьәлә булып чыкты. Нигәдер моңа борчылмадык, ничек тә хәл ителер әле, дидек.

Очар көн җитте. Аэропортта теркәлүебез булды, рейс бер сәгатькә тоткарлана, дип игълан иттеләр. Бер сәгать безнең өчен хәлиткеч булырга мөмкин: Мәскәүдә икенче очкычка күчеп утырырга өлгермәсәк... Көтәбез. Тыштан тыныч кебек күренсәк тә, эчтәге киеренкелек арта бара. Безнең белән Зәлиянең дус кызы Наташа да оча: мин дә, ул да үзебезне кая куярга белмибез, Уфадан очуның мәгънәсе булырмы, дип баш ватабыз. Бер Зәлия генә тыныч: «Ходай ни язса, шул булыр», – дип, исе китмичә генә тик утырып тора.

Мәскәүгә сәгать ярымга соңарып барып төштек. Чираттагы рейсыбызга өлгерү өчен аэропорт буйлап чабарга туры килде: самолет салонына иң соңгы пассажирлар булып аяк бастык.

Ура! Без – Тель-Авивта!

Кунакханәбез борынгы шәһәрнең уртасында ук урнашкан иде. Иртәнге бишкә килеп җиттек, безне исә, барлык отельләрдәге кебек үк, номерга көндезге 12 дән генә кертә башларга тиешләр. Әмма, ни гаҗәп, сәгатькә карап тормадылар, урнаштырдылар, өстәп түләгез дә димәделәр. Юлдан килгәнсез, ачыккансыздыр, дип, искиткеч тәмле иртәнге аш белән дә сыйладылар әле: төрле-төрле балыклар, дистәгә якын төрле сыр, салатлар... Тәкъдим иткән акчамны алмадылар, елмаеп кире кактылар. Вак нәрсәләр, әлбәттә, тик ничектер күңелдә эз калдыра һәм уйландыра. Дөньяга карашны үзгәртә.



■ Ул вакытта: «Бирегә кабат махсус киләчәкмен һәм мәчеткә керәчәкмен», – дип сүз биргән идем. Ниятемне чынга ашырыр сәгать сукты бугай...

Алдан ук белешкән гид белән очраштык. (Кызык, ничә еллар гид булып эшли, ә үзе иске шәһәр эчендә кунакханә барлыгын да белмәгән!) Болай үзе гаҗәеп ачык күңелле кеше булып чыкты. Бөтен диннәргә дә объектив караштa, һәркайсы турында искиткеч бай мәгълүматы бар. Без шунда ук таныш гидлары арасыннан гарәп милләтеннән булганын эзләвен үтендек, бик тә мәчеткә керәсебез килә, дидек. Ул кемнәргәдер шалтыратты, озак итеп сөйләште һәм, ниһаять, тапты.

Мәчеткә кереп, бер-ике рәкәгать намаз укый алсак, безнең өчен шул да зур бәхет булачак.


Чистарындык, тәһарәтләр алдык. Ашыкканда, дулкынланганда шулай була бит – Зәлия ялгыш кына бите белән бәрелде, кан ага башлады. Бетте, бара алмыйбыз инде, тәһарәтсез ярамый бит, дибез. Кәефе төшеп, Зәлия елап ук җибәрде. Шөкер, ярасы алай зур булмады, канны тиз туктаттык, лейкопластырь да таптык. Тынычланып, янә чистарындык һәм юлга кузгалдык. Урамга чыгуыбыз булды – коеп яңгыр ява башлады. Җил котыра гына! Кулчатырларыбызны әйләндереп үк ташлады. Әмма кире борылу уебызда да юк! Наташа Иерусалим буйлап экскурсиягә китте, без – гарәп гиды белән очрашу урынына.

Йөз-кыяфәте белән Роман Карцевны хәтерләтүче шук бер егет булып чыкты ул. Үтә дә тар урамнар буйлап сәфәребезнең төп максатына таба алып китте. Ике яклап шәрык өслүбендәге кибетләр тезелгән. Һәм – полиция нарядлары кебек, автомат тоткан хәрбиләр. Шундый постларны дүрт тапкыр узарга туры килде. Икесе яныннан узу өчен гид сөйләште, ә икесендә, безне туктатып, «Әл-Фатиха» һәм «Ихлас» сүрәләрен укыттылар. Зәңгәр күзле булгангамы икән, догаларны Зәлия укыганда, аеруча игътибар белән тыңладылар. Хәер,

PRESSA.RU



■ Ул арада безнең җитез гидыбыз «Кыя гөмбәзе» мәчете астында урнашкан, кайчандыр пәйгамбәрләр гыйбадәт кылган мәгарәгә керүне сөйләшеп, килешеп куйган. Безгә анда кереп, бер-ике рәкәгать намаз укырга да рөхсәт иттеләр. Әйтүләренчә, бу мәгарәдә Мөхәммәд пәйгамбәр дә гыйбадәт кылган, диләр. Мәгарә зур түгел, әмма аның ташларыннан ниндидер рәхәт энергия килеп тора.



Зәлия Коръән сүрәләрен миннән күбрәк белә, шуңа да аның өчен борчылмадым. Ул догалар укый башлагач, безнең гидның да күзләре маңгаена менде. Ә инде аның гарәпчә укый-яза белүен дә ишеткәч, чын-чынлап ихтирам итә башлады.

Гомергә бер була торган мизгелләр кичерүебезне мин дә, Зәлия дә аңлый идек...


Тар урамнар, иксез-чиксез тыкрыклар аша бара торгач, киң мәйданга килеп чыктык. Безнең алда гүзәлләрдән-гүзәл манзара ачылып китте. Шунда ук каршыдагы мәчетнең зур алтын гөмбәзенә күзем төште. Сизми дә торабыз – яңгыр туктаган икән бит! Намаз вакыты җитеп килә. Хатын-кызлар намазларын әнә шул алтын гөмбәзле «Кыя гөмбәзе» мәчетендә укый икән. Ул шәһәрнең теләсә кайсы ноктасыннан күренеп тора. Ә ир-атлар – түрдәрәк урнашкан Әл-Акса мәчетендә. Бөтен җирдән нур һәм пакьлек бөркелә кебек. Күңелгә шатлык тула. Ни гаҗәп: ул хис монда яши бугай. Ташларга кадәр сеңгән дә, шулардан безнең күңелләргә үзеннән-үзе иңә... Ә манарадан яңгыраган азан тавышы! Шундый моңлы – бәхеттән елыйсы килә хәтта.

Мин гидка иярдем, ә Зәлия хатын-кызлар ягына атлады. Аны анда шактый маҗаралар көткән. Хикмәт шунда: ул, ашыгып, тырнагыннан буявын сөртеп бетерә алмаган иде. Намаз укый башлагач, янәшәсендәге гарәп хатыннары, аның кулларына күрсәтеп, катгый рәвештә: «Хәрам», – диешә башлаганнар. Зәлия исә намазыннан аерылмаган, бирелеп-бирелеп укуын дәвам иткән. Читтән караганда ул шактый сәер тоелгандыр инде: ап-ак тәнле, зәңгәр күзле, киемнәре дә бүтән, җитмәсә, бер коры җире юк, битендә – лейкопластырь... Үзе чын күңелдән намазга оеган. Җомга намазы тәмамлангач, гарәп хатыннары, калып, тагын берничә рәкәгать укырга булганнар. Зәлия дә алар белән калган. Нәрсәдер сөйләшмәкче дә булып караганнар, ләкин бер-берсен аңламаганнар. Шуннан соң хатыннарның берсе Зәлиягә тәсбихын бүләк иткән: учына салган да: «Ал», дигән кебек баш каккан.

Ә мин исә мәчеткә аяк бастым да... әллә кая очтым бугай. Җомга намазын укыганымны хәтерлим, аңа өстәп тагын берничә рәкәгать укыганымны... Колонналар, матур түшәмнәр, киштәләрдә Коръән китаплары, келәмнәр... Ләкин барысы да төш кебек кенә узды, гүя мин бөтенләй башка дөньяга эләктем. Атом һәм молекулалардан тыш, анда һавада тагын нидер бар кебек иде. Тыгыз, тулышкан, кырыс, шул ук вакытта игелекле һәм рәхмәтле... Музыкант буларак, мәчеттән чыкканда бу моңны озаккарак хәтерләп калырга тырыштым. Гид нәрсәдер сөйли, ә мин, елмаеп, тик басып торам, күңелемнән генә әлеге гүзәл һәм якты көйне бергә җыйнарга тырышам...

Зәлия белән без шактый кыюлана төштек: гидыбызны Ибраһим пәйгамбәр каберенә алып барырга үгетли башладык. Башта каршы торды: «Сез чыннан да анда барырга телисезме?» – дип кат-кат сорады. Чөнки ул Шевронда – Иордан елгасының көнбатышында урнашкан. Ә ул территорияләрдә кораллы бәрелешләр булып тора, Палестинаның низаглы урыннары икән. Анда барырга теләсә кайсы такси йөртүче җөрьәт итми, барса, шунда яшәүче гарәп кешесе генә алып бара, ди. Ләкин без ниятебездән баш тартырга җыенмый идек инде. Гидыбыз, таныш-белешләренә шалтыратып, андый таксистны тапты. Хакы тешләшә тешләшүен, ләкин мондый форсат тагын кайчан була әле? Һәм без, кулчатырларыбызны ачып та тормыйча (барыбер чыланып беттек!), янә тар тыкрыклар буйлап, үзебезне таксист көтеп торган урынга йөгердек.

Таксист безне: «Әссәламегаләйкем!» – дип елмаеп каршы алды. Без исә тешләр тешкә тимәсә дә: «Вәгаләйкем-әс-сәлам», – дип сәламен алдык та җылы, коры машинага кереп чумдык... Киттек, Аллага тапшырып!



■ «Патриархлар мәгарәсе». Бу урында дүрт пар җирләнгән дип әйтәләр: Адәм белән Хава; Ибраһим белән Сара; Исхак белән Ревекка; Якуб белән Лия.

Шәһәрне чыгуга таулар башланды, урыны белән куе томан – гүя болыт юл өстендә генә асылынып тора. Борма юллар аша озак бардык, блокпостлар аша үттек. Капчыклар артында кораллы солдатлар утыра, бронялы джиплар йөреп тора. Бетон плитәләрдән салынган ныгытмалар аша үтәбез. Таксист белгән кешеләре булгач, безне беркайда да тоткарламадылар.

Һәм менә шәһәргә керәбез. Гарәпләр яши торган гадәти кала. Тар тыкрыклар, борынгы таш йортлар. Шәһәр калкулыкка урнашкан: урамнар әле үргә менә, әле түбәнгә төшә. Рульдәге шофер бу кадәр тар юллардан йортларга бәрелмичә ничек йөри аладыр – шаккатмалы. Без әле уңга, әле сулга борылабыз, әйтерсең лә юлны таба алмыйбыз. Әллә адаштык инде? «Мәчеткә берничә урам алып бара, бүген исә кайбер урамнарны Израиль хәрбиләре япкан», – диде гидыбыз. Аңлап бетермәдек, күптән түгел генә теракт ясалгангамы, җомга көн булгангамы – мәчеткә кертмиләр икән. Нindидер бер урында туктадык. Машинабызны әллә нинди шикле кешеләр урап алды. Зәлия белән сүзсез генә бер-беребезгә карашабыз: беренче тапкыр күргән гид белән таксист, шәһәрнең хәвефле бер районы... Шушында төшереп калдырып китәләр икән, исән-имин цивилизациягә барып җитәрмен, димә... Шул вакыт безнең гид янына бер көтү малай-шалай йөгереп килде. Ул аларга тиз-тиз генә нәрсәдер әйтте дә, тегеләр төрлесе-төрле якка чәчелде. Гид та, таксист та машина янындагы кешеләр белән, кызып-кызып, нидер турында сөйләшәләр. Без сүзсез генә утыруыбызны дәвам итәбез – хәзер барысы да Аллаһы Тәгалә кулында инде... Күп тә үтмәде, теге малайлар кире йөгереп килеп, куллары белән кайсыдыр якка таба төртеп күрсәтә-күрсәтә, нидер сөйләргә керештеләр. «Малайлар мәчеткә үтеп керерлек тишек тапканнар», – ди гидыбыз. Малайлар артыннан ашыктык. Алар шунда ук кулларын суздылар: һәрберсенә таңкәләр өләшеп чыктым – сүз әйтеп булмый, эшләп алдылар... Шактый атлый торгач, коймада малайлар тапкан тишеккә килеп җиттек.

Мәчет территориясенә үтсәң дә, эчкә тиз генә керерлек түгел икән әле. Ишек төбендә броня пыяла артында хәрби кешеләр утыра. Металлдан эшләнгән зур турникет. Син өчпочмак эчендә каласың – тикшерә башлыйлар. Мин үземне Россиядән, дидем. Шунда бер солдат: «Россиянең кайсы төбәгеннән?» – дип сорады. Күрәсең, безнең ватандаш иде. Татарстаннан, дидем. Үзара нәрсәдер сөйләшеп алдылар, турникет ачылды. Татарстанда да мөселманнар яши, диюләре булгандыр инде. Сак бик төгәл һәм уяу иде. Шулай кирәктер дә – изге урын бит. Бу урынны «Патриархлар мәгарәсе» дип йөртәләр. Биредә Ибраһим пәйгамбәр, аның уллары Исхак белән Якуб, хатыннары Сара, Ревекка һәм Лиянең җәсәдләре ята. Риваятьләргә караганда, Адәм белән Хава да биредә җирләнгән.

Зәлия белән мәчет эченә үттек. Ходайның хикмәте дими ни дисең – бу көнне без мәчеттә икәү генә идек диярлек. Сакчыдан кала, билгеле. Бераздан ул безнең үзебезне генә калдырды. Анда күпме вакыт булганбыздыр, хәтерләмим... Намазлар, догалар укыганнан соң, һәркайсыбыз тын калып, эчтән генә бик озак теләкләр теләдек. Мәчеттән чыккач та бик озак сөйләшә алмадык әле, хәер, сүзләр артык иде...

Ниятен тормышка ашыру өчен ерактан ук килгәнен аңлаганнар, күрәсең. Хатын-кызлар шул – сизгерләр...

Аннан соң, коеп яуган яңгыр астында Иерусалимга кайттык. «Елау дивары»на барып килдек, синагогага сугылдык. Иртә белән гарәп базарын карап чыктык та икенче шәһәргә – дустыбызга кунакка киттек. Вәгъдә ителгәнчә, анда безне барбекю көтә иде. Ул кичне тәрәзәләре диңгезгә карап торган отельдә кундык. Иртә белән серфингистларның дулкыннарда чайкалуын күзәттек... Шушында кадәр килеп, шопингсыз да булмый бит инде. Кызлар нindидер кремнар алдылар, балаларга эчертергә балык мае сатып алдык – бик сыйфатлы, диделәр.

Юлыбызга изге күңелле, яхшы кешеләр генә очрап торгач, Израильдә гел шундый кешеләр генә яшидер, дигән тәэсир калды. Без Израильне яһүдләрнең тарихи Ватаны дип санарга күнеккән. Анда исә мөселманнар да шактый. Гомумән, бик күп диннәр яралган җир бу. Ата-бабаларыбызның уртак икәне, изгеләребез дә бер үк кешеләр булуы монда аермачык күренә – бу тарих Израильдә өстә, күзгә күренеп ята. Һәм шуны аңлыйсың: безне бер-беребездән бер генә нәрсә аерып тора – тәкәбберлек. «Мин синнән өстенрәк» дигән уй кальбебездә яшәгәндә, бу сугышларның чиге булмас, күрәсең...



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз: www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU

16+

ХАТЫН-КЫЗ ШАЯРТУНЫ АҢЛАСЫН...



Фәнис СӘЛӘХИЕВ, Халыкара класслы спорт мастеры (1993), Россиянең атказанган спорт мастеры (2000). Гер спорты буенча 8 мәртәбә – Россия, 11 мәртәбә Дөнья чемпионы. Эшмәкәр.
Гаилә стажы – 27 ел;
Зилә исемле кызы,
Кирам исемле оныгы бар.

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән?
Сүзне аларга бирик.

1 Иң элек хатын-кызның Сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Алай аерып караганым юк. Тышкы кыяфәт, гомумән, минем өчен мөһим түгелдер дип уйлыйм. Хатын-кызның күңеле, эчке дөньясы бай булырга тиеш. Кайбер хатын-кыз читтән караганда әллә ни күзгә дә бәрелеп тормый, ә сөйләшеп китсәң, шундук үзенә җәлеп итә бит...

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Игътибарсызлыгын, әйтик. Алар хисләр белән яши торган халык. Әле бер нәрсә турында уйлый ул, шул арада, дөньясын онытып, икенче темага күчә. Бүген бертөрле уйлый, иртәгә – икенче төрле... Болар берсе дә ир-атның ачуын китермәскә тиеш. Вак-төякләр, чөнки.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Гафу итә алмаслык сәбәп юктыр, дип уйлыйм. Хыянәт... Хатын-кызның хыянәте өчен дә ир кеше гаепле. Димәк, ул моңа юл куйган, нигез тудырган, үзара мөнәсәбәтләрен шушы чиккә җиткергән, кайдадыр хата җибәргән! Ир-ат чынлап та гаилә башлыгы булса һәм үз роленә тулысынча туры килсә, мондый хәл килеп чыгарга тиеш түгел. Барысы да ир-аттан тора!

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?

– Хатын-кыз сине илһамландыра алмаса, ул комфорт та тудыра алмый. Чөнки болар бер-берсенә бик нык бәйләнгән. Комфорт, сезнеңчә, нәрсә соң ул? Өйнең җыештырылган, ашарга пешкән булуы гына түгел бит! Күңел тынычлыгы, әйтик. Сүзләрсез генә дә бер-береңне ишетү дип саныйм мин аны. Менә шулай утырасың диванда... Бер-береңә карап та түгел әле, аркага арка терәп... Бер сүз сөйләшмисең... Ә шулай да күңелгә рәхәт...

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Дус була ала гына түгел, ул, һичшиксез, дус булырга тиеш!

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Дөресен әйткәндә, бөтен нечкәлекләре белән хәтерләмим... 1989 ел иде ул. 1987 елда мин Әлмәттә физкультура техникумын тәмамладым. 1988–92 нче елларда читтән торып Киров шәһәренең педагогика институтында укыдым. Кыскасы, бу әле минем укып та йөргән, тренер булып та эшләгән, актив төстә спорт белән дә шөгыльләнгән вакытым. Туган ягымда – Киров өлкәсенең Нократ Аланы бистәсендә, машина төзү заводында, «Электрон» спорт клубында авыр атлетика буенча тренер идем. 1988 елда, спортчы буларак, Россиянең җыелма командасы составына кабул ителдем. 1989 елда гер спорты буенча СКА (армиянең спорт клубы) җәмгыяте исеменнән чыгыш ясый башладым. Аннары Татарстан Республикасының Спорт комитетыннан Татарстанга күчәргә тәкъдим булды... Шулкадәр тыгыз арада ничек әле өйләнергә вакыт тапканмын!

Без хатыным Динә белән икебез дә бер яктан. Ул Киров өлкәсенең Малмыж шәһәрендә туып-үскән кыз. Һөнәре буенча – фармацевт. Мин – авыл егете – Малмыж районының Иске Йөрек авылыннан. Бүгенге көндә Кукмарада яшибез.

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый...

– Бәлки шулайдыр да. Динә чыннан да әниемә охшаган: кешелекле, сабыр...

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Синең акча, минем акча, дип, бар тапканны бүлешү башлана икән, гаилә ахыр чиктә таркаладыр, дип уйлыйм мин. Гомумән алганда, ир-ат, әлбәттә, хатын-кызга караганда күбрәк акча эшли. Әмма моны һичшиксез шулай тиеш дип карарга ярамый. Әйтик, ир кешенең сәламәтлеге начарланып китсә? Ул чакта нишләргә?

9 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Гомумән, мәхәббәтне сүз белән белдерүгә начар карыйм. Ул һавада очып йөрергә тиеш! Сүз күп икән, ул, гадәттә, буш була. Тәмле сүздән ямьсез сүзгә ярты гына «адым».

10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Бу инде хатын-кызның яшенә, тормышка мөнәсәбәтенә бәйледер. Акыл утырткан, урта яшьләрдәге хатын-кыз турында сүз бара икән, аны ир-атның тышкы кыяфәте аз кызыксындырадыр дип уйлыйм. Ул акылы, дөньяга карашы, холык-фигыле белән үзенә охшаган кеше эзлидер. Ә яшь чакта, билгеле, беренче урынга матурлыкны куясың. Шуңа күрә, кызганычка каршы, акыллы кызларга юньсезрәк егетләр эләгә дә. Яисә киресенчә: әйбәт кенә егеткә җиңел холыклы кыз...

11 Хатын-кызлардан үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүләрен көтәсез?

– Мин үземне катлаулы хәлләрдән дә чыга ала торган кеше дип саныйм. Ир кеше өчен бу бик кирәкле сыйфат. Тагын – монысы инде безнең бөтен нәсел-нәсәпкә хас сыйфат – без кешене беркайчан да авыр хәлдә ташлап китмибез.

12 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Юк. Әгәр хатын-кыз акыллы икән, аның өстәвенә әле чибәр дә, көчле дә булуыннан ни зыян? Бу бит уңай сыйфатлар! Аннан соң... Чибәрлек ул – бик чагыштырма төшенчә бит. Ничек диләр әле? Һәркемнең үз «вкусы» диләрме?

Мин үзем, мәсәлән, хатын-кызда иң мөһиме: юмор булырга тиеш дип саныйм. Уен-көлкене аңламаган һәм дөньяга көлемсерәп карый белмәгән хатын-кыз белән яшәү бик авырдыр...

13 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар.

– Ир-ат логикасы ул «практиклык», катгыйлык белән аерылып торадыр. Хатын-кызлар исә хис белән яши, җирдә түгел, «күктә йөри». Кайбер гаиләләр, мисал өчен, елга икешәр мәртәбә, бурычларга бата-бата, чит илгә ял итәргә баралар. Күп очракта хатын сүзе белән. Акча юк, мөмкинлек юк дигәнне бөтенләй аңламаучы, кабул итә алмаучы хатын-кызлар да була шул.

14 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.

– Юк андый очрак. Мин хатын-кызны бик яхшы аңлыйм.

15 Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатыныгызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.

– Ул акылсызрак сүз сөйли башладымы, вакытында туктатам. Хатын-кызны, гомумән, вакытында туктата белергә кирәк. Юкса, артык кызып китү сәламәтлек өчен зыянлы ул.

Җитди мәсьәләләр турында сөйләшәбез икән, әйе, бәхәсләшеп алган вакытлар да, аның дөреслеген танып, минем «җиңелгән», юл куйган чаклар да була. Хатын-кызга юл куюны мин алай гайре табигый хәл дип санамыйм.

16 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән...

– Әзерлим дә ашыйм, билгеле. Хатын-кызның арып-талчыгып китүе дә (эшләмичә, өйдә утыра башласа, ул әле бигрәк тә арачак!) бик мөмкин, дус кызлары белән кафега баргач, онытылып, вакыт исәбен югалтуы да бар. Тормыш булгач, төрле хәлләр килеп чыга. Болар барысы да вак-төякләр, алар ике арадагы мөнәсәбәтләрне бозарга тиеш түгел, минемчә.

17 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...

– Поездга соңга калмасак, ачуны китерми. Поезд гына безне көтеп тормый бит ул – үз вакытында кузгала, синең ни сәбәпле соңаруыңда эше юк. Концертны да, без килеп җитмәгән әле, дип, башламый тормыйлар. Соңга калуга каршы ничек көрәшәсең инде ул? Гомумән, хатын-кызга каршы көрәшеп була димени?

18 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә...

– Бүләк ул – игътибар. Шуңа күрә мин бүләкне ошый-ошамый, дип бәяләп карамыйм. Иң мөһиме – ул соңгы акчага алынмасын да, бүләк бирүчене кыен хәлдә генә калдырмасын.

Аннары, нинди ир-ат хатыныннан кыйммәтле-файдалы бүләк көтсен инде?! Хатын-кызның бүләге – бары тик символик, безнең очракта мәхәббәткә ишарә генә булырга мөмкин...

PRESSA.RU



«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Лилия ГӘРӘЕВА әзерли.

Мастер-классны Татарстанның атказанган артисты, Халыкара һәм Бөтенроссия конкурслары лауреаты Марсель ВӘГЫЙЗОВ үткәрә.
5 яшеннән үзе гармун уйнап, үзе җырларга өйрәнгән Марсельнең җырчы булу теләге балачактан ук бөреләнеп калган. Яшүсмер чагыннан ук шактый конкурсларда лауреат исемнәре яулаган егет, мәктәпне тәмамлауга, туп-туры Мәдәният һәм сәнгать университетына юл ала. Остазы – Венера Ганиева. Язмышын сәнгатькә багышлавына бер дә үкенми ул, әмма тамашачыларның елдан-ел җиңелрәк җырларга өстенлек бирүенә, халыкны күбрәк җәлеп итү өчен, бәгъзе артистларның сәхнәдә әллә ниткән мөгезләр чыгарырга тырышуына күңеле әрнегәнен яшерми. Үзе дә утызлап җырга көй язган Марсельнең репертуарында халкыбызның борынгырак җырлары, профессиональ композиторларның узган гасырда иҗат иткән үлемсез әсәрләре бар. Артист сәхнәдә генә түгел, тормышта да зәвыклы булырга тиеш дип саный ул. Аш-суга карата да аның үз таләпләре. Ул, әлбәттә, тәмле, җиңел һәм җиренә җиткереп әзерләнгән булырга тиеш. Кәефе күтәренке чакларда, аш бүлмәсенә ул үзе хуҗа, җиң сызганып, җырлый-җырлый берәр тәмле сый әзерләү аның өчен җан рәхәте. Бүген ул безгә тай итеннән бик тәмле калҗа пешереп күрсәтмәкче.



ТАЙ ИТЕННӘН КАЛҖА



Кирәк:

• 1 кг чамасы сөяксез тай ите;
• кара борыч;
• тоз;
• 2 аш кашыгы зәйтүн мае (булмаса, көнбагыш мае да ярый);
• 50 г тирәсе акмай.

Гарнирга:

• 2 зур кызыл борыч;
• 2 кечкенә ташкабак;
• 2 баклажан.

Эш барышы:

■ итне калынлыгы 2-3 см булган зур калҗа итеп кисеп, әзерләп куябыз. Сеңерләре, ярылары, артык мае булса, аларын кисеп алабыз. Аннары итне юып, тоз-борыч ышкыйбыз, өстенә зәйтүн мае агызабыз да, 1-2 сәгатькә суыткычка куеп торабыз. Озагракка калдырсаң, бигрәк тә яхшы.
Ат ите җепселле, каты ит, шуңа күрә аны маринадта озаграк тотуның бер зарары да юк, йомшаграк кына булачак.

■ Итне маринадтан алып, коры табада ике ягы да кызарганчы кыздырабыз. Табаның төбе сырлы-сырлы булганы (гриль-таба) яхшырак. Андый табагыз булмаса, гадәти чуен табада да кыздырырга мөмкин. Итне озак кыздырырга кирәкми, һәр ягына өчәр минут вакыт җитә.

■ Ит кызгач, аны башка табага күчереп, өстенә мул итеп акмай кисәге куябыз да 10 минутка кызу мичкә тыгабыз. Кемнең нинди дәрәҗәдә пешкән ит яратуына карап, мичтә озаграк яки кимрәк тә тотарга була. Эче алсу калган ит яратсагыз, тизрәк алырга кирәк.

■ Ит мичтә булганда, гарнирга дип, тиз генә яшелчәләр кыздырабыз. Баклажан белән ташкабакны – 1 см калынлыгында тәгәрмәчләп, баллы борычны эре кисәкләп турыйбыз да, шулай ук төбе сырлы-сырлы табада кыздырабыз.
Бу юлы инде таба төбенә бераз гына үсемлек мае тамызырга кирәк булыр. Тозны исә яшелчәләр тәмам әзер булгач кына сибәбез.

■ Итне мичтән алып, 10 минутка фольгага төреп торабыз – ял итсен, тәмам йомшап җитсен.

■ Итне зур сай тәлинкәнең уртасына куеп, янына яшелчәләрне тезәбез дә, өстеннән «Ткемали», «Наршәраб» ише, үзебезгә ошаган әчкелтем соус сибәбез. Соусны аерым савыт белән генә дә бирергә була.

■ Ашларыгыз тәмле булсын!

PRESSA.RU

Зөлфиянең кул эшләре һәркайсы үзенчәлекле. Беркайчан да бер-берсен кабатламас, кемгә дә килешер... Менә бу шарф та һәр хатын-кызны бизи торган. Җәй өчен дә, кыш өчен дә матур ул. Теләсә кайсы киемне ачып җибәрә, бәйрәмчә тантаналы төс өсти.






Мастер-классны «Сөембикә»нең күптәнге дусты, оста куллы Зөлфия СӘЛИМҖАНОВА үткәрә.

СӘЙЛӘНЛЕ ШАРФ



Кирәк:

- матур шифон шарф (буе – 1,5 м, иңе – 40 см);
- 6 төстәге эре мәрҗәннәр. Диаметры – 6 мм. Һәр төстән – 65 данә. Төсләре шарфның бизәкләре белән ярашырга тиеш;
- 200 г үтә күренмәле вак сәйлән (№ 10);
- нечкә һәм нык кыл яки җеп (кул белән генә тартып өзәрлек булмасын);
- нечкә сәйлән энәсе;
- кайчы.



Сәйләннәрне тезү схемасы.



Эш барышы:

■ 1,5 м җеп кисеп алып, энәгә саплыйбыз. Шуңа 1 вак сәйлән элдереп, аны җепнең очына кадәр этәрәбез (20 см чамасы «койрык» калдырырга кирәк була) һәм энәне кабат шушы ук сәйлән эченнән уздырып, төенләп куябыз, җеп буйлап шуып йөрмәслек булсын.

■ 1 нче рәт: энәгә 1 вак сәйлән (берсе инде бар), 1 мәрҗән, 2 сәйлән, 1 мәрҗән (бу юлы инде башка төслесен), 2 сәйлән, 1 мәрҗән итеп, мәрҗәннең алты төслесен дә энәгә элдерәбез, аннары бу рәтне боҗрага тоташтырабыз: энәне рәт башында беренче булып торган 2 вак сәйлән аша тыгып алабыз.

■ 2 нче рәт: энәгә 5 вак сәйлән һәм аскы рәттәге мәрҗән төсендәге мәрҗән эләктереп, энәне аскы рәттә шушы турыдагы мәрҗәннән соң икенче булып торган сәйлән аша тыгып алабыз. Энәгә кабат 5 сәйлән, аннары тагын бер мәрҗән (алар һәрвакыт астагы рәттә торучы мәрҗән төсендә булырга тиеш) эләктереп, барлык алты төсле мәрҗәннәрне дә бер рәткә җыеп бетерәбез. 6 нчы мәрҗәнне энәгә эләктергәч, безгә өскә таба үрергә кирәк булачак. Моның өчен энәне икенче рәтнең башында булган 5 сәйләннең иң өстә торганы – бишенчесе аша уздырып алабыз.

■ 3 нче һәм калган барлык рәтләр: энәгә 5 сәйлән, аннары аскы рәттәгесе төсендәге мәрҗән эләктереп, энәне аскы рәттәге сәйләннәрнең бишенчесе аша уздырабыз. Калган барлык рәтләр дә шушы рәвешле бәйләп дәвам ителә.

■ Иң соңгы рәт: энәгә бер сәйлән һәм мәрҗән эләктереп, энәне аскы рәттәге бишенче сәйлән аша уздырабыз. Иң соңгы адым: энәгә 1 сәйлән, 1 мәрҗән һәм 1 сәйлән элдерәбез. Әлегә җепне кисми торабыз.

Шарфны сәйләнле «торба»га кидерү:

■ шарфны уң ягы тышка калырлык итеп, буйга гармунлап төрәбез. «Гармунны» шарфның икенче чите белән каплыйбыз һәм сак кына җыеп тотып, бер башыннан җеп белән чорныйбыз. Җепнең икенче очын карандашише артык юан булмаган озынрак таякчыкка бәйлибез. Шушы таяк ярдәмендә шарфны «торба» аша уздырабыз.

■ Гадәттә, шарфның бер очы чак кына озынрак итеп калдырыла, бәйләп куйгач, тигезлек саклансын өчен кирәк бу.

■ Соңгы эш итеп сәйләннән үрелгән «торбаның» баш-башларын тарттырып, энәне соңгы рәтнең сәйләннәре аша йөртәбез, астагы рәттәге сәйлән аша уздырып, төенлибез һәм җепне кисәбез.

■ Сәйләннәрне тезә генә башлаганда, без бер сәйләнне җепкә урап, беркетеп калдырган идек бит. Сак кына җепнең очын сүтеп алып, аны энәгә саплыйбыз һәм энәне соңгы рәт аша уздырып, аскы рәттәге сәйлән аша йөртеп, җеп очын төенлибез.

■ Шарф әзер.



PRESSA.RU

Бакчада эшнең иң күп вакыты. Суган, кишерләрне инде утыртып та өлгергәнсездер. Бүген сүзебез томат белән борыч үсентеләрен дөрес итеп күчереп утырту һәм тәрбияләү хакында.



МАЙ АЕНДА БАКЧАДА

Болгар борычы – нәзберек үсемлек. Кояшлы, җилдән ышык урынны, көпшәк туфракны ярата. Алдагы елны тәмләткеч үләннәр, кабак, кәбестә, кыяр үскән түтәлләрдә яхшы уңа. Үсентеләрне күчереп утыртырга бер атна кала, җирне йогышсызландырсаң яхшы. Моның өчен түтәлләргә 1 чиләк суда 1 аш кашыгы бакыр купоросы эретеп сибәләр.

Үсемлекләрне ачык җиргә күчереп утырту өчен быел 14–16, 19–23 һәм 28–29 май; 5–7 июнь көннәре уңышлы санала.

Борыч салкын җиргә утыртканны яратмый (бу томат белән баклажанга да кагыла), шуңа күрә алдан ук биек түтәлләр ясап, җир тизрәк җылынсын өчен, өстен полиэтилен белән каплап торсаң яхшы. Япма кара төстә булса, тагын да яхшырак.

Утыртканда рәт араларын 40 сантиметрдан да кимрәк калдырмаска кирәк. Биек булып үсә торган сортларга 60 см калдырсаң да ярый. Рәттә үсемлекләр арасы 30-40 см. Төрле сортны бер түтәлгә утыртырга киңәш ителми, алар бер-берсе белән серкәләнгәнгә күрә һәр сортның үзенә хас үзенчәлеге югала. Бер сорт белән икенче сорт арасына помидор, кукуруза ише биек булып үсә торган үсемлекләр утыртырга кирәк.

Оя төбенә 1 кашык ашлама һәм 1 кашык агач көле салып калдырсаң әйбәт. Күчерер алдыннан борычка яхшылап су сибәсе, утыртасы ояга да яхшылап су сеңдерергә кирәк. Аннары, үсемлекнең муентыгын артык тирәндә калдырмыйча гына, туфрак белән күмәсе. Өстән инде су сипмиләр, югыйсә туфрак тыгызланачак, тамырларга кислород кермәячәк. Үсемлекләрнең төбен печән белән мулчәләү яхшы нәтиҗәләр бирә. Мулчәләнгән җир тыгызланмый, артык кипми, чүп үләннәре дә котырмый. Борыч та, помидор кебек үк, артык тармакларын өзгәндә генә мул уңыш бирә. Биек үскәннәрен казыкка бәйләп куйсаң яхшы.

Помидорларны күчереп утыртырга атна-ун көн кала, су сибүне туктаталар. Утыртасы көнне генә бик мул итеп су сибәләр. Чәчәккә бөреләнгән помидор үсентеләрен күчерер алдыннан бор төнәтмәсе белән ашласаң әйбәт (1 л кайнар суга 1 чәй кашыгы бор кислотасы).

Помидорлар да кояшлы урынны ярата. Ике рәтле итеп утырту отышлы. Рәт арасы уртача биеклектәге куаклар өчен 50 см, тәбәнәк булып үсә торганнарына 40 см да җитә. Рәттәге үсемлекләр арасын шулай ук 40-50 см калдырасы. Утырту ояларының тирәнлеге – 15–20 см. Артык озын булып үскән үсемлекләргә чокырны тирәнрәк итеп казырга кирәк. Шулай да тамырлар салкын туфракка тирән күмелергә тиеш түгел. Мул итеп су сеңдерелгән оя төбенә 1 уч черемә, бераз гына көл салып калдырыла. Утыртканнан соң, төбен мулчәләп, берара су сипми торасы булыр. Температура 12 градустан түбән төшеп китсә, өстен дә капларга кирәк. Зур япмагыз булмаса, һәр куакка оннан бушаган капчык кидереп куярга мөмкин.

10 көннән соң, үсемлекләрне ачыткан сыер тизәге яки кычыткан ачыткысы белән тукландыралар. Бераздан үсентеләр ян тармаклар чыгара башлый. Аларны өзеп тормасаң, помидор бар көчен шуларга бирә. Тармакны сындырганда бераз төбен калдырырсаң, ул урыннан яңа тармаклар үсеп чыкмый.


Кучкар. Куанычларга бай ай. Тормыш вак-төяге күңелегезне төшерә алмас. Моңарчы булган проблемаларга башка яссылыктан карарсыз һәм күңелегезне борчыган ул әйберләрнең бөтенләй дә юк нәрсә булуын абайларсыз.


Үгезбозау. Тормыштан тәм табып, ләззәтен тоеп яши башларсыз. Бу дөньяда үзегезнең дә барлыкны күрсәтәсегез килер. Һәм моның өчен форсаты да килеп чыгар, тирә-юньдәгеләр сезнең акылыгызга, сәләтегезгә шаккатар.


Игезәкләр. Сезнең бар да яхшы булыр. Артык көч куймый гына да ниндидер уңышларга ирешерсез. Гүя, ниндидер көч үзе сезгә ярдәм итә кебек. Тормышның бу дәверен тиешенчә файдаланып калыгыз.


Кысла. Тирә-юньдәге ыгы-зыгының үзенә күрә тәмен тоярсыз. Тормышыгыздагы үзгәрешләр сөенеч, шатлык алып килер. Баштарак вакыйгалар сез теләгәнчә бармаса да, борчылмагыз, ахыры хәерле булачак.



Арыслан. Һәр өлкәдә уңыш елмаер. Көчегезне, вакытыгызны күбрәк гаиләгезгә багышлагыз. Ялгыз «арысланнар»ның насыйп ярларын очрату мөмкинлеге бик зур. Гомумән, бу ай танышуларга бай булыр.



Сөмбелә. Алдыгызда яңа мөмкинлекләр ачылыр. Шулар белән бергә кичекмәстән хәл итәсе мәсьәләләр дә калкып чыгар. Бу айда уңыш сезнең якта, нинди генә проблема булса да, җиңел генә чишелер.


Бизмән. Бик шәп ай – бәхет һәм уңыш ае. Күңелегездән дәрт китмәс, көчегезнең артуын тоярсыз, үзегезне бәхет канатларында очкандай хис итәрсез. Тормышның үзәгендә кайнарга әзерләнегез, бөтенесенең игътибары сездә булыр.


Чаян. Язмыш әзерләгән мөмкинлекләрдән файдалану өчен бераз көч түгәсе булыр. Аның каруы, әҗерен мулдан алырсыз. Алдыгызда яңа үрләр ачылыр, хезмәт баскычында күтәрелү форсаты чыгар. Яңалыкларга игътибарлы булыгыз.


Укчы. Үзегезне бик кирәкле кеше итеп тоярсыз, игътибар үзәгендә булырсыз. Бу айда кабул ителгән карарлар дөрес булачак, яхшы нәтиҗәләргә китерәчәк. Яңа эшләр башласагыз, отарсыз.


Кәҗәмөгез. Үзегезгә артык мәшәкать һәм чит вазыйфалар йөкләми торыгыз, көчегез кимеп киткән вакыт. Кешеләргә ярдәм итү, кайгырту хисегез көчле. Моннан файдаланырга омтылучылар да табылыр, чит-ятлардан ераграк булырга тырышыгыз.


Сукояр. Шәхси тормышта да, эштә дә искиткеч яңа мөмкинлекләр көтелә. Күңелле вакыйгалар бөтереп алыр, күптәнге яшерен хыялыгызны тормышка ашыру форсаты килеп чыгар. Үз алдыгызга зур максатлар куюдан курыкмагыз.


Балык. Тыныч һәм уңышлы ай. Зур йөкләмәләр алмый торыгыз, көчегезне гаиләгезгә, якыннарыгызга бирегез. Аз гына булса да ял итү форсатын кулыгыздан ычкындырмагыз.

*Май*да кабынган йолдызлар

Татарстан



Әлфия Галимова (30.05.1922–25.03.2015) – **Татарстанның халык аристы.**

Казанда туып-үсә. 1950–1961 елларда Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының төп җырчыларыннан берсе. Тормышын җыр сәнгате белән бәйләвенә Горький урамындагы белдерү сәбәпче була. Мәскәүгә ГИТИСка һәм консерваториягә студентлар җыялар икән. Комиссиядә утыручылар аңа консерваториягә юллама бирә. Консерваториядән соң ул Казанга – опера театрына кайта. Монда башкарган тәүге роле – «Кармен» операсында Фраскита. Дебюты дип, ул үзе «Иван Сусанин» операсындагы Антонида ролен атый. 1956 елда куелган «Алтынчәч» операсында Алтынчәч партиясен башкарып, чып-чын уңыш казана яшь актриса. 1961 елдан ул Мәскәүдә аспирантурада укый, 1964–1965 елларда Казан музыка училищесында укыта. 1966 елдан Татар дәүләт консерваториясендә эшли.

Россия



Майя Булгакова (19.05.1932–7.10.1994) – **Россиянең халык артисты.**

Украинада туа, 1941 елда гаиләләре белән Краматорск шәһәренә күченәләр. 1955 елда ВГИКны тәмамлый һәм шул ук елны Киноактер театр-студиясенә эшкә урнаша. Кинода башкарган тәүге роле – «Вольница» фильмындагы Оксана. Рольне уңышлы башкарса да, режиссерлардан әллә ни тәкъдимнәр булмагач, ул Леонид Утесов оркестрында җырлый башлый. СССРда беренчеләрдән булып Эдит Пиаф җырларын башкара. Ун елга сузылган тынлыктан соң, аны ниһаять «Крылья» фильмында Надежда Петрухинаны уйнарга чакыралар. Үзенең иң уңышлы эше дип, «Преступление и наказание» фильмындагы Катерина Ивановна ролен атый ул. Барлыгы 150 гә якын фильмда уйный.


Чит илләр



Луселия Сантос (20.05.1957) – **актриса.**

Бразилиянең Сан-Паулу штатындагы Санта-Терезинья шәһәрендә туа. Беренче ролен ул инде 14 яшендә үк башкара, «Дон Кихот» спектаклендә уйный. Яшь артистның талантын шул чакта театр укытучысы Эужениу Куснет күреп алып, Сан-Паулуга театр курсларына чакыра. Кинода уйнап караганы булмаган Луселиягә 1976 елны «Рабыня Изаура» фильмында төп рольне тәкъдим итәләр. Фильм искиткеч уңыш казана, артисткага бер-бер артлы тәкъдимнәр ява: "Глупый Купидон», «Живая вода», «Война полов»... Үзе дә ике документаль фильм төшерә. Элеккеге ире, режиссер Джон Нешлингтан туган улы Педро Нешлинг – шулай ук артист.

PRESSA.RU





СӘЙЯР РӘССАМ

Татарстан һәм Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы, ТРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты профессоры, ЮНЕСКО сынлы сәнгать халыкара Ассоциациясе әгъзасы... Закир Солтан улы БАТРАЕВ белән таныштыруны әнә шул рәвешле рәсми төстә дә башларга булыр иде. Әмма бик күпләр өчен иң беренче чиратта ул олы йөрәкле педагог.

Бу чын педагог, профессиональ рәссам буларак кылкаләмен кулыннан төшерми. Ул язган портретларда сугыш ветераннарын да, сәнгать әһелләрен дә, гап-гади замандашларыбызны да күрергә мөмкин. Икешәр мольбертта берьюлы төгәллисе эшләре көтеп тора рәссамны. Узган елның сентябрь, октябрь аенда гына сәфәр кылган Венеция дә әле рәссам хәтерендә үз төсен җуярга өлгермәгән. Шуларны тәмләп ясап ятуы. Пейзажларында Казан күренешләренә, меңьеллык шәһәрнең тарихи-архитектура һәйкәлләренә, иске агач йортларына да еш мөрәҗәгать итә ул. Үзенең күргәзмәләрендә тамашачыны Казанның инде «югалган» урам-тыкрыкларын искә төшерү мөмкинлегеннән дә мәхрүм итми. Вакыт-вакыт эшләрендә кайчандыр үзе үскән, укыган Урта Азиянең архитектура үрнәкләре дә чалынып китә. Дөнья буйлап сәяхәт иткән рәссам Мисыр пирамидаларын да, Һиндстан күренешләрен дә киндердә үзенчә шәрехли. Әнә бит, рәссамчылык инде канда: кая гына бармасын, этюднигын үзеннән калдырмаган. Африка, Испания, Греция... Кояш нурына манчылган илләрдә кылкаләме әфлисун төсенә ешрак үрелсә, Себер якларында актан да агырагын эзләгәндер ул төсләрнең. Күләгә талымлаган шәркый дөнья чалымнары, Урта Азиянең архитектура образлары да очраклы килеп кермәгән аның тупланмасына. Болары рәссам туган (Бохара), укыган (Ташкент театраль-сәнгать институты) җирләр. Ул аларның һәркайсына үз вакытында тулы шәлкемнәр багышлаган.

Тагын бер хикмәт – тауларга менү, биеклекләр яулау ләззәте. Андагы сихри манзаралар, альпинистларны гына түгел, рәссамнарны да гел ымсындырып үзенә чакырып тора шул. Бу яктан Закир Батраев та искәрмә түгел. Картиналарын күрмәсәң, бар булмышы, Ходай биргән табигате белән ашыкмый-кабаланмый торган, басынкы гына булып тоелган бу рәссамны Памир, Тянь-Шань, Һималай, Арарат, Альп, Кавказ тауларында үз сукмагын калдырган кешедер дип уйламас та идек.

– Тауда салават күперендәге бөтен төсләрне генә түгел, тагын әллә нинди могҗизалы төсләрне күрергә була. Анда яктылык та башкача. Тянь-Шаньга өч рәссам – мин һәм ике Ташкент рәссамы бергә күтәрелдек. Без – өстә, бездән аста вертолет оча. Гаҗәп бит!..


Кыскасы, юл йөрүгә килгәндә, сәйяр рәссам сәяхәтчеләрдән калышмый. Эшләре дә кимен куймый дияргә буладыр. Бүгенге көндә Россия, Япония (Токио), АКШ (Сиэтл), Кытай (Харбин) сәнгать галереяларында саклана Закир Батраевның эшләре. Йөзәрләгән картинасы Россия буйлап таралса, тагын шуның кадәрлесе Англия, Франция, Югославия, Төркия, Мисыр, Венгрия, Израиль, Греция кебек илләрдә шәхси тупланмаларда саклана. Рәссамның дистәгә якын эше Татарстан Сынлы сәнгать музеенда да урын алган.

Расиха ФАИЗОВА









ЗАКИР БАТРАЕВ

PRESSA.RU



ИГЪТИБАР!
«Сөембикә» журналының индексы үзгәрде



«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ЯҢА ИНДЕКСЫ П2204

11–21 май көннәрендә «Почта России»ның почта бүлекләрендә «Абунәче декадасы» узачак. Ташламалар булганда, журналыбызга язылып калырга ашыгыгыз!

Якыннарыгызга бүләк эзләгәндә «Сөембикә»не сайлагыз!



Татарстаннан читтә яшәүчеләр «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча язылa алалар: 73002

Журналыбызга онлайн режимда : http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып) яки безнең сайтыбызның онлайн язылу бүлегендә дә язылырга мөмкин.



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. **iPad** һәм **iPhone** кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.
Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була (**www.syuyumbike.ru**).

16+